ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ һӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

СӘЯХӘТ ИТӘ-ИТӘ ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНӘБЕЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

СӘЯХӘТ ИТӘ-ИТӘ
ТАТАР ТЕЛЕН ӨЙРӘНӘБЕЗ

КАЗАН
2024

ББК 74.268
С93

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 25 августында 730 номерлы карары белән расланган «Татар халкының милли тәңгәллеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә басыла.

Төзүчеләр:
Һадиева Г.В., ТРМҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы;
Фәттахова Р.Ф., ТРМҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты.

Сәяхәт итә-итә татар телен өйрәнәбез / төз.: Г.В. Һадиева, Р.Ф. Фәттахова. — Казан: ТРМҮИ, 2024. — 342 б.

© ТРМҮИ, 2024

ӘТИ-ӘНИЛӘР ӨЧЕН АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Тәкъдим ителә торган укыту-методик комплектына татар балалар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре сайлап тупланды. Балалар әдәбияты яшь буынны тәрбияли. Балалар өчен язылган әсәрләрнең тәрбияви көче зуррак, алар балалар күңеленә ныграк сеңеп кала.

Бу җыентыкка мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен язылган әсәрләр тупланды. Бала даими рәвештә игътибарлы булырга, тиешле мәгълүматны тотып ала белергә, истә калдырырга, күзәтергә, үз фикерен белдереп барырга мәҗбүр. Бала белән алып барыла торган әңгәмә беренче чиратта шул максатны күз алдында тотып алып барыла. Әдәби әсәрләр тирәсендә әңгәмә алып бару, сораулар кую баланы җанлы сөйләм тирәсендә йөртә, татар телендә сөйләшү ихтыяҗы тудыра. Аеруча мөһим булган мәгълүматларны кабатлату, сүзнең лексик мәгънәсен биреп бару, аерым очракларда рус телендә тәрҗемәсен бирү баланың сүзлек байлыгын арттыруга ярдәм итә. Әлеге җыентык эти-әниләр, тәрбиячеләр өчен баланы туган теленә өйрәтү барышында, милли үзаң тәрбияләү процессында, дөньяны туган телең аркылы кабул итүдә ярдәмче булыр дип ышанабыз.

ТӘМЛЕ ТЕЛЕМ

Нәни дустым, минем күптәннән синең белән очрашасым килә иде. Менә шундый мөмкинлек туды. Синең өчен җыентык төзергә алынучылар безгә синең белән очрашырга, аралашырга мөмкинлек тудырдылар. Бик зур рәхмәт аларга.

Без синең белән бик кызыклы дөньяга — тәмле тел дөньясына сәяхәткә китәрбез. Әлеге сәяхәтне без язучы, шагыйрь абый — апаларыгызның синең кебек балалар өчен язылган иң кызыклы әсәрләре аша ясарбыз. Сәяхәт булгач, тукталышларыбыз да булыр. Дөрес, алар гадәти тукталышлар булмас. Аларын вакыты җиткәч үзең дә белерсең, алдан сөйләп кызыгын бетермим.

Сәяхәтебез кызыграк барсын өчен, синнән дә ярдәм кирәк булачак, акыллым. Син бик игътибарлы, актив булсаң гына сәяхәтебез кызык булыр.

Сиңа мөрәҗәгать иткәндә, син бөтен тапкырлыгыңны, зирәклегеңне җыеп, җаваплар әзерләрсең, шулай бит. Синең әле җырларны, шигырьләрне бергәләп кабатлыйсың, исеңдә калдырасың да килер. Мондый мөмкинлек тә булыр.

Менә шундый файдалы итеп вакытыңны үткәрү мөмкинлегең бар синең, үскәнем.

— Сәлам, нәни дускаем! Синең белән танышуыма, очрашуыма мин чиксез шат.

— Ә син шатмы?

— Әйе! Ә син кем... ?

— Син минем кем икәнлегемне белмисеңме? Әйдә танышыйк. Мин — синең Туган телең. Мин сине искиткеч кызыклы туган телең дөньясына сәяхәткә чакырам. Син ризамы?

— Риза, риза.

— Әйдә рәхим ит, хуш киләсең, кадерлем.

Безнең сәяхәтебездә беренче тукталыш — Аралашу дөньясы тукталышы.

Син һәр көн әти-әниең, туганнарың, күршеләрең, кешеләр белән очрашасың, алар белән аралашасың. Әйдә әле, менә шул аралашу тәртибе турында язылган хикәя белән танышып китик.

Без, татарлар, “Исәнмесез!” дип исәнләшәбез. Кайвакытта ахырдан кешенең исемен дә кушып әйтәбез: “Исәнмесез, Зифа апа!”, “Исәнме,

Мансур!” — дибез. “Саумысез!” диярга дә була. Яшьтәшләрнең, дусларның бер-берсенә “Сәлам!” дип эндәшүләре гаеп ителми. Тик бер үк: “Сәлам, Тәһир бабай!” — дип исәнләшә күрмәгез. Тәһир бабагыз моңа бер дә сөенмәс.

Өлкәннәр белән беренче булып сез — кечеләр исәнләшергә тиеш.

Кызларны беренче булып малайлар сәламли.

Бер үк кеше белән көненә берничә мәртәбә исәнләшмиләр. Вакытка карап “Хәерле иртә!”, “Хәерле көн!”, “Хәерле кич!” диярга була.

Күрдегезме инде, дөрес итеп исәнләшә белү үзе бер һөнәр икән. Исәнләшә белеп тә, саубуллашырга оныта торган булсагыз, сезне барыбер тәрбияле бала димәсләр.

Саубуллашу сүзләре берничә: “Хушыгыз!”, “Сау булыгыз!”, “Сау булып торыгыз!”

Фирая Бәдретдин

— Үскәнем, әйт әле, нинди кешене тәрбияле диләр?

— Дөрес исәнләшә белә торган кешене...

— Әйе, иптәшләре белән, олылар, гомумән кешеләр белән дөрес исәнләшә, саубуллаша белгән, кешеләргә игътибарлы булган, дөрес аралаша белгән кеше тәрбияле кеше була.

Нәни дустым, ә аралашу кайчан рәхәт була, нинди сүзләр күңелне күтәрә икән? Син шундый сүзләрне беләсеңме?

— Зинһар өчен, рәхмәт, исән бул .

— Акыллым, син бик күп матур, тәмле сүзләр беләсең икән. Татар телендә язучы апаларың, абыйларың да мондый сүзләрне бик яраталар. Әйдә әле аларны тыңлап китик, ни өчен аларны тәмле сүзләр дип атауларын да белеп китәрбез.

Тәмле әйбер ашагач, авызга рәхәт була. Тәмле сүз ишеткәч, күңелгә рәхәт була. Ашый торгач, тәмле әйбер бетә. Ә тәмле сүз... Күпме генә тыңласаң да, күпме генә кабатласаң да, тәмле сүзнең кадере китми, рәхәте әйткән кешегә дә, ишеткән кешегә дә җитә.

Безнең телебездә тәмле сүзләр бихисап! Сез дә беләсез аларны. Төн узып, көн туу белән әйтелә торганы нинди әле? Әйе, шул: “Хәерле иртә!” Шуны бер отып алсагыз, өйдәгеләрне, күршеләрне., дусларны “Хәерле иртә!” дип сәламләргә онытмыйсыз инде! Әле тагын “Хәерле көн!”, “Хәерле кич!” дигән сүзләребез бар. Алары да онытыла күрмәсен. Хәер, көн саен, кич саен кабатлап торгач, ничек онытылсын ди алар?!

Хуш, көнне кешеләргә яхшылык, дөньяга иминлек теләп башладык. Ә нинди теләк белән тәмамлыйбыз! Шулай! Тыныч йокы теләп: “Тыныч йокы, әнием!”, “Тыныч йокы, әтием!”, “Тыныч йокы үземә, тыныч йокы күземә!”

Фирая Бәдретдин

— Язучы Фирая апагыз тәмле сүзләрне күп белә икән. Күңелләр дә күтәрелеп китте, шулай бит, нәни дустым. Әйдә әле, үзең дә язучы апа белгән тәмле сүзләрне әйтеп кара.

— ... , ... , ...

— Онытмас өчен минем арттан бу сүзләрне тагын бер кат кабатла, яме!? Хәерле иртә! Хәерле көн! Хәерле кич! Тыныч йокы, әнием! Тыныч йокы, әтием! Тыныч йокы үземә! Тыныч йокы күземә!

— Ә хәзер тәмле сүзләрне шагыйрь Шәүкәт абый Галиев белән бергә кабатлыйк әле.

Тыныч йокы

Тыныч йокы әнкәйгә!
Тыныч йокы әткәйгә!
Тыныч йокы абыема!
Тыныч йокы радиога!
Тыныч йокы үземә!
Тыныч йокы күземә!
Тыныч йокы курчакларыма!
Куяннарыма-куркакларыма!
Тыныч йокы сәгать күкесенә дә,
Тыныч йокы бөтенесенә дә!
Юк, юк, күке уяу ятсын.
Иртән безне уятсын.

Шәүкәт Галиев

— Нәни дустым, син белгән тәмле сүзләр арасында иң еш кабатлана торганы, күңелләргә аеруча якыны нинди сүз икән? Нинди сүзне ишетәсең дә әйтәсең дә килә синең?

— Рәхмәт сүзе...

— Без бертөсле уйлыйбыз икән бит, дускаем. Әле синең белән мин генә түгел, язучы абыйларның апаларың да шулай уйлыйлар. Әйдә игътибар белән тыңлыйк әле аларны.

Хикмәтле сүз

Бер сүзне күп сөйләсәм,
Аны тәмам “иләсәм”,
Тирги мине һәммәсе:
Туйдырамын, янәсе.

Ә мин шундый сүз беләм, —
Ул сүздән туймый һичкем.
Тиргәмиләр, сүкмиләр, —
Сөйләп торсаң да өч көн.

Кыен түгел әйтергә,
Бик ансат, рәхәт үзе.
Сезгә дә өйрәтәм аны:
Ул була “рәхмәт” сүзе.

Фәнис Яруллин

— Акыллым, шундый матур шигыре өчен шагыйрь абыйга без нәрсә әйтәбез.

— Рәхмәт!

— Бик дөрес, булдырасың!

Акыллы малай икән

Булат ачыгып керде,
Өстәл янына килде:
— Исәнме, тәлинкәм,
Исәнме, кашыгым,
Кердем бик ачыгып,
Тизрәк ашыймчы, — диде.
Тәмләп ашады, туйды.
Барын да алып куйды.
— Рәхмәт, — диде, — тәлинкәм,
Ашың бик тәмле икән.
Зур рәхмәт дәү әниемә,
Ул ашны тәмле иткән.
Күр ничек әйбәт иткән!
Акыллы малай икән...

— Акыллы малай ничә тапкыр рәхмәт әйтә? Кемнәргә?

— 2 тапкыр. Дәү әнисенә һәм тәлинкәсенә... .

— Мин тулысынча синең белән килешәм. Ә син игътибар иттеңме соң, шигырьдә “Рәхмәт” тән башка да тәмле сүзләр бар бит әле.

— Исәнме.

— Әйе шул. Тәмле сүзләр күп булгач, шигырьне уку аеруча рәхәт. Рәхмәт сүзен әйтүнең төрләре бик күп. Сиңа инде таныш язучы Фирая апагыз алар белән сине дә таныштырырга теләк белдерде. Тыңлап китәбезме?

— Әйе.

— Рәхим ит, нәни дустым. Игътибар белән тыңла әле, үзең дә шулай рәхмәт әйтергә өйрәнеп кал, яме?!

“Рәхмәт!”, “Рәхмәт яусын!”, “Рәхмәтләр яусын!” — бик тәмле сүзләр. Син аларның тәмен үзең дә беләсең, чөнки үзеңә генә атлганнарын гел-гел ишетеп торасың.

“Бер рәхмәт мең бәладән коткара” диләр. Тик рәхмәт ишеткән саен: “Инде ничә бәладән котылдым икән?” — дип санап барасы юк. Ишеткән рәхмәтләреңнең санын белмә син.

Ә менә тиешле урында үзең дә рәхмәт әйтә бел. Берәрсе иелеп ботинка бавыңны бәйләсә — рәхмәт әйт. Әниең белән син килеп керүгә автобуста кемдер сикереп торып урын бирсә — “Рәхмәт!” диген. Өйдә дә, урамда да, бакчада да кемнәрдер сиңа гел яхшылык эшләп тора бит. Берсен дә рәхмәтсез калдырма. Алар: “Дәү үс!” — диярләр. Көненә утыз мәртәбә “Дәү үс!” дисәләр, ай үсәсен көн үсә башлыйсың әле ул. Чынлап. Ышанмасаң, сынап кара.

Фирая Бәдретдин

— Акыллым әйт әле, шундый матур итеп әйткән “Рәхмәт” кә ничек җавап бирергә кирәк икән?

— Дәү үс!

— Кара әле, нинди матур, тәмле сөйләшү килеп чыкты:

— Рәхмәтләр яусын !

— Дәү үс! — Шулай бит. Әйдә әле бергәләп кабатлыйк. Исеңдә калдымы?

— ... .

— Нәни дустым, ә син үзең рәхмәт сүзен еш ишетәсеңме? Исеңә төшер әле кайчан, кайда һәм ни өчен сиңа рәхмәт әйткәннәре бар? Исеңә төштеме? Бик

яхшы. Ә менә Алсуга беренче рәхмәтне абыйсы әйткән. Ни өченме? Шигырьне игътибар белән тыңласаң, син моны үзең дә беләчәксең. Син әзерме?

Беренче рәхмәт

Алсу хәзер зур кыз инде —
Аңа өч тулган.
Алсу бүген абыйсының
Яулыгын юган.
Сабынлаган да яулыкны,
Чиләккә тыгып
Чайкаган да элеп куйган,
Тормыйча сыгып.
Шатлыктан нәни Алсуның
Күзләре яна:
Рәхмәт әйткән моның өчен
Абыйсы аңа.
Мөмкин түгел шатланмаска:
Бит шундый рәхәт,
Чын күңелдән эшләп алган
Беренче рәхмәт!

Әхмәт Исхат

— Акыллым, тәмле сүзләр арасында йөри торган һәм тормышта кирәк була торган тагын бер сүзне исеңә төшерәсем килә. Ул — “Гафу ит?!” “Гафу итегез?!” сүзләре. Исеңә төшереп кара әле бу тәмле сүзләрне кешеләр кайчан әйтәләр?

— Ялгышканда.

— Дөрес аңлыйсың. Әйе, ялгышлык белән дөрес түгел эш эшләгәндә, ялгышып киткәндә. Шагыйрь Шәүкәт абыегыз үзенең шигырендә сиңа шундый очракларның берсе турында сөйли. Тыңлыйбызмы? Рәхим ит.

Гафу үтендем
Ялгыш аягына баскач,
Тизрәк гафу үтендем.
Борынымны ялап алды —
Кәефе килде этемнең!

Шәүкәт Галиев

Дустым, тел — халыкның, милләтнең иң беренче, иң әһәмиятле билгесе. Тел бетсә, ул телнең иясе булган халык та, милләт тә югала. Шуның өчен дә туган телен кадерләп саклау, үстерү, аның сафлыгы, матурлыгы өчен көрәшү — һәр кешенең изге бурычы. Кечкенә дустым, телебезне бергәләп саклыйк!

Татар теле

Мин бала чактук «әти, әни»
дидем шул тел белән,
Һәм дә әнкәм дә миңа
«бәбкәм» дигән шул тел белән.
Әле дә шул тел белән
укыйм, язам һәм сөйләшәм,
Шул татар теле белән
көйлим, берәр көй көйләсәм.

Мәҗит Гафури

Татар теле

Татар теле — минем туган телем,
Сөйләшүе рәхәт ул телдә.
Шул тел белән көйлим...
Шул тел белән сөйлим
Милләттәшем булган һәркемгә.
Дөньялар киң, анда илләр бик күп,
Туган илем минем бер генә.
Туган илемдә дә телләр бик күп,
Туган телем минем бер генә.

Нәҗип Мадьяров

Туган тел

Әткәң-әнкәң телен белсәң
Адашмассың кайда да...
Туган телемдә эндәшәм
Кояшка да, айга да
Игелекле булып үсим
Газиз туган телемә.
Туган тел бер генә була,
Әнкәй кебек бер генә.

Газинур Морат

Хәерле иртә!

Кояшның шаян нурлары
Аркама төртә минем.
Хәерле иртә, әнием!
Хәерле иртә, өем!
Хәерле иртә дип дәшәм
Сөйгәнгә анам телен.
Хәерле иртә, туганнар,
Хәерле иртә, илем!
Озата бара мәктәпкә
Иртәнге җылы җилем!
Хәерле иртә, дусларым,
Хәерле иртә, җирем!
Өметләр алга чакыра,
Офыклар дәшә юлга.
Хәерле иртә, кешеләр!
Хәерле иртә, дөнья!

Рифат Сәлах

Былбыл сайратам

Сокланып туймыйм
Сайрар кошларга:
Кайларга китми
Алар кышларга!
Тик онытмыйлар
Туган илләрен,
Саклый һәммәсе
Туган телләрен.
Мин дә телемне
Бик тә яратам,
Туган телемдә
Былбыл сайратам.

Хәкимҗан Халиков

Дустым, син дә туган телеңне — татар телен онытма!!! Туган телдә былбыл сайратучы бул!!! Кошлар да бит туган телләрен онытмыйлар!!!

Туган тел — иң татлы тел,
Туган тел — иң тәмле тел.
Тәмле дип, телең йотма —
Туган телне онытма!

Шәүкәт Галиев

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.
Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.
И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.
И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

Габдулла Тукай

Бигрәк күңелгә керә торган сүзләр...

Габдулла Тукайның “Туган теле” шигыре татар халкының рәсми булмаган гимны икәнен белә идеңме? Ә гимны һәрвакыт аягүрә басып тыңлыйлар. Онытма!!!

Ел саен Габдулла Тукайның туган көнендә туган тел көне үткәрелә. Туган телдә матур шигырьләр, җырлар яңгырый. Бик күңелле һәм матур бәйрәм!

Тылсымлы “Туган тел”

Бик шатлыклы көнем бүген —
Чәчәк аткан яран гөлем.
Сулар сипкән идем җырлап
Тукйның мин “Туган тел”ен.
Минем бу гөлем, күрәсең,
Җырымны бик тә ошаткан,
Аннан шул моң тылсымыннан,
Күр, кыш көне чәчәк аткан.
Язлар биткәч тә, гөлемә
Җырлармын туган телемдә.
Аннан һәйкәлгә итәрмен
Тукайның туган көнендә.
Йолдыз

Туган тел бәйрәме
Кунакка килдек мәктәпкә,
Туган көн бәйрәменә.
Туган көн кебек кадерле
Туган тел бәйрәменә.
Без киләсен белеп, дуслар
Алдан ук сөенгәннәр.
Туган көндәге шикелле,
Бик матур киенгәннәр.
Сөенмичә ни —
бәйрәм ич! —
Шигърият дигән илдән
Шагыйрә апалар белән
Шагыйрь абыйлар килгән.
Матур сүзне матур сүзгә
Сөйлибез, бәйләп кенә.
Әйләнсен һәрбер көнебез
Туган тел бәйрәменә!

Лена Шагыйрьҗан

Һәйкәл

— Тукай туган Кушлавычта,
Исмен данлый һәйкәле,
Энем, белсәң, әйт әле?
Аңа кем соң һәйкәл куйган,
— Беләм, абый, зур
шагыйрьнең
Китабы гел кулымда,
Аның моңы, үлмәс җыры
Яши күңел кылымда.
Гасырларга барсын диеп,
Аңа һәйкәл куелган.
Халык мәхәббәтен салып,
Исме ташка уелган.

Нур Гайсин

Әйе, татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайга Арча районы Кушлавыч авылында һәйкәл куелган. Музее да бар. Өлкәннәр белән барып әлеге урынны карап кайта аласың.

Туган телем

Дөньяда иң-иң матур ил
Ул — минем туган илем.
Дөньяда иң-иң матур тел
Ул — минем туган телем.
«Балам!» —диеп , туган телдә
Эндәшә миңа әткәм.
«Әнием!» — дип, әнкәемә
Мин туган телдә әйтәм.
Туган телемдә сөйләшеп,
Яшим мин туган илдә.
«Туган ил» дигән сүзне дә
Әйтәм мин туган телдә.
Иң изге хисләремне мин
Туган телдә аңлатам.
Шуңа күрә туган телне
Хөрмәтлим мин, яратам.

Энҗе Мөэминова

Әбиләр биеклеге

Туган телем, син җанымны
Шигырьле, нурлы иттең.
Үстердең, үсендердең дә,
Күңелне җырлы иттең.
Әбием куллары булып
Сыйпадың, иркәләдең.
“Әкият аз сөйләдең”, — дип
Турсайдым, үпкәләдем.
...Сөйләрләр әле әкият,
Берне түгел, икене.
Тик әбиләр мөнбәрендә
Яшәү безгә икеле...

Эльмира Шәрифуллина

Дустым, туган тел кешене нинди итә? Син дә әбиең кебек була алырсыңмы?

Үз телендә сөйләшә

Әтисе дә сөйләшә,
Әнисе дә сөйләшә.
Шулай булгач, нигә әле
Айдарга сөйләшмәскә?! —
Теле бар бит аның да!
Кара-каршы сөйләшергә
Әбисе бар янында.
— Әт-тә, ән-нә, тәт-тәт-тәт!..
Әб-бә, баб-ба, тәт-тәт-тә!.. —
Айдар шулай матур итеп
Үз телендә сөйләшә.

Энҗе Мөэминова

Телләр белүче каләм

Үзем дә сизми калам —
Татарча яза каләм.
Русчасын да ким белми —
Хәзер русча кем белми!
Артекта исем китте,
Чит телдә сырлап үтте:
Француз алгач кулына —
Французча яза каләм!
Немец алгач кулына -
Немецча яза каләм!
Инглизчә дә йөгерә,
Испанча да өлгерә,
Вьетнамча, гарәпчә,
Әллә ничә тел белә!
Язды каләм истәлек,
Бер үк булды эчтәлек:
Тынычлык диеп язды,
Һәм дуслык диеп язды!
...Татарча язган каләм,

Русча да язган каләм,
Шулай бик тиз көйләнеп,
Дөньяларны әйләнеп,
Кайтты телләр өйрәнеп!

Шәүкәт Галиев

Ат ник көлә?

Авылга әбиләренә
Кунакка кайткан Ирек
“Привет, конь!” — дип
исәнләшкән.
Җирән кашканы күреп.
Җирән кашка башын чайкап:
— Миха-ха-хай! — дип
көлгән.
“Ник көлә ул?” — диеп Ирек
сораган әбисеннән.
Әбисе хәйләкәр генә
Елмаеп болай дигән:
— Үз телен оныткан, диеп
көләдер, улым, синнән...

Шамил Маннапов

Дустым, ничек уйлыйсың, ат нигә көлде икән? Синең белән яки танышларың, дусларың белән шундый көлкеле хәлләр булганы бармы?

Танышу

Күрсәтим дигән идем
Русча белгәнемне,
Әтәч тә аңламады
«Привет» дигәнемне.
— Ки-ке-ри-күк! — диде дә
Очты кунды киртәгә.
Акбай әйтә: «Татарча
Исәнләш, — ди, — иртәгә!»

Рәшит Бәшәр

Белми

Күршебезгә бер малай
Кунакка кайткан.
Уйнаганда, болыннан ул
Бер бөҗәк тапкан.
«Камка бабай»ны иелеп
Алды кулына.
Такмаклады, ап-ак җәймә
Җәеп юлына.
Камканың шул исе китми,
Берни ишетми.
Гүя шәһәр малаен ул
Үзенә иш итми:
Мыегын да, канатын да
Һич тә селкетми.
Мин кулыма алган идем:
— Камка, кач, — дидем, —
Балаларың көтә сине,
Алар ач, — дидем.
Канатларын җилпеде дә
Китте ул очып.
Карап калды кунак малай
Авызын ачып.
Үпкәләде шәһәр кунагы —
Елмаймый, көлми.
Безнең авыл камкасы ул,
Урысча белми.

Йолдыз Шәрәпова

Рус казлары: га-га, ди...

Русларда да бар казлар,
Татарда да бар казлар.
Рус казлары: га-га, ди,
Татар казы: кыйгак, ди.
Русларда да бар әтәч,
Татарда да бар әтәч.
Русларның: кукареку!

Татарның: кикерикүк!
Русларда да бар маэмай,
Татарда да бар маэмай.
Рустагысы: гав, гав, ди,
Татардагы: һау, һау, ди.
«Гав, гав»ларга юлыксам мин
Русча гына эндәшәм.
«Һау-һау»ларны күргән чакта
Гел татарча сөйләшәм.
Урамда, ишек алдында
Алар да очрашалар.
Ничек хәл сорашалар,
Үзара аңлашалар?
Русча мәче: мияу, ди,
Татарча да, мияу, ди,
Анда, монда йөри мәче,
Шул мәллә тәрҗемәче?
Шәүкәт Галиев
Шифалы сүзләр
Шифалы сүзләр өйрәтте
Безгә тәрбиячебез,
Шуңа күрә бакчабызда
Без бик тату яшибез.
Исәнмесез. Сау булыгыз.
Зинһар. Гафу итегез.
Хәерле көн. Хәерле юл.
Исән кайтып җитегез.
Рәхмәт. Бик шат яхшы сүзгә.
Котлы булсын. Хушыгыз.
Я, кем миннән күбрәк белә?
Ягез, өстәп кушыгыз!

Вәсимә Хәйруллина

Чынлап та, сүзләр шифалы буламы? Син ниди сүзләр өсти аласың? Мондый сүзләрне ишеткәндә син үзеңне ничек хис итәсең?

Ана теле

Үз ана телем — минем өчен матур, иң тәмле тел,
Үз телем — үз әйберем булган өчен ярата күңел.
Шул ана телем белән мин максудымны аңлатам;
Шул анам теле белән «бала» диләр ата-анам.
Шул тел аркылы иман, уку-язуны үрәнәм;
Шул тел аркылы укып, белеп булырмын чын адәм.
Мин бала чактук «әти-әни» дидем шул тел белән,
Һәм дә әнкәм дә миңа «бәбкәм» дигән шул тел белән.
Әле дә шул тел белән укыйм, язам һәм сөйләшәм,
Шул татар теле белән көйлим берәр көй көйләсәм.
Һәрвакыт шул тел белән язган матур китап укыйм,
Һәрвакыт шул тел белән тарих укыйм, хисап укыйм.

Мәҗит Гафури

— Балам, туган телең һәрвакыт кадерле булсын! Хөрмәт ит, ярат аны!

Татарстан

Мин яшим татар илендә,
Татарстан — ватаным.
Тәүге сүземнән үк сине
«Ватаным!» дип атадым.
Мин яшим татар илендә,
Мин — татарның баласы.
Күңелгә якын урманы,
Елга-күле, даласы.
Мин яшим татар илендә,
Татарстан — ватаным.
Монда көнем гел кояшлы,
Төнем айлы, ал таңым.
Мин яшим татар илендә,
Чит җирне якын күрмәм.
Ата-анам нигезенең
Җылы нурын сүндермәм!
Мин яшим татар илендә,
Мин — татарның баласы!
Күңелгә якын авылы,

Бистәләре, каласы.
Мин яшим татар илендә,
Татарлыкны аклармын! —
Әби-бабамнардан килгән
Гадәтләрне саклармын!

Ленар Шәех

Иң тугры китап
(әкият)

Китапханәгә яңа, матур киштә кайткач, китаплар арасында бәхәс чыкты: «Кайсыбыз анда куелырга лаеклы?» — дип. Чөнки киштә, чыннан да, шундый да гажәеп күркәм, менә дигән итеп эшләнгән, ди. Җитмәсә әле, үзен, һәр кергән кешегә дә күренерлек итеп, бүлмәнең иң түренә дә элгәннәр, ди. Дөрестән дә, яңа киштәдә урын алу һәр китапка зур дәрәҗә булыр иде. Кызганыч, анда күп китап сыймаячак икән шул.

— Әйдәгез, болай итик. Кайсыбыз эчтәлек ягыннан иң кызыгы, камиле, күбрәк укылган — шул арны сайлап алыйк. Беренче чиратта, китапханәбез күрке алар ич! Күп укылганнар ихтирамга чиксез лаеклы. Урыннары да мәртәбәле урында булсын! — диде матур тышлы, калын олпат китап, алга чыгып.

— Ә без кайсыбызның күпме укылуын каян белик? — диеште аңа каршы калганнары.

Олпат китапның моңа да җавабы әзер:

— Кайсыбыз күбрәк таушалган, шул күбрәк укылган була инде! — диде ул горур гына, үзенең шундый да акыллы киңәш бирүеннән канәгать калып.

Һәм китаплар бик-бик ерткаланып, сызгаланып, пычранып беткән бер китапны шундук араларыннан сайлап та алдылар.

— Иң таушалганы син, димәк, иң күп укылганы да син! — дип, җиңүче итеп аны билгеләделәр.

Әмма теге китап, һәммәсен дә аптырашта калдырып:

— Ашыкмагыз әле… — ди. — Фикерегез дөрес түгел. Битләрем балалар үтә дә яратып укыганга шулай теткәләнеп беткән, дип уйлап ифрат ялгышасыз. Күп укылганга да шулай таушалган бу, диеп хаталанасыз. Мондый хәлгә мине тәртипсез бер малай җиткерде. Бер генә мәртәбә укырга дип алды мине һәм туп урынына типкәләде-очырды, футбол уйнады. Теләсә кая ыргытып кадерсезләде. Рәсемнәремне сызып, бозып, буяп бетерде.

Дусларым, берегезгә дә мин кичергәнне кичерергә, минем хәлдә калырга язмасын.

һәм мескен китап үз ишләренә башыннан үткәннәрне, моң-зарларын бәйнә-бәйнә сөйләп бирүгә, аңа кушылып, башка күп кенә китаплар да:

— Мине дә шулай рәнҗеттеләр…

— Мине дә… — дип уфтанышты.

Бераз тынычлангач, теге таушалып-теткәләнеп беткән китап янә сүз алды: — һәрберегез дә, мөгаен, үзенең ничә мәртәбә укырга алынуын санап, укылу-укылмавын барлап бара торгандыр. Шуның исәбен алыйк та лаеклыларны билгеләп куйыйк, — диде ул, киңәшен биреп.

Ни гаҗәп! Исәп-хисап ясалганнан соң, «иң күп укылган китап» дип сайланганга карасалар, ни күрсеннәр — аның тышлыгы ап-ак кәгазь белән тышланган, битләре дә бөкләнмәгән-тапланмаган, рәсемнәре дә сызгаланмаган-бозгаланмаган иде. Әле хәтта, укылган урынын билгеләп барыр өчен, бит арасына тасма да кыстырып куелган.

— Килеш-килбәтебезнең пөхтәлеге, җыйнаклыгы укучыларыбыз ихтыярында икән. Әнә күрәсез, күп укылып та, чип-чиста булып калуыбыз бар. Ә кайбер юньсезләрнең кулына бер генә эләгеп тә, таушалып, ерткаланып, теткәләнеп бетүебез ихтимал икән! — диеште китаплар, үз ачышларына таң калып.

Иң күп укылган китапларны сайлап алганнан соң, җыелганнарга беразга таралышмаска кушып, олпат китап болай диде:

— Җәмәгать, менә бу таушалган китап, хакыйкатьне ачмаса, иң күп укылучы китап — мин, дип, теләсә, һичшиксез, киштәбез түренә беренче булып менеп кунаклый ала иде. Ә ул мин-минләнмәде, дөреслекне яшереп, дәрәҗәле урын алырга омтылмады. Хаклыкны өстен күрде. Алдашмавы, дөреслекне ихтирам иткәне өчен без дә аны зурлыйк, аңарга «Иң тугры китап» дигән дәрәҗәле исем бирик. Аны, олылап, туры сүзләләрне, ялган сөйләмәүчеләрне генә хөрмәт итүебезне белдереп, күп укылучы китаплар янына урнаштырыйк!

Башкалар да аның сүзен хуплап кул чапты:

— Тугры китап, үзең дә күрәсең һәммә китапларның да бу тәкъдимне ничек кабул итүен. Бу исем, чыннан да, җисемеңә шундый да туры килә. Син ихластан олы хөрмәткә лаек! Шуңа күрә урының да һәрчак түрдә булсын! Китапханәбезгә кайтачак һәр яңа китапка да сине күрсәтеп, үзеңне олыларбыз! Синнән үрнәк алырга өндәрбез!

Олпат китапның сүзе тәмамлануга, һәммә китаплар да иң таушалган китапны уратып алып, аның кулын кысты. Аны ихластан хөрмәт итүләрен белдерде.

— Пычранып, теткәләнеп беткән килеш тә, китап кадерен белмәүче малай-кызларга гыйбрәт булсын өчен, күп укылган, дәрәҗәле китаплар яныннан урын алырга мин каршы түгел. Безне ерткаламаска, таушалдырмаска, бары тик укыр өчен генә кулга алырга кирәклеген искәртеп торыр өчен. Бәлки әле, мине кыерсыткан теге малай да китапханәбезнең ишеген ачып керер, үзенең ни кылганын күреп оялыр-кызарыр, китап кадерен белергә өйрәнер, — диде китап, хөрмәтләүләре өчен янындагы-ларга ихластан рәхмәт әйтеп.

Һәм, чыннан да, иң күп укылучы дәрәҗәле берничә китап белән әлеге Иң тугры китап та, тәртипсезләргә, китап кадерен белмәүчеләргә гыйбрәт булсын өчен, бүгенге көндә дә матур киштәдә тора, ди!

Нурия Сәйяр

Татар баласы

Калфак кигән кыз баланың
Багып алчы йөзенә:
Нинди гүзәл татар кызы! —
Күз тимәсен үзенә.
Килешеп тора түбәтәй
Аның күркәм йөзенә:
Нинди матур татар улы! —
Күз тимәсен үзенә.
Үзе тыйнак, үзе горур,
Хак сүз булыр әйткәне.
Яратыр газиз Ватанны,
Сөяр әткәй — әнкәйне.
Дәү булгач та шулай калыр
Татар баласы булып.
Әйтерләр:
— Татар кызы бу!
Диярләр:
— Татар улы!

Ләбиб Лерон

Татар баласы нинди була? Ул нәрсә кигән? Син мин татар кызы яки улы дип әйтә аласыңмы?

Сөйләшәләр безнеңчә

Җирдә нинди илләр юк,
Нинди генә телләр юк.
Һәркем сөйли үзенчә,
Сөйләшәләр безнеңчә.
Эреп китәм май кебек,
Йөзәм тулган ай кебек.
Яктырганнан яктыра.
Күңелдә таң аттыра
Балдан да татлы телем,
Нәфис һәм затлы телем.

Хәкимҗан Халиков

ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Нәни дустым, без бит икенче тукталышка да килеп җиткәнбез, бу — үзем дигән дөнья.

Тәмле сүзләр турында сөйләшә- сөйләшә без бит әле ныклап танышмадык та. Әйдә әле, синең турыда сөйләшик. Ике кулыңа кара әле, ничә бармагың бар? Саный беләсеңме аларны? Әйдә бергәләп саныйк: бер бармак, ике бармак, өч бармак, дүрт бармак, биш бармак. Бер кулда ничә бармак?

— Биш.

— Булдырдың, әйе шул бер кулда биш бармак. Ә икенче кулда ничәү икән? Саныйбызмы? Әйдә бергәләп: бер бармак, ике бармак, өч бармак, дүрт бармак, биш бармак. Бик матур санадың. Ә ике кулда ничә бармак булуын санап чыгарасың киләме? Әйдә бергәләп саныйбыз: бер бармак, ике бармак, өч бармак, дүрт бармак, биш бармак, алты бармак, җиде бармак, сигез бармак, тугыз бармак, ун бармак. Афәрин! Бу сүзне кеше эшне яхшы итеп эшләсә, аны мактаганда әйтәләр. Әйдә кабатлап карыйбыз: Афәрин!

Акыллым, мин әле синең исемеңне дә белмим икән бит. Синең исемең ничек?

— ... .

— Исемең бик матур. Танышуга мин бик шат. Минем белән син таныш инде, шулай бит? Мин — Туган тел. Ә син бармакларның да исемнәре булганны беләсеңме?

— Юк, белмим.

— Белмисеңмени? Алай булгач, әйдә, танышыйк. Әминә апагыз Бикчәнтәеваның алар турында бик матур шигыре бар.

Бармаклар

Менә минем бармаклар,
Шаян алар, шук алар.
Бармаклар гел уйныйлар,
Уйный-уйный туймыйлар.
Менә минем бармаклар:
Баш бармак, имән бармак,

Урта, атсыз һәм чәнчә —
Бик дус алар, гел бергә.

Әминә Бикчәнтәева

— Кайсы бармагыгызның исеме ничек икәнен белдегезме? Әйдәгез бергәләп әйтеп чыгыйк әле: баш бармак, имән бармак, урта бармак, атсыз бармак, чәнчә бармак. Нәни дустым, ә син кулларның ни өчен икәү икәнлеген беләсеңме?

— Әйе .

— Белсәң әйтеп кара әле?

— Эшләр эшләр өчен.

— Афәрин! Ә тагын ни өчен икәнен беләсең килә синең, шулаймы? Әйдә бергәләп шигырьләрне тыңлап китик. Шигырьләрне тыңлагач, үзең дә әйтерсең, яме?

Кулым нигә ике?

«Кулың нигә ике?» — диләр
Бу ни өчен, әйтимме?
Берсе әнине тотарга,
Икенчесе — әтине.

Мәрзия Фәйзуллина

Тәти кул

Уң кул була, сул кул була,
Ә уң кул була әти.
Тәти кул белән ашарга
Өйрәтте мине әти.

Мәрзия Фәйзуллина

Чәбәк-чәбәк

Чәп-чәп, чәбәкәй,
Кулларыбыз бәләкәй.
Ә хәзер тизрәк-тизрәк
Чәбәклик күңеллерәк.

Әминә Бикчәнтәева

— Акыллым, куллар нинди булалар, исеңдә калдымы? Әйдә бергәләп кабатлыйбыз. Уң кул, сул кул. Ә кайсы кул тәти була?

— Уң кул.

— Әйе, уң кул тәти. Әйдә бергәләп кабатлыйк: уң кул — тәти. Нәни дустым, ә синең кулыңны ясап караганың бармы? Әйдә әле, бергәләп ясап карыйк. Моның өчен дәфтәреңне, карандаш алырга кирәк. Сул кулыңны, бармакларыңны җәеп, дәфтәр битенә куй, ә уң кулыңа карандаш ал һәм кулыңны, бармакларыңны кырыйдан йөртеп чык. Килеп чыктымы? Афәрин. Мөгаен, бик матурдыр. Кулларыңны чәбәкәй итеп, үзеңне үзең дә мактап ал инде. Ничек чәбәкәй иткәннәрен беләсеңме? Ике кулыңны бер-берсенә сугып-сугып алу чәбәкәй итү була. Әйдә бергәләп: ... . Күңелләр күтәрелеп китте, шулаймы?

Килеп чыкмаса да күңелсезләнмә, син башта кулыңны берәр олы кеше ярдәме белән ясап кара, ә аннан соң үзең,сөйләштекме?

— Акыллым, ике кул бик күп эшләр башкара ала. Шуларның аеруча әһәмиятлесе турында хикәя тыңлап китикме? Рәхим ит.

Канатларың булса

Бер кыз кошларның канатлы булуларына кызыгып яшәгән.

— Ник минем канатларым юк икән? — дигән бу кыз әнисенә.

— Кошларның канатына кызыгасыңмы? — дигән әнисе.

— Әйе, бик кызыгам, — дигән кыз.

— Канатың булса нишләр идең, балам? — дигән әнисе. — Әллә очып китәр идеңме? Мине калдырып?

— Очып китәр идем дә... Очып кайтып җитәр идем, сине сагынып. — дигән кызы.

Әнисе кызын кочагына алган. Кыз да әнисен кочаклаган.

— Канатларың булса, кулларың булмас иде. Син мине болай кочаклый алмас идең, кызым, — дигән әнисе.

Кыз шунда әнисен тагын да кысыбрак кочаклаган.

Моннан соң ул кошларның канатлы булуына да кызыкмаган. Аларга ул бик яратып карый, кызганып та куя... Үзенең бердәнбер әнисе, әнисен кочакларга ике кулы булган өчен шатланып яши икән.

Рөстәм Мингалим

— Акыллым, син дә яныңдагы якын кешеңне, яраткан уенчыгыңны кочаклап ал. Рәхәт булып китте, шулаймы?

— Нәнием, без куллар, бармаклар белән таныштык. Әле аяклар, колаклар, иреннәр һәм башкалар белән дә танышасыбыз бар, аларны танырга

өйрәнәсебез бар. Без тыңлаячак хикәя шул турыда. Игътибар белән тыңла, үзең дә аларны тап һәм атап чыгарга әзерлән, ярыймы?

Барын да юарга кирәк

Минем ике кулым бар. Ике кулда — бишәр бармак. Бармакларда — тырнаклар. Монысы — терсәк. Кулның бу ягы — уч төбе, бу ягы — кул сырты. Тырнакларны кисеп торырга, тырнак төпләрен әйбәтләп юарга кирәк.

Минем ике күзем бар. Күзләрнең — кабаклары, кабакларның — керфекләре бар. Алар күзне тузан керүдән саклыйлар. Күз өстендә каш бар.

Бусы — баш. Башка чәч үскән. Иртә дә, кич тә мин чәчемне тарыйм. Болары — колаклар. Колакларның яфраклары бар. Колакны да юып торырга кирәк.

Монысы — муен. Бусы – күкрәк. Болары — аяклар. Аякта да бармаклар бар. Бусы — тез. Монысы аяк табаннары, монысы — үкчә, үкчәдән югары — балтырлар. Кич белән ятар алдыннан мин аякларны юам.

Мин тагын авыз белән борын турында әйтергә онытканмын. Авызда тешләр бар. Бусы — тел, ул бер дә тик тормый.

Мин иртә белән кулларны, колакларны юарга, тешне чистартырга онытмыйм. Билгә кадәр чишенеп, салкын су белән юынам. Шуннан соң сөлге белән сөртенәм.

— Нәни дустым, ә син юынырга яратасыңмы? Без әзерләп куйган карандаш белән дәфтәреңә үзеңнең ничек юынганыңны ясап куярга онытма, яме? Рәсемеңне миңа да якыннарыңа да күрсәтергә дә онытмассың дип уйлыйм.

— Ә без синең белән танышуны табышмаклар ярдәмендә дәвам итсәк, син каршы килмәссең бит? Табышмаклар чишү, аның җавабын табу бик мавыктыргыч эш ул. Син инде аңладың булсаң кирәк: тыңларга, аңларга һәм бирелгән билгеләре аша җавабын табарга кирәк. Син әзерме? Тыңлыйбыз, уйлыйбыз, җавабын әйтәбез. Әйдә әле бергәләп нишләргә кирәген кабатлыйбыз: тыңлыйбыз, уйлыйбыз, җавабын әйтәбез.

Ике агай тау артында яши,
бер-берсен күрми.

— Уйлыйк әле, күрер өчен нәрсәләр кирәк? Әйе, шул күзләр. Алар ничәү? Әйе икәү. Димәк, табышмакның җавабы да — күзләр. Ә синең

дәфтәргә карандаш белән күзләреңне ясап караганың бармы? Буш вакытта ясап кара әле, яме? Аннан соң якыннарыңа да күрсәтергә онытма.

(Күзләр)

Ти дигәндә тими,
Тимә дигәндә тия.

— Әйтеп карыйк бергәләп: ти, ти. Иреннәр бер-берсенә тидеме? Юк шул. Инде әйтеп карыйк: тимә, тимә. Иреннәр нишләде? Әйе, бер-берсенә тиде.

Димәк, табышмакның җавабы — иреннәр.

Бер анадан биш бала.

— Нәни дустым, исеңә төшер әле, биш санын без нәрсәләр турында сөйләшкәндә искә төшердек. Нәрсә бишәү? Әйе, бер кулда бармаклар. Димәк, табышмак нәрсә турында ?

(Бармаклар)

Берәү сөйли,
икәү тыңлый,
икесе карап тора.

(Тел, колаклар, күзләр)

— Акыллым, табышмакның җавабын таба алмасаң, әйдә икәүләп уйлыйк: без нәрсә ярдәмендә сөйләшәбез? Әйе, авыз, тел ярдәмендә. Нәрсә ярдәмендә тыңлыйбыз? Алар ничәү? Әйе, шул колаклар. Ә карар өчен, күрер өчен нәрсәләр кирәк? Әйе, күзләр. Димәк, табышмакның җавабы — тел, колаклар, күзләр.

— Ә хәзер бергәләп кабатлыйк: минем бер башым, бер муеным, ике күзем, бер борыным, бер авызым, бер телем, ап-ак тешләрем, алсу битләрем, ике кулым, ике терсәгем, ун бармагым, ике аягым бар.

— Нәни дустым, ә хәзер минем табышмагымның җавабын эзләп кара әле: алар сәламәт, матур булсын өчен нишләргә кирәк?

— ..., ...

— Ай, афәрин! Әйе, чиста тотырга, юынырга, вакытында ашарга-эчәргә онытмаска кирәк. Өченче тукталыштыбыз сәламәтлек (режим) дөньясына булыр. Әйдә әле, бергәләп шул турыда язылган шигырьләрне тыңлап китик. Син әзерме? Яхшы.

Чисталык сөябез

Иртә белән торабыз,
Битебезне юабыз.
Сабын белән юынгач,
Бигрәк матур булабыз.

Муеныбызны юабыз,
Тешләрне чистартабыз.
Пөхтәлекне, чисталыкны
Һәрвакыт яратабыз.

Аш алдыннан һәрвакыт
Кулыбызны юабыз.
Ап-ак итеп кулны юып,
Ашарга утырабыз.

Аякларны кичкырын
Сабын белән юабыз.
Юынырга яратабыз, –
Без бик чиста торабыз.

Әхмәт Ерикәй

— Акыллым, ә син кайчан юынасың? Юынырга яратасыңмы? Нәрсә белән юынасың?

— ... .

— Сабын беләнмени? Мөгаен, шагыйрь абыең язган исле сабын беләндер әле. Шигырь үзе дә исле сабын дип атала. Тыңлап китик.

Исле сабын

Иртә белән торам да
Бик әйбәтләп юынам.
Ап-ак булып күперә
Исле сабын кулымда.

Мондый яхшы сабынны
Кемнәр ясыйлар икән?
Исле сабын ясаучылар
Кайда яшиләр икән?

Моңа җавап кайтара
Әнием шулай менә:
— Сабын ясаучы апаң
Яши күршедә генә.

Ул ясаган сабыннар
Тәмле хуш ис тарата,
Шуңа күрә дә аны
Кешеләр бик ярата.

Әнәс Кари

— Үскәнем, чисталыкны кешеләр генә түгел, хайваннар да, җәнлекләр дә, кош-кортлар да, табигать үзе дә бик ярата. Синең песиең бармы? Булса, күзәткәнең бардыр, ул ничек тырышып юына. Ә кошларның ничек юынганнарын күргәнең юкмы? Булмаса, урамга йөрергә чыккач, тирә-якны игътибар белән күзәт әле, яме. Әлегә шигырь тыңлап карыйк.

Чисталык яратабыз

Су буенда, ком өстендә
Уйныйбыз төрле уен.
Уйнап туйгач, чүп-чарлардан
Чистартабыз яр буен.
Дулкыннар да чүпне судан
Күтәреп ярга ата.
Димәк, алар да, безнең күк,
Чисталыкны ярата.

Мәрзия Фәйзуллина

— Үскәнем, күр әле, нинди акыллы балалар, нинди игелекле эш башкаралар. Әле бит аларга булышучы да бар? Нәрсә соң ул?

— ... .

— Бик дөрес аңлагансыз шигырьне. Әйе, дулкын. Ә менә юынырга яратмаганнар белән нәрсә була икән? Шул турыда кечкенә генә хикәя тыңлап китикме? Әйдәгез.

Юынмый торган балык

Яшәгән, ди, бер Балык. Юынырга бер дә яратмаган икән ул. Юынмагач, бите дә каралган, муены да каралган, койрыгы да каралган. Әнисе юындыра

башласа, кычкырып елый икән бу. Имеш, әле күзенә сабын керә, әле борынына су керә! Шулай итеп, бер дә юынмыйча йөри, ди. Ашар алдыннан, канатларын юмаган, йоклар алдыннан, койрыгын юымаган. Танырлыгы да калмагач, Балык адашкан. Ә адашкан, танырлыгы да калмаган Балыкның кемнеке икәнен кем белсен? Шулай итеп, юынырга яратмаган балык бөтенләй югалган.

Әхәт Гаффар

— Менә шундый күңелсез бер вакыйга, үскәнем. Бу күңелсезлеккә кем гаепле булуын аңладыңмы?

— ... .

— Әйе, балык үзе.

— Нәни дустым, сәламәт булу, тиз үсү өчен вакытында йоклау бик кирәк икәнлеген син беләсеңдер инде, шулай бит? Ә менә шуны белмәгән бер бала белән булган хәлне тыңлап китәсең киләме синең? Килсә, әйдә тыңлыйк әле.

Йокы бабай

Йокларга яратмый торган бер бала булган, ди. Кичен караңгы төшкәч, әннәсе яки әттәсе, бабакае яки әбекәе аны караватка утыртуга, теге бала:

— Мин ятмыйм! Мендәр бә-әк! Йокы бә-әк! Бә-әк! — дип акыра-бакыра елый башлый икән.

Ә бер кичне аның бу ямьсез сүзләрен ап-ак сакаллы Йокы бабай үзе ишетеп торган һәм, бии-ик тә үпкәләгән, тиз-тиз китеп барган.

Төн җиткән, ә берәү дә йоклый алмый икән. Мәчеләр мырылдаган. Кетәктәге әтәч-тавыклар, ишегалдына чыгып, арлы-бирле йөгерешә башлаган. Сарайдагы сыерлар өзлексез мөгрәгән, ә атлар тибенә-тибенә кешнәгән. Дуңгызларның мыркылдавына хәтта трактор да чыдап тора алмаган: “Тыр-тыр-р-р...” – дип тыр-пыр килгән.

Йоклый алмый интеккән кешеләр, колак тондыргыч әлеге шау-шудан котылыр өчен, башларын мендәр астына тыкканнар. Моны күреп, теге бала да, үзенең йомшак мамык мендәрен кочаклап:

— Нәнәм... Йокы нәнәм... Нәннә! — дип әйтүен дә сизми калган.

Йокы бабай аның бу акыллы сүзләрен шундук ишетеп алган һәм тылсымлы таягын бер селтәп куюга, барча балалар, ә аннан соң эти-әниләр, әби-бабайлар, кош-кортлар һәм хайваннар иртәгесе көнгә кадәр тәмле йокыга чумганнар, ди.

Җәвад Тәрҗеман

Үзенә охшаган

Айсылу аптырады:
Җыр да җырлап карады,
Сөйләде әкият тә,
Биеп күрсәтте хәтта!
Айсылу аптырады...
Бармак янап карады,
«Конфет бирмим бүтән», дип
Ачуланып карады...
Юк, курчагы тыңламый —
Йокламый да йокламый!
...Охшаса охшар икән
Айсылуга шулчаклы:
Айсылу йокламыйча,
Йокламады курчагы.

Ләбиб Лерон

— Димәк, нәни дустым, вакытында йокларга, вакытында торырга кирәк. Шулай булганда, күңелсезлекләр дә килеп чыкмас.

— Әйдә әле, тагын шигырьләр тыңлап китик. Алар нәрсә әдәбе турында икән.

— Утыр, бәбкәм, ашарга.
Түгеп-чәчеп ашама.
Тәти утыр табында,
Алдыңда күл ясама:
Ипи валчыгың койма,
Аяк астына ташлама.
Карга боткасы түгел бу,
Аягүрә ашама!

Халык авыз иҗатыннан

Аның өчен, оялам

Тәһир ботка ашаса,
Бөтен бите буяла.
Карап-карап торам да,
Аның өчен оялам.
Аннан шулай уйланам:

Әллә авызы кыекмы,
Әллә ботка сыекмы?
Әллә ашыймы ашыгып,
Тишелгәнме кашыгы?!
Ни булса да булгандыр,
Бер үк маэмай килмәсен,
Таһир битен күрмәсен.
Йә тотыныр яларга,
Барыбер ич аңарга.

Зәкия Туфайлова

Ботка

Ләлә ботка ашамый —
Ботка аңа ошамый.
Әллә майсыз булганмы?
Өстәл җайсыз булганмы?
Боткага май өстиләр,
Аша диеп кыстыйлар.
Ләлә һаман ашамый —
Инде кашык ошамый.
Агач кашык бирәләр,
Тимер кашык бирәләр,
Көмеш кашык бирәләр,
Алтын кашык бирәләр —
Ошамагач ошамый,
Ләлә барыбер ашамый.
Алайса, ярый, диләр,
Табыйк бер дару, диләр.
— Кызым, — диде әнисе, —
Әйдә кызык итәбез,
Хәзер синең бүлмәңне
Җыештырыйк икәү без.

Күнде Ләлә, тырышты —
Әнисенә булышты:
Керләр юып элеште,
Гөлләргә су сибеште,

Мендәрләрне өеште,
Идәннәрне юышты.

Шулардан соң эш бетте,
Ашыйсы килеп китте.
Ботканымы? Ботканы
Ялт иттерде ул аны!

Мәхмүт Газизов

— Үскәнем, сиңа шигырьләр ошадымы? Ә син ботка яратасыңмы? Өстәл артында ничек утырасың?

— ... .

— Әйе, үсәр өчен ботка ашарга кирәк. Ботка ашаганда алдыңа гына карап ашарга, ашыкмаска, түкмәскә, чәчмәскә кирәк. Әйдә әле, бергәләп нишләргә һәм нишләмәскә кирәкне кабатлап чыгыйк: алдыңа гына карап ашарга, ашыкмаска, түкмәскә, чәчмәскә кирәк.

Ә менә Ләлә ничек ботка ашарга булган соң?

— ... .

— Әйе шул, әнисенә булышкан, эшләгәч, ашыйсы да килгән. Димәк өйдә эти-әниеңә булышсаң, ризык та тәмлерәк була, андый баланы яхшы бала, акыллы бала диләр. Алдагы тукталышыбыз — яхшы гадәтләр дөньясы, бик кызыклы, бай дөнья ул.

Ике “мин”

Миндә яши ике “мин” —
Икесе дә бергә тиң.
Аерма тик шунда:
Берсе йөри гел уңда,
Икенчесе — гел сулда.
Уңдагысы гел уңай,
Ул акыллы “мин” бугай.
Сулдагысы — тискәре,
Кулында буш биштәре.
Нигәдер ул гел ипсез,
Кире, ялкау, тәртипсез.
“Мин” дә “мин” килеп йөри,
Дустыннан көлеп йөри.

Укый “ике”гә, “өч”кә —
Ул өстерәлә көчкә...
Кечеләрне елата,
Рогаткасыннан ата.
Әни сүзен санламый,
Әбинекен аңламый.
Бүген дә шелтә тигән —
Курка бары әтидән.
Уңае бик тыңлаучан,
Бар нәрсәне уйлаучан.
Ярты сүздән үк аңлый.
Укый гел “биш”кә генә,
“Биш”лене ишкән генә!..
Арлы-бирле йөгерә,
Барысына өлгерә.
Һәрчак рәхмәт ишетә —
Көн дә шулай кич җитә...
Тискәре “мин” берчакны
Уңай туганга бакты.
Утырып кичтән генә,
Уйлады эчтән генә:
“Аны һаман мактыйлар,
Җил-яңгырдан саклыйлар...
Һәркем аны ярата...
Ул бит барлык кешене дә
Авызына карата...”
Әйтте шушы сүзләрне.
Бер көннән ул үзгәрде.
“Уңай” белән дуслашты –
Теләге чынга ашты:
Аны да гел мактыйлар,
Саклыйлар һәм яклыйлар.
Һәркем сөя аны да,
Хөрмәт итә бары да...
... Миндә яши тик бер “мин” —
Нәрсә булган соң, белмим?..
Берсе кая югалган?..

Сүземдә юк бер ялган —
Уңай гына минем “мин”,
Начар якны җиңдем мин!..

Ленар Шәех

Дустым, ничек уйлыйсың, бер кешедә ике “мин” яши аламы? Синдә уңай “мин” күбрәкме әллә тискәреме? Уңай мин күбрәк булсын өчен нишләргә кирәк?

Һәрвакыт тәртипле һәм башкалар хөрмәт итә торган бала бул!

Үземнән көлгәнмен

Иң беренче мин киендем,
Чыккан чакта уйнарага.
Кинәт көлеп җибәрделәр,
Белмим, ни дип уйларга?
Бар да көлгәч, мин дә көлдем,
Яшь чыкканчы күземнән.
Кемдер шунда әйтеп куйды:
“Көләсең бит үзеңнән!…”
Күр инде син, бүрегемнең,
Алдын артка кигәнмен!
Кеше көлә диеп көлеп,
Мин үземннән көлгәнмен.

Хәкимҗан Халиков

Ник кирәк?

Ике күзем бар минем
Барын да күрер өчен,
Аякларым туктаусыз,
Тып-тып йөгерер өчен.
Ә ике кул ник кирәк
Беләсезме ни өчен:
Әти белән әнием,
Җитәкләп йөрсен өчен.

Хәкимҗан Халиков

Ат яратучы малай

Поездга да утырганым бар...
Ә мин атны яратам!
Атта рәхәт! Кая телим —
Тезгенне генә тартам!
Поездлар баралар алар
Бер салган эздән генә...
Аннан дөньяны күрәсең
фәкать тәрәзәдән генә.
Атта
телим — кырга чыгам,
телим тауларга менәм!
Иреклекне тою рәхәт,
Куышып җилләр белән!

Равил Фәйзуллин

Дустым, ә син нәрсә яратасың? Нинди транспорт төренә өстенлек бирәсең? Атта йөрүнең уңай якларын санап кит.

Ике

Ике аягы Әнвәрнең,
Ике кулы.
Берсе кече, берсе олы
Ике тубы.
Ике колагы бар тагын,
Ике күзе.
Һич теленнән төшми торган
Ике сүзе:
— Әни, әти! —
Бар белгәне ике булды.
Аның үзенә дә инде
Ике тулды.

Сажидә Сөләйманова

Туган илнең улы мин

Бабайның да
Улы мин,

Әбинең дә
Улы мин,
Әтинең дә
Улы мин,
Әнинең дә
Улы мин,
Аларның уң кулы мин.
Бабай кебек
Булырмын,
Әби кебек
Булырмын,
Әти кебек
Булырмын,
Әни кебек
Булырмын,
Бернигә дә карамый.
Шулай булмый
Ярамый —
Соң бит инде
Олы мин,
Туган илнең
Улы мин!

Роберт Миңнуллин

Безнең бабай

Исем китә: безнең бабай
Җитмеш төрле һөнәр белә.
— Каян болай, ничек алай?
Дисәң әгәр, көлә генә.
— Без, оланнар, яшь чагында
Тырай тибеп йөрмәдек, — ди,
Әти нәрсә кушса, шуны
Иренмичә эшләдек, — ди.

Мөнир Мазунов

Бабай балаларга оланнар дип мөрәҗәгать итә. Шулай итеп хөрмәтләп һәм зурлап эндәшә. Ә син ничә төрле һөнәр беләсең, олан? Санап кара.

Тырай тибү вакытны бушка уздыру дигәнне аңлата. Вакыт ул чикләнгән ресурс. Вакытны юкка сарыф итәргә ярамый. Исеңнән чыгарма!

Алдагы шигырь дә шул турыда.

Иртәнге кояш

Иртәнге кояш
Нурларын чәчә.
«Иртәрәк уян,
Кызым Зилә, ди,
Йоклап ятуны
Кем дә белә, ди.
Битемнән сөеп,
Миңа эндәшә:
Карап көчеңә,
Тотын эшеңә.
Хезмәт батырлык
Өсти кешегә».

Зәкия Туфайлова

Мин бүген...

Сары,
Сары, сап-сары
Күк тавык чебиләре...
— Үлән йлокып, — диде әни, —
Кулларым чебиләде!...
Соры,
Соры, соп-соры
Бабайның куяннары...
Бүген урманга барганда,
Энем бик куянланды...
Кара,
Кара, кап-кара
Әбинең кәҗәләре...
— Өстенә ки, салкын! — дигәч,
Сеңлем нык кәҗәләнде...
Ап-ак,
Ап-ак, ак кына
Дустымның песиләре...

Бүген туган көне булгач,
Абыем песиләнде....
Мин генә берни кылмадым,
Мин бүген ... кешеләндем!

Ленар Шәех

Ә син бүген кемгә яки нәрсәгә охшадың? Ничек уйлыйсың, кешеләр хайваннарга охшый аламы?

Ничек яхшы булырга?

Аны сезгә әйтә алам:
уйла син, күреп тора, дип,
һәр адымыңны анам;
йә булмаса, класстагы
матур күзле кыз бала...
Шуннан инде нишлисең?
Билгеле инде нишлисе –
гел яхшы эш эшлисең!
Ә эш эшләгән кеше –
була иң яхшы кеше!

Равил Фәйзуллин

Синең өчен

— Нилектән, йөгерек чишмәкәй,
Шифалы көмеш суың?
— Туган җирнең куеныннан
Башлана минем юлым.
— Нилектән җиләк-җимешең
Авызда эри, урман?
— Туган җирдә үскән алар,
Шунлыктан татлы булган.
— Нилектән болын-кырларда
Күңелгә шатлык алам?
Туган җирнең бар ямьнәре
Тик синең өчен, балам!

Сания Әхмәтҗанова

Куян, кәбестә һәм син.

Синең бабаң бик бәләкәй
Малай булган вакытта
Төшеп киткән чүлмәктәге
Чөгендерле катыкка.
Уф! Юк, тукта!..
Бабакаең бик бәләкәй
Бәби булган чагында
Урам буйлап, гармун уйнап,
Шуып йөргән чаңгыда.
Чынындамы?
Ә чынында
Алай булмаган инде.
Туганда ук гармун уйный
Белеп тумаган инде.
Елак-мылак малай булган,
Сөт эчәргә яраткан,
Мәми сорап, бишегендә
Кычкырып елап яткан.
Ашый торгач, йоклый торгач,
Өч яшен дә тутырган.
Өч яшь тулгач, бишегеннән
Сикереп төшеп утырган.
«Өйдә ятып ардым инде,
Все, булды, җитәр! — дигән. —
Иртәгәдән әти белән
Мин эшкә китәм», — дигән.
Бу сүзләргә бөтенесе
Аптырап беткәннәр, ди.
Уйлый торгач бабаеңны
Садикка илткәннәр, ди.
«Шушында гына эшләп тор,
Бала караш, дигәннәр.
Уйнап йөрү, ботка ашау —
Бик авыр эш» дигәннәр.
Ризалашкан инде бабаң,
Ялындырып тормаган.

Тырышып ботка ашаган,
Бик тырышып уйнаган.
Иртән китереп куйганнар,
Кич килеп алганнар, ди.
Бабаң бакчага киткәндә
Елашып калганнар, ди,
Өстәлендә карандашлар,
Идәндә уенчыклар.
Тэдди-Аю алпан-тилпән
Хәтта озата чыккан.
«Балалар бакчасы» дигән
Эштә эшләгән бабаң.
Анда эшләгән өчен ул
Күп итеп акча алган.
Шул акчага кибетләрдән
Туңдырма ала икән.
Туңдырмасының яртысын
Кесәгә сала икән.
Кесәгә кергәч туңдырма,
Әлбәттә, җеби икән.
«Туңдырмам кая?!» — дип бабаң
Үкереп җылый икән.
Әтисе дә ачуланмый,
Әнисе дә тиргәми,
Өф-өф итеп әбисе дә
Йөри икән тирәли.
Шулай күңелле яшәгән
Малай чакта бабаең.
Әле дә шулай рәхәт кенә
Яшәр иде мөгаен.
Туңдырманы һәм ботканы
Күберәк ашаган шул,
Бакча киемнәренә дә
Сыялмый башлаган шул.
Бабаеңа тәти матур
Галстук кидергәннәр,
Укучы булдың инде, дип,

Мәктәпкә китергәннәр.
«Человек-паук» ясалган
Сумка сатып алганнар,
Шул биштәргә карандашлар
Һәм дәфтәрләр салганнар.
Тырышып укыган бабаң,
Алгалаган «бишле»ләр,
Сирәк-мирәк ялгыш кына
«Икеле»ләр, «өчле»ләр.
«Икеле» алган көннәрдә
Кайткан ул башын иеп,
«Бишле» алган чакларында
Йөргән тыпырдап биеп.
Өйрәнгән китап укырга,
Язарга да өйрәнгән.
Бабакаең турында соң
Тагын ниләр сөйләргә?!
Әбиеңме? Ә әбиең
Шундый матур булган, ди.
Сокланып карап туймаслык
Чибәр булып туган, ди.
Дөресрәге, аны монда
Куян китереп куйган, ди.
Ул куянмы – йомшак куян
Карурманда яшәгән.
Кәбестә алырга диеп
Килгән булган шәһәргә.
Базар буйлап, кәрҗин болгап,
Сикереп йөргән, диләр,
Һәм кәбестәләр тезелгән
Киштәне күргән, диләр.
Сикерә-сикерә шунда киткән,
Тиз генә килеп җиткән.
Кәбестәләр шундый тәмле —
Кетердәп тора икән!
Киштәләрнең иң түреннән,
Иң биектән, иң өстән

Һоп! Куянның кәрҗиненә
Кәбестә килеп төшкән!
Куркак куян гажәпләнеп
Хәтта сызгырып куйган.
Кәбестә дип уйлаганы
Бик матур бер кыз булган.
Шуннан соңмы?
Шуннан соң шул:
Озак уйлагач куян
Кәрҗиндәге ул бәбине
Безгә китереп куйган.
Китергән дә үзе кире
Базарга китеп барган.
Һәм бу юлы бик күп итеп
Кишерләр сатып алган.
Һаман әле урман буйлап
Кишер ашап йөри, ди.
Базардагы хикмәтләрне
Бар җәнлеккә сөйли, ди.
Ә синең әби-бәбиең,
Әй лә! — бәби-әбиең
Ул да яратып яшаган
Кишер дигән мәмине.
Шуңа күрә зур үскән ул
Чибәр-матур кыз булып.
«Ардым инде, эшләмим», дип,
Тормаган һич утырып.
Уенчыкларын да җыйган,
Тузаннарны да сөрткән,
Һәр күлмәге кесәсендә
Чиста кулъяулык йөрткән.
Иртән торгач теш чистарткан,
Битләрен юып куйган.
Йоклаган урын-җирен дә
Пөхтәләп җыеп куйган.
Телефонда уен уйнап
Утырмаган бөтенләй.

Ул вакытта телефонда
Булмаган ди бит инде.
Интернеты да булмаган,
«Вай-фае» да булмаган.
Һәр бүлмәнең диварында
Телевизор тормаган.
Әтәчләр «кикрикүк» дип
Йокыдан уятканнар.
Уянмасаң, «йокычы» дип
Үчекләп оялтканнар.
Кет-кет килеп тавыклар да
Хәтта көлеп калганнар.
Шуңа иртүк зарядкага
Уянганнар балалар.
Ә телефон уеннарын
Уйныйсы килгән чакта
Әбекәең җыенган да
Китапханәгә чапкан.
Төрле-төрле матур-матур
Китаплар ала икән,
Китапханәче елмаеп,
Сөенеп кала икән.
Әтисе дә китап укый,
Китап укый әни дә.
Аларга ияреп көн дә
Укыган ди әби дә.
Табалмассың беркайда да
Укымаган кешене!
Укый икән хәтта куян,
Читкә куеп кишерен.
Беренче сентябрь җиткәч,
Әби киткән мәктәпкә,
Күп укыгач, отличница
Булган инде, әлбәттә.
Бакчада солы боткасы
Ашаган чакта микән,
Мәктәптә Тукай шигырен

Ятлаган чакта микән —
Кайчандыр бер дуслашканнар
Әбиең белән бабаң.
Бабакаең әбиеңне
Шундук җитәкләп алган.
Дус булганнар, бергә-бергә
Уйнаганнар, көлгәннәр.
Һәм берзаман икесе дә
Бер карарга килгәннәр:
Карурманда кишер ашап
Йөргән теге куянны,
Базардан кәбестә сайлый
Белгән теге куянны
«Безгә онык алып кайтчы», — диеп,
Җибәргәннәр базарга.
Күп итеп акча биргәннәр,
Алмасын дип арзанга.
«Иң матурын, иң батырын
Сайлап ал, дип, оныкның,
Бәйләдек дип аның өчен
Иң җылысын оекның,
Тектек диеп аның өчен
Иң тәтиен башлыкның,
Сайладык дип аның өчен
Иң зурысын кашыкның» –
Аңлатканнар ди куянга.
Киткән куян ашыкмый.
Бара торгач барып җиткән
Кәбестә базарына
Соңга кала язган ди ул,
Өлгергән аздан гына.
Кәбестәләр арасында
Әрле-бирле йөренгән.
Йөри торгач, киштәдә бер
Матур бәби күренгән.
Ул шундый да тәти булган,
Шундый да матур булган!

Куянкайның кәрҗиненә
Үзе кереп утырган.
Куян сикерә-сикерә
Алып кайткан бәбине.
Сөендергән ди бабайны,
Куандырган әбине.
Әби белән бабай аңа
Күп итеп кишер биргән,
Кишер ашый-ашый куян
Урманына йөгергән.
Әбиең белән бабаең
Бәбине яратканнар,
Мамык юрганнарга төреп,
Иркәләп йоклатканнар.
Ел үсәсен ай үскән ул,
Көн үскән ай үсәсен,
Кояшкаем, күз нуркаем,
Ул син булган икәнсең!
Йокла, балам, йоклый хәтта
Урманда теге куян.
Тәмле төшләр күреп йокла,
Күзеңә йокы кунган.
Шушы урында әлегә
Китапны ябып куям.
Китапны да, йокласын дип,
Өстәлгә алып куям.

Лилия Гыйбадуллина

Кем тизрәк үскән?

Матур, кояшлы яз. Кечкенә Фәритнең әтисе — бакчачы. Ул бакчасына помидор, кыяр, шалкан, кәбестә һәм тагын әллә нинди яшелчәләр утырта. Менә кәбестә үсентеләре. Әтисе аларны рәт-рәт итеп утыр- тып бара, әнисе аңа ярдәм итә, Фәрит кечкенә чиләк белән кәбестә утыртасы чокырларга су сибә. Әтисе моңа бик шат.

Алар кәбестәне кичке якта утырталар — кояш көйдереп алмасын үзләрен.

Эшләрен бетергәч, күтәрелеп карасалар, кәбестә үсентеләре матур булып, рәт-рәт тезелеп утыра! Аларның үсәселәре килә.

Әнисе шунда:

— Улым, кем тизрәк үсәр икән: синме, әллә кәбестәләрме? — дип шаярта. Фәритнең дә, тиздән үсеп, әтисе кебек бакчачы булырга теләвен белә ул. Фәрит, әти-әнисенә карап:

— Кәбестә, — дип елмая.

— Көз килер, күрербез диген, улым, — ди әтисе. — Алдан кычкырган күкенең башы авырта, ди халык.

Фәрит кәбестәләргә көн дә су сибә. Көндез кәбестәләр кояшка елмаеп карыйлар, һаман кояш нурларына сузылалар. Кояш аларны алтын нурлары белән иркәли.

Кайчак болытлар да Фәриткә ярдәмгә килә, кәбестәләрне шифалы тамчылары белән сыйлый. Яңгырдан соң көн тагын да ямьләнә, үсентеләр дә яшелләнеп, матураеп китә.

Көн артыннан көн үтә, көз килеп җитә. Кәбестәләр баш кадәрле булып үскән. Кул белән кыскаласаң шыгырдап торалар. Үзләре катлы-катлы, сусыл, тәмле. Аларга күзләр, борын, авыз ясап куйсаң, «Без инде үсеп җиттек!» — дияр кебек.

Әти-әнисе белән бергә Фәрит тә шатлана.

Әнисе, кәбестә үсентеләрен утырткандагы сүзләрне искә төшереп:

— Улым, йә, кем тизрәк үскән? — дип елмая.

Фәрит зур булып үскән кәбестәләрне күтәрергә тырышып карый да: — Кәбестәләр! — ди.

Аннан соң, җәй буе аларга су сибә- сибә, үзенең дә буйга сузылганын, күлмәк җиңнәренең кыскарып калганын күреп:

— Мин дә! — дип өсти.

Нәкыйп Каштан

Беренче мәртәбә мәктәпкә бару

Ибраһим, иртәнге чәйне ашыгып-ашыгып эчеп, дога кыйлды да иң элекке мәртәбә мәктәпкә барырга җыена башлады.

Мәктәп һәм анда уку тугърысында Ибраһим төрле сүзләр ишеткәнгә, анда ничек барырмын, ничек ят балалар берлә бергә укырмын дип, анда барудан күңеле тартына иде.

Шулай да аны атасы, кулыннан җитәкләп, өйдән алып чыкты. Ерак түгел генә бер мәсҗед янына җиткәч, атасы Ибраһимга мөгаллимгә ни өчен

килгәнлеген, ничек итеп сөйләргә кирәклеген өйрәтеп, аны мәктәп ишегеннән кертеп җибәрде.

Ул вакыт иртә булып, сәгать сигезне дә сукмаган иде әле. Мөгаллим дә килмәгән иде. Иртә булса да, балалар, җыелышып, шаулашып, мөгаллим килүен көтә иделәр.

Ибраһим ишектән килеп кергәч тә, аның һәр дүрт ягын мәктәп балалары сырып алдылар. Аны һәр яктан баштанаяк карый һәм кем угылы вә ни атлы икәнлеген сораштыра башладылар. Ибраһим исә, алардан оялганлыктан, кып-кызыл булып кызарып, идән уртасында басып тора иде.

Шулай торганда, ишектән мөгаллим әфәнде килеп керде дә, балалар җирле җирләренә утырыштылар. Утырырга махсус урыны булмаганга, Ибраһим, нишләргә дә белмичә, аягүрә калды.

Мөгаллим әфәнде кара мыеклы, кара сакаллы, түгәрәк ак йөзле, көләч кенә, мөлаем генә бер кеше иде.

Ул үзен ят җирдә сизеп, йөзенә аптырау галәмәтләре чыккан Ибраһимны шәфкатьле һәм җылы сүзләр белән үз янына чакырып алды. Ибраһим да үзен атасы укырга җибәргәнлеген вә кем баласы икәнен сөйләде.

Мөгаллим әфәнде Ибраһимны дәфтәргә кайд иткәч кулыннан тотып, сыйныфка алып чыгып, махсус көрсигә утыртты.

Ушбу көннән башлап Ибраһим, «урам баласы»лыктан чыгып, мәктәп шәкерте булып китте. Баштарак шәкертләрдән оялса да, кызарса да, соңга таба ияләшеп, кыюланып китеп, бик тырышып сабак укырга башлады.

Габдулла Тукай

Дустым, син мәктәпкә бардыңмы? Әлә җыенасыңмы? Беренче укытучыңны хәтерлисеңме? Ул көнне нинди хисләр кичердең?

Сара мәктәпкә бара

— Карасана, кара, Сара укырга бара!..

Әлеге яңалык иң әүвәле нәни оныклары белән ишегалдына чыккан әбиләрне, гәп сатып утырган апаларны хәйранга калдырды: «Күрче, зинһар, кай арада үсеп җиткән диген син аны!»

Ә инде Сара үзе күренгәч, комлы әржә эчендә уйнап утырган бала-чагалар да гажәпләнүдән авызларын ачып тынып калдылар.

Ул иртәдә Сара, чыннан да, карап туймаслык иде. Өстендә күз явын алырлык ак алъяпкыч, аякларында сыек саргылт төстәге өр-яңа сандаллар.

Чәчләренә күк йөзе кебек җете зәңгәр «күбәләк» кунган. Янында кулына чәчәк бәйләме тоткан әнисе белән әтисе.

Сара комлы әрҗә эчендә җыелган дус-ишләре янына килмичә булдыра алмады.

— Мин бүтән сезнең белән уйный алмам инде... Мәктәпкә укырга барам...

Көннең икенче яртысында әбиләр, апалар үзләренең оныкларын янә ишегалдына алып чыктылар. Комлы әрҗә тирәсе яңадан бала-чагаларның чыр-чуы, шау-шуы белән тулды. Бу юлы инде дөньяларын онытып мәш килеп уйнаучылар арасында өс-башын алыштырып чыккан Сара да бар иде.

Мәхмүт Хәсәнов

— Дустым, син әле мәктәпкә бардыңмы? Әллә җыенасыңмы? Мәктәп укучысы булу зур җаваплылык ул. Укучы күп вакытын мәктәптә үткәрә. Уенга вакыт бик аз кала. Уку зур тырышлык таләп итә.

Балалар өчен иң матур, иң әһәмиятле бәйрәм ул Белем көнедер. Язучы абый-апаларың нәрсә ди микән? Укып карыйк әле.

Хәтерлим мин, әле бүгенгедәй,
Сентябрьнең бере җиткәнен.
Хәтерлим мин, әле бүгенгедәй,
Көтә-көтә арып беткәнем.
Иң беренче булып килим, диеп,
Өскә матур яңа күлмәк киеп,
Хәтерлим мин, әле бүгенгедәй,
Ашыга-ашыга чыгып киткәнем.
Ләкин миннән бик күп алдан килеп,
Хуш киләсең, әйдә, әйдә, диеп,
Хәтерлим мин, әле бүгенгедәй,
Укытучы апам көткәнен.
Шушы көннән башлап безнең өчен
Кызганмады үзенең бөтен көчен.
Безне сөйде, безгә белем бирде,
Рәхмәт аңа изге эше өчен!

Энҗе Мөэминова

Беренче сентябрь

Көзнең бу бер
Гаҗәп көне,
Әйтерсең лә
Чәчәк көне:
Һәрбер өйдән
Чәчәк чыга,
Урамнарга
Чәчрәп чыга!
Жыела да
Уңнан, сулдан,
Чәчәк елга
Ага юлдан!
Мәктәпләргә
Алар килде,
Бакчаларга
Кайтмас инде…
Язлар җиткәч,
Киләчәктә,
Жимеш бирер
Бу чәчәкләр!

Шәүкәт Галиев

Минем дустым — Әлифба

Мин иртә белән мәктәпкә
барам,
Беренче китап минем
кулымда.
Буран булса да, мин
юлны табам,
Мине өйрәтер дустым
Әлифба.
Шат күңел белән мәктәпкә
керәм,
Сабак укырга, белем
алырга.
Мин хәрефләрне әле аз
беләм,

Мине өйрәтер дустым
Әлифба.
Хәрефләр белгәч, сүзләр
язармын,
Каләмем кулда, дәфтәрем
алда.
Яшә, диярмен, туган
Ватаным,
Мине өйрәтер дустым
Әлифба.
Мин үсә-үсә буйга
җитәрмен,
Бәлки, юлларым китәр
еракка.
Таулар үтәрмен, диңгез
кичәрмен,
Мине өйрәтер дустым
Әлифба.

Нәби Дәүли

Беренче көн

Бүген иртә уяндык,
Көнгә карап куандык.
Их, сикердек, шатландык,
Кош кебек канатландык.
Сентябрьнең бере ич,
Бүген уку көне ич.
Сикерешеп тордык без,
Бит-кулларны юдык без.
Ашап-эчеп киендек,
Шау-гөр килдек, сөендек.
Китап-дәфтәрләр салдык,
Матур сумканы алдык.
Бик күңелле сөйләшеп,
Шаулашып та гөрләшеп,
Иң беренче мәртәбә
Җыйналдык без мәктәпкә.

Мөхәммәт Әхмәтгалиев

Мәктәпкә барасы бар

Туйганчы уйнар идем дә,
Минем шул вакытым тар,
Иртәгә «биш»ле алырга
Мәктәпкә барасы бар.
Әтәчебез сизәр микән —
Бик иртә торасы бар.
Сез дә озак йокламагыз
Мәктәпкә барасы бар.
Киләчәктә туган илдә
Зур юллар саласы бар.
Ә хәзергә, соңламыйча,
Мәктәпкә барасы бар.

Гәрәй Рәхим

Бакча белән хушлашу

Олы бәйрәм бүген бездә,
Зурлар инде күбебез.
Бакча белән хушлашабыз,
Бүген соңгы көнебез.
Тик елыйсы килә минем,
Инде ни хәл итәсе? —
Бакчадан, дуслар яныннан
Бер дә килми китәсе.
Тәрбияче апа елый...
Бу дөнья кызык кына:
Китәсе килми моннан да,
Мәктәп тә кызыктыра!
Күңелле дә, күңелсез дә...
Хәлемне белмиләр шул.
Китмәс идем, зур балалар
Бакчага йөрмиләр шул.
Гел карап торырмын инде
Шушы бакча ягына.
Нигә укытмыйлар икән
Шушы бакчада гына?!
Роберт Миңнуллин

Мәктәпкә!
Чәчәкләр тотып кулга,
Без чыктык матур юлга.
Һәркем белә, әлбәттә,
Без барабыз мәктәпкә!
Безне котлый этиләр:
— Бик дәү үстегез! — диләр.
Өйрәтәләр әниләр:
— Әйбәт булыгыз! — диләр.
Дәү эти, дәү әниләр:
— Хәерле юл, хуш! — диләр.
Бари Рәхмәт
Укытучыларга
Карап тагын сәгатькә,
Җыелдык без мәктәпкә –
Укытучылар белән
Юл алдык киләчәккә.
Белем иленә башлыйбыз
Матур сәяхәтебезне!
Бушка вакыт уздырмаска
Өйрәтәсез сез безне.
Игътибар белән тыңлыйбыз
Дәрестә үзегезне.
Ямьле майдан көзгә кадәр
Мәктәпне сагынабыз.
Менә кабат күрештек без!
Армый-талмый эшләгез, дип,
Саулык тели барчабыз.

Зимфира Исламова

Без чыктык сәяхәткә

Сагынышып җыелдык без
Бүген газиз мәктәпкә.
Кулларны кулга тотынып,
Юл алдык киләчәккә.
Зыялы укытучылар
Янәшәдә – бәхеткә:

Алып чыга алар безне
Кызыклы сәяхәткә.
Белем иле – иксез, чиксез;
Могҗиза белән тулган.
Вакытны буш үткәрмәбез –
Булырбыз уңган, булган!
Диңгезләрдә йөзәрбез дә
Биек тауга менәрбез,
Оксидлардан металл ясап,
Атом төшен җиңәрбез.
Табигатьнең серләренә
Төшенеп тә бетәрбез:
Һаваны, суны, туфракны
Без чистарак итәрбез.
Берни авыр булмас безгә,
Янда булса мөгаллим.
Фән кыяларын кимереп,
Булырбыз әле галим!

Зимфира Исламова

Бүген белем бәйрәме!

Беренче сентябрь безгә
Бәйрәмнең дә бәйрәме.
Һәрберебезнең кулында
Күпме чәчәк бәйләме.
Укытучы апалар да
Елмаеп-көлеп тора.
Шатлыгыбыз эчкә сыймый,
Алар да белеп тора.
Бәйрәм булгач, бәйрәм инде,
«Икеле» дә куймыйлар.
Хәтта өй эшен бирергә,
Орышырга кыймыйлар.
Шаярабыз рәхәтләнеп,
Сөйләшеп туялмыйбыз.
Кызык хәлләр искә төшә,
Авызны җыялмыйбыз.

Беренче сентябрь бүген,
Мәктәп гөр килеп тора.
Һәрберебезнең йөзеннән
Шатлык бөркелеп тора.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов

Хәерле сәгатьтә!

Беренче сентябрь,
Беренче сыйныфка.
Әз генә шүрлим дә,
Күңелле, кызык та.
Беренче тапкыр бит
Мәктәпкә барамын.
Кулыма чәчәкләр
Бәйләме аламын.
Җәй буе көттем мин,
Көткәнсең син дәдер.
Бу Белем бәйрәме –
Беренче сентябрь!

Лилия Гыйбадуллина

Көтәбез!

Мин көтәм, әни көтә.
Авылда – әби көтә.
Абый да көткән кебек,
Тилмереп беткән кебек.
Ашыкмый вакыт кына,
Йөри гәп сатып кына.
Кабаланмый һич кенә –
Ахры, син, ди, кечкенә.
Ашыкмый гына үс, ди,
Әйдәле, бераз түз, ди.
Мәктәп сине көтәр, ди,
Ул көн әле җитәр, ди.
Көтә-көтә арсам да,
Түзми хәл юк, ни эшлим?!
Тик ничек түзә икән

Миңа дигән зур бишлем?
Лилия Фәттахова

Урам буйлап, чәчәк тотып
Урам буйлап китеп барам
Чәчәк тотып, сумка асып.
Янәшәмнән әни атлый,
Шат елмаеп, тек-тек басып.
Очрап тора минем кебек
Матур киенгән балалар.
Әни әйтә: «Мәктәпкә бит
Белем алырга баралар».
Ә ул «белем» дигәннәре
Һәркемгә дә җитәр микән?
Бик кирәкле әйбер дисең,
Без барганчы бетәр микән?
Әни көлә: «Хафаланма.
Барсына да җитә ул, – ди.
Акыллы һәм тырышларны
Кочак җәеп көтә ул», – ди.
Мин мәктәпкә китеп барам
Чәчәк тотып, сумка асып.
Янәшәмнән әни атлый,
Шат елмаеп, тек-тек басып.

Гөлфизә Кәлимуллина

Яшә, көмеш кыңгырау!

Үз итте безне елгалар,
Эшкә дәште басулар.
Ил гизсәк тә, йөрәкләрдә
Басылмады ярсулар.
Чәчәк җыйдык, гөмбә җыйдык,
Ял иткәндә урманда,
Булыштык без абыйларга,
Җәен иген урганда.
Вакыт таптык уенга да,
Яндык кояш нурында.
Тизрәк барып мәктәпләргә,

Сөйлик шулар турында.
Каршы алыр укытучы,
Каршылар классташлар.
Көмеш авазлы кыңгырау
Тәүге дәресне башлар.
Гел елмаер безгә кояш,
Баш тыгып тәрәзәдән.
Китәрбез белем иленә –
Таныш түгел эзләрдән.

Разил Вәлиев

Соңга калма!

Әтәч кычкыра: «Кикрикүк! –
Ишетми калама берүк.
Әгәр ишетми калсаң?
Мәктәпкә соңга калсаң?
Синең өчен кем барыр?
«Дүртле», «бишле» кем алыр?..»
Әтәч кычкыра: «Кикрикүк!
Соңга калма син берүк!»

Резеда Фәрхетдинова

Мәктәптә

- Бу ел укуга барасың, -
Дигәч әни шатландым.
Очраган бөтен кешегә
Шулай диеп мактандым.
Казанга кадәр барып,
Сумка да сатып алдык.
Булган китап-дәфтәрләрне
Шушы сумкага салдык.
Менә бүген басып торам,
Ике кыз арасында.
Оялыплар куям инде
Кайсысы караса да.
Бик кызык икән мәктәптә
Урын күп йөгерергә.
Йокыдан тору бик читен,

Ничекләр өлгерергә?

Миләүшә Хәсәнова

Беренче дәрес

Без бу ел гына
Мәктәпкә килдек.
Аңарчы һаман
Бакчада идек.
Мәктәп өр-яңа,
Анда парталар,
Алар күңелне
Эчкә тарталар.
Кулыбызда безнең
Яңа әлифба.
Менә монсы «а»,
Менә монсы «ба».
Без хәрефләрдән
Сүзләр ясыйбыз,
Шуннан соң җырлап
Укый башлыйбыз:
Ат, ата, арта,
Ат арба тарта.
Ата-аналар
Атта баралар.
Нинди зур бәхет,
Нинди үзгәреш!
Бигрәк күңелле
Беренче дәрес!

Муса Җәлил

Әхмәтнең укыйсы килә

Алты яшь тик әле Әхмәткә
Бик йөрисе килә мәктәпкә.
«Кайчан җиде яшькә җитәм? — ди, —
Тиз-тиз генә үссәм икән»,—ди.
«Улым, ашыкма,— ди әнисе,—
Кечкенә бит, яшь бит әле син.
Бер елдан соң йөри башларсың».

«Ә бер ел ул, әни, кайчан соң?
Иртәгәме? Берсекөнгәме?
Көннәр салкынайгач, көзгәме?
Әйт тә, әйт!» — ди Әхмәт, йә ничек
Җавап бирсен инде әнкәсе?!
«Илдар тәпи йөри башлагач,
Укырсың, — ди, җавап тапмагач, —
Бер ел үтәр, бәбкәм, шулчакта
Озатырмын сине мәктәпкә».
«Илдар! Илдар! Тор инде,
Тизрәк тәпи йөр инде».

Бари Рәхмәт

Бәйрәм

Бүген мин йокыдан
Таң белән уяндым.
Беренче тордым дип,
Әй, шундый куандым.
Карасам, көткәндәй
Кадерле кунагын,
Әнием пешереп
Өлгергән коймагын!
Кояш та елмая,
Гөлем дә, энем дә...
Ә үзем шатлыктан
Җырлыйм да, биим дә.
Бүген бит зур бәйрәм —
Беренче сентябрь!
Хуш, әни! Мин киттем —
Мәктәбем көтәдер.
Дүртлеләр, бишлеләр
Көтәдер үземне...
Ә, энем, син инде
Бер елга түз инде.

Хәкимҗан Халиков

Беренче сентябрь иртәсе

Портфельне тотты әни,

Букетны кочты әби.
Ә энем бигрәк нәни,
Күтәрә алмый берни,
Кулында – кәнфит-мәми.
Алмаш аяк киемле
Янчыкны соң кем алыр?
Әни, әби, энем белән
Мине яңа мәктәпкә
Тагын кем озата барыр?
Шулчак ишек алдында
Тавыш бирде дус маэмай:
“Алып чык, һау, янчыгыңны,
Ташламас сине Акбай!”
Портфельне тотты әни,
Букетны кочты әби,
Акбай янчыкны капты...
Минем дә кул буш түгел –
Ялык-йолык килеп тора
Әти бүләге – смартфон!

Сирень Якупова

Супермалай

Ул — супермалай.

Ул, теләсә, әллә ниләр эшли, әллә нәрсәләр майтара ала...

Теләсә, кибеткә барып, ипи-сөт алып кайта ала.

Чишмәдән «ә» дигәнче су алып кайта ала. Теләсә.

Утын кисә ала.

Елап яткан энесен юата ала. Әгәр теләсә.

Буш вакытында (ә аның буш вакыты күп!) китаплар укый ала. Урындыкны төзәтә ала. Идәнне себерә-юа ала...

Тагын әллә нәрсәләр, әллә ниләр эшли ала...

Әгәр теләсә....

Ләбиб Лерон

— Син супермалай яки суперкыз исеменә лаекмы? Бу исемлекне тагын ничек дәвам итәр идең? Супер эшләрне санап чык.

Буш вакытларыңда нәрсә эшлисең? Супер эшләр исемлеген төзе.

Арыслан белән тычкан

Арыслан тычканга карап: — Тычкан нинди бәхетле! — ди икән.

Арысланны читлеккә япканнар. Ә читлекнең бер почмагында — аста тычкан оясы булган. Тычкан оясыннан башын чыгарып арысланны күзәтә икән:

— Арыслан кебек зур булсам мин читлек астында түгел, читлекнең үзендә яшәр идем, — ди икән. Арыслан исә тычканга карап: — Тычкан нинди бәхетле! Әгәр мин тычкан кебек кечкенә булсам, бу читлектә бер көн дә тормас идем, — ди икән. — Арысланның эше рәхәт аның. Аңа хезмәтчеләре ризыкны алдына ук китереп салалар, ә миңа кышын ачка үлмәс өчен күпме тир түгәргә кирәк, — дип уйлаган тычкан.

Шуннан соң тычкан үсмәкче булган, ә арыслан кечерәергә теләгән. Арыслан алдына куйган бер ризыкны да капмый башлаган, ә тычкан исә аңа дигән ризыкны көне-төне ашарга тотынган. Шулай итә торгач, арыслан тычкан хәтле, тычкан исә арыслан хәтле булган. Тычкан читлек эчендә калган, арыслан качкан.

Хәзер тычканны арыслан дип уйлап, ризыкны аның алдына салганнар. Әмма ул үзенең элекке оясын, иркенләй йөргән чакларын сагынган. Тик читлектән чыга алмаган. Шунда ул арысланның хәлен аңлаган һәм бөтенләй ашамый башлаган. Ач тора торгач, ябыккан һәм элекке хәленә кайткан. Читлектән чыгып, ул да урманга качкан. Ә анда арыслан белән очрашкан. Алар бер-берсен күреп бик сөенгәннәр. Арыслан да әзерне генә ашарга өйрәнеп беткән булган, хуҗасын һәм читлеген, читлектәге ризыкны сагынган. Шуннан кире оясына кайткан, тычканга үз оясы яныннан бер почмак бүлеп биргән.

Тычкан хәзер арыслан булырга кызыкмаган. Тычкан булуның да уңай яклары булуын ул аңлаган. Арыслан да: — Ач булганда ирек бер дә күңелле түгел икән, — дип уйлаган.

Сәмига Сәүбанова

ЯХШЫ ГАДӘТЛӘРЕМ

Үзем үстем
Бәрәңге әрчибез шулай
Әби белән икебез.
Мин – берне,
Әби – икене.
Кичә генә әби миңа:
“Син кечкенә әле”, – диде.
Бүген кызык,
Әби: “Кызым,
Инде зур үскәнсең”, – диде.
Бәрәңге әрчибез ич,
Әби – берне,
Мин – икене.

Ямаш Игәнәй

Аш вакыты
...Тәртипне беләбез:
Кул юып керәбез.
Әйбәтләп кенә без
Ашыйбыз, эчәбез,
Бер сүз дә дәшмибез,
Түкмибез, чәчмибез.
«Апа, бик рәхмәт!» — дип,
Урыннан торабыз,
Авызны чайкыйбыз,
Кулларны юабыз,
Ә урындыкларны
Урынына куябыз.

Бари Рәхмәт

Онытылган...
Укучылар дәфтәрләрен
Парталарга тезеп салган.

— Дәфтәрләрең кайда, Мәсгуть?
— Онытылган... өйдә калган...
Иртәгесен бар балалар
Кулларына китап алган.
— Китапларың кайда, Мәсгуть?
— Онытылган... өйдә калган...
Балаларның һәммәсе дә
Галстуклар бәйләп алган.
— Галстугың кайда, Мәсгуть?
— Онытылган... өйдә калган...
Башкаларның «дүртле», «бишле»,
Мәсгуть тагын «икеле» алган.
— Ник башыңны эшләтмисең?
— Онытылган... өйдә калган...

Шәүкәт Галиев

Физзарядка ясый куян

Кызыл күзен ачуы —
Төпкә менеп басуы!
Бер, ике, өч — утыра,
Бер,ике,өч — ул тора.
Йә ботакка тотынып,
Ала таган атынып.
Алан тулы төп тә төп,
Сикергәли дөп тә дөп...
Кинәт читкә тартыла —
Куян уктай атыла.
Ә-ә, бар икән юлаучы.
Юлаучымы? Юк, аучы!
Аучы куа куянны,
Куян тоя куганны.
Шундый кызу элдерә -
Ничек кенә өлгерә.
Чыныккан шул, ул чыдам.
Котылды бит аучыдан!
...Иртәгесен аучы да
Ишегалдына чыга.

Бер, ике, өч — утыра,
Бер, ике, өч — ул тора.
Йә турникка тотынып
Ала тиз-тиз атынып...
Куян куып туйганмы,
Аучылыкны куйганмы?
Ю-ук.
Физзарядка ясамасаң,
Тотып булмый куянны!

Шәүкәт Галиев

Томау, җиң һәм кулъяулык

Ах, төшкән миңа томау,
Әйбәт түгел томаулау.
Борыннан ага гына!
Сөрткән идем, югыйсә,
Борынны яңа гына.
Үч иткәнедәй, кулъяулык
Нигәдер калган өйдә.
Йөрим менә урамда
Шул томаулаган көйгә...
Борынымны сөртергә
Ярый әле бар җинем.
Юешләтеп бетердем
Ул җиңемнен бар җирен.
Юп-юеш шул, юп-юеш,
Тагын сөртер идем дә.
Борчылмагыз!
Минем әле
Бар икенче җинем дә!

Роберт Миңнуллин

Гигиена таләбе

Хәят уң кулын юды да
Ак сөлгегә үрелде.
Әнисе, кулын юмагач,
Ризасызлык белдерде.

Озак уйламады кызый,
Җавабы булды кыска:
“Бер кулым белән генә ич,
Ашадым, әни, ботка”..
Һичшиксез, дөрес эшләми,
Минемчә, дуслар, Хәят.
Ә сездә ничек куелган
Гигиенага таләп?

Люция Әблиева

Таза булып үсегез

Күзем төшсә, ташландык су
Эчеп ята чебиләр-
Чисталыкны белмиләр.
Кем эчә ди пычрак суны,
Әй чебиләр, юләр сез!
Җитте сезгә-чирләрсез!
Менә сезгә чишмә суы,
Рәхәтләнеп эчегез,
Таза булып үсегез.

Хәкимҗан Халиков

- Ә син нинди гигиена таләпләрен үтисең? Ашарга утырыр алдыннан һәм ашаганнан соң нишләргә кирәк?

Кесә

“Синең кесәң — чүп савыты,
Нәрсә генә юк анда”, —
Диде әни ял көнендә
Чалбарымны юганда.
Сагыз тышы, конфет чүбе,
Автобус билетлары...
“Әллә, — ди әни, — кесәңә
Җеннәр кереп йоклады?”
Ике каләм, тимер ручка,
Машина төшкән кәгазь.
Дүрт-биш шөреп, алты сәдәп...
Әле санадым бик әз...
Әни әйтә: “Ник җыясың,

Нигә кирәк бу чүп-чар?..”
“Минем бит, дәү үсеп җиткәч,
Нәкъ менә әтием кебек,
Шәп кеше буласым бар!..”

Ленар Шәех

Ә хәзер ялкаулар турында сөйләшеп алыйк. Кем ул ялкау? Синең танышларың арасында андый кешеләр юкмы?

Ялкау Әкъдәс

Дәү әтием белми әйтмәс:
Бар иде, ди, ялкау ӘКЪДӘС
Йокы аңа аш иде, ди,
Йокламаса ач иде, ди,
Су эчсә дә тук иде, ди,
Бу авылда юк иде, ди,
Аңардан да ярлы кеше.
Шушы моңлы-зарлы кеше
Асраган, ди, ике сарык,
Берсе ябык, берсе арык
Булган, имеш, алары да.
Берни юк, ди, алларында.
Шулай шактый вакыт узган,
Бер сарыгы аяк сузган,
Икенчесе үлеп киткән,
Әкъдәснең дә эше беткән.
Әкъдәс башта сөенгән, ди,
Аннары бик көенгән, ди,
Хәтта ятып елаган, ди,
Өй салырга уйлаган, ди,
Аннан соң ул ап-ак таштан…
Сөйлимме соң яңабаштан?

Хәкимҗан Халиков

Ялкау

Үрдәк әйтә: “Бак-бак, — ди, —
Бирегез тагарак, — ди. —

Рәхәтләнеп су керим,
Авыз белән су көрим....”
Тавык әйтә: “Кыт-кытак,
Төзегез миңа кетәк.
Күп йомырка салырмын,
Чебиләр чыгарырмын”.
Сыер әйтә: “Му-му, — ди, —
Кертегез печән, су, — ди, —
Күп итеп сөт бирермен,
Ак май ташып йөрермен...”
Марат әйтә: “Карбыз, — ди, —
Бирегез сез сагыз, — ди, —
Тәмле конфет, тәмле су”, —
Нәрсә була инде бу?..
Елый-елый сорый ул,
Бүре кебек улый ул.
Таң калган тавык көлә:
“Бу нәрсә эшли белә?..”
Маэмай әйтә: “Хау-хау, — ди,
Безнең Марат ялкау”, — ди...

Ленар Шәех

Ялкаулык — начар сыйфат. Ялкау булырга ярамый! Тырыш булып, вакытны бушка уздырмыйча яшәргә кирәк. Әйләнә-тирәгә күз сал. Синең ярдәмең кирәк түгелме?

Әниемә булышам

Пөхтә итеп өйне җыям,
Гөлләремә су сибәм.
Курчакларымны йоклатам,
Еласалар, юатам.
Менә ничек тырышам,
Әниемә булышам.
Әнием белән кибеттән
Ипи-сөт алып кайтам.
Борчулы булса әнием,
Тынычлан, дип, юатам.

Менә ничек тырышам,
Әниемә булышам.

Лиана Әмирханова

Булышчы

Әниемә эш күп өйдә —
Мин шуңа да булышам.
Менә әле дә мин аңа
Чынаяклар юышам.
Булышам шул, юышам шул,
Мин бит инде булышчы.
Уф, арыдым! һаман бетми!
Әнием, кил, булышчы!

Роберт Миңнуллин

Җиләк пеште

Җиләк пеште, җиләк пеште
Безнең бакчада!
Күңел рәхәтләнеп китә
Күргән чакларда.
Кирәк түгел бал, шикәрең,
Шулкадәр татлы!
“Нилектән, дим, әби, җиләк
Тәмле бу хәтле?”
“Үстергән, караган чакта
Булыштың миңа.
Татлы булып өлгерделәр
Җиләкләр шуңа”.

Әнәс Кари

Менә бит ничек икән! Эшләгәч җиләкләр дә татлырак тоела икән. Гаиләдә олыларга ярдәм итү үзе күңелле!!! Булышчы дип эндәшәләр сиңа!

Әфлисун һәм алма

Әфлисун агачын күрде,
Хәят диҗгезгә баргач.
Күзендә очкын кабынды:

“Әни, бу би алмагач!”
“Өлгермәгән әфлисун ул
Яшел шуңа җимеше”.
Нәни Хәятка әнисе
Аңлата күренешне.
Сабый күңеле самими,
Үзе кебек, эчкерсез.
Туган якның алмаларын,
Сагынганы берсүзсез...

Люция Әблиева

Алмаз

Бер итеге уңга карый,
Берсе карый сул якка.
Уңын сулга бутап кигәч
Кыендыр ул аякка.
Бияләй — ишле-сыңарлы,
Бүрек каплаган күзен.
Әллә малай, әллә кыз ул —
Танып та булмый үзен.
Танымаса танымаслар,
Алмаз сөенә генә:
Инде бүген икенче көн
Үзе киенә менә.

Җәүдәт Дәрзаман

Атлас

Күлмәге шәп — атластан,
Күз алмыйбыз Атластан. —
Шундый мтур киенгән!
Тик аның ташбашы гына
Никтер түбән иелгән.
Кара инде Атласны,
Укый алмый атласны!..
Казан Америкадан
Кире безгә кайтмасмы?..
Көньяк полюстагы Мәскәү

Үз урынын тапмасмы?..
Ә Берлин белән Будапешт
Океанда батмасмы?..
Кара инде ташбашны,
Һаман акыл сатмакчы!..
Парижны да Африкага
Була алып атмакчы...
Бер карыйбыз Атласка,
Тактагы атласка...
Ничек тә тырыша инде,
Күзәрен иеп аска,
Зур картада батмаска!..

Ленар Шәех

Һәрнәрсәнең үз урыны бар

Габдулла, йокысыннан уянды исә, үзенең кием-салымын аннан-моннан эзләргә тотына.

Аның бер читеге урындык астында, икенче сыңгары өстәл астында ята. Бүреге карават астында ауный, кәләпүше бүлмәдә үк юк.

Габдулла һәр иртә белән шул баш, аяк киемнәрен эзләп маташа да һәр көн сабакка соңга калып килә.

Габдулла Тукай

— Дустым, Габдулла ни өчен көн саен соңга кала? Син әйберләреңне урынына куясыңмы? Киемнәрен кайда тора? Салган киемеңне урынына кую, сумка, китапларны тиешле урынга кую – тәртип дип атала. Тәртипле, җыйнак бул! Киемнәрең пөхтә булсын! Үзең дә юынып чиста йөр! Алайса Батулла бабай шапшакларны бака ялый, ди. Нигә шулай икән? Укыйк әле...

Шапшакларны бака ялый

Мөбарәкша манный боткасы ашап утыра икән. Үзе алакялак карана. Күке кычкырса, сәгатькә карый. Песи мияулап урындыктан сикереп төшсә, Мөбарәкша песигә карый. Абыйсы телевизор кабызса, Мөбарәкша телевизордан күзен алмый.

— Алдыңа гына карап аша, улым! — диде әнисе Мөбарәкшага. — Әнә тагын түшеңә тамызгансың. Эчкән сөтең дә, ашаган боткаң да күлмәгеңә җыела бит.

Мөбарәкша түшенә тамган сөтне, ботканы кулы белән сыпыра. Сыпырган саен, күлмәк карала бара.

— Һи-и, Мөбарәкша улым, — диде әнисе. — Күлмәгеңне пычратып бетергәнсең бит. Әнә түшең каткан. Битең пычранган. Алай ярамый.

— Нигә алай ярамый? — ди Мөбарәкша.

— Түше каткан малайлар, бите шапшаклар янына төнлә бака килә икән. Бака килә икән дә пычранган җирләрне ялый икән. Йоклаганда, синең дә битеңне бака ялап китәр инде.

Мөбарәкша ашап туйгач, әнисе аның өстен алыштырды, чиста күлмәк кигезеп, битен-кулын юдырып, йокларга яткызды. Мөбарәкша, йокламаска тырышып, төн уртасына чаклы бака килгәнне көтте. Күпме генә көтсә дә, аның битен яларга бака килмәде. Белгәндер ул бака, Мөбарәкшаның бите чиста икәнен белгәндер. Шуңа килмәгәндер.

Батулла

Шапшак песи баласы

Песи баласы юынырга яратмаган.

Песи баласы юынырга яратмаган. Әнисе аңа:

— Юынып йөр, чиста булмасаң, сине яратмаслар, уйнау түгел, кулларына да алмаслар, — дигән.

Песи баласы:

— Мине син яраткач, шул җитә, — дип һич кенә дә юынырга теләми, — ди.

Башта песи баласын әнисе үзе юындырган, тик аның түземе беткән һәм:

— Гомер буе әни белән яшәмиләр. Минем яныма юынмаган килеш киләсе булма. Болай шапшак булсаң, хуҗабикә табылмас үзеңә, — дигән.

Песи баласы әнисенә үпкәләп ишегалдына чыккан. Аның тавык-чебешләр белән уйныйсы килгән. Тик тавык чебешләре аның белән уйнамаганнар.

— Фу, шапшак! Әллә чүпрәк итеп идән юдыларmы синең белән? Син безне пычратасың. Читтәрәк йөр, якын килмә! — дигәннәр.

Каз бәбкәләре дә аны якын китермәгәннәр.

— Синең белән уйнамыйбыз, сасы ис килә үзеңнән!

— Абау! Миңа кагылып кына китте, канатым кап-кара булды!

— Әйдәгез, су буена төшеп канатыбызны юабыз! — диешкәннәр.

Ана каз песи баласын әллә кая ук куып алып киткән.

— Йөрмә монда! Әнә, юынмагач, йоның коелып, пеләшләнеп беткәнсең. Шапшаклыгың бәбкәләремә йогып, алар пеләш кала күрмәсен!

Чынлап та, песи баласының ярты йоны коелып бетә язган икән. Моны күргәч. песи баласы акырып еларга тотынган.

— Әни! Минем йомшак мамыгым коелып беткән! — дигән.

— Тиккә юынырга кушмадым бит мин сиңа, — дигән әнисе.

Песи баласы кытыршы теле белән тәнендәге пычракны ялап ала

да төкерә , ялап ала да төкерә, үзе :

— Тьфү! Бигрәк тәмсез икәнмен мин. Бу хәтле ямьсез генә түгел, тәмсез дә булырмын, — дип һич уйламаган идем! — ди икән.

Шулай атна буе үзен чистарткан. Пычрак йоны коелып, аның урынына яңасы үскән. Шундый матур, шундый йомшак песи баласына әверелгән бу. Шуннан соң гел юынып кына тора башлаган. Юыну үзенә дә ошап киткән һәм аны бик матур, бик акыллы бер кыз үзенә алган.

Сәмига Сәүбанова

Ә табын янында үзеңне ничек тотарга кирәк? Безнең бабаларыбызның киңәшләре белән танышыйк.

Табын әдәпләре

Әй угыл, ризыкны уң кулың белән аша. Авызыңны тутырып капма. Вак-вак чәйнәп аша, ашың сеңешлерәк булыр. Табынга ашны китергәч, шунда ук ашарга утыр, көттермә. Ашап бетергәч, өстәлдән ашны алмас борын торып китмә. Күп кеше килгән булып, бер генә кеше килеп җитмәгән булса, бер кеше өчен күп кешене көттермә.

Каюм Насыйри

Ашау әдәпләре

Ашарга утырган вакытыгызда, иң элек кулларыгызны юыгыз вә яхшы сөртегез.

Үзегездән олы кешеләр булганда, өстәл янына алардан элек утырмагыз.

Аш янында берни белән дә уйнамагыз.

Аш янында борыныгызны тартмагыз, чөмереп ашамагыз.

Ризыкны зур-зур алмагыз, ашыкмагыз, яхшы чәйнәгез, кул вә киемнәрегезне буямагыз, башкаларның ашавына карап тормагыз, күп ашарга гадәтләнмәгез, аштан күңелегез кайтканчы туктагыз. Бу нәрсәләрнең сәламәтлек өчен файдасы күп икәнлеген үзегез дә белерсез.

Чәй янында каймак вә майлы ашлар булса, киемнәрегезгә тамызмагыз, кулларыгызны майламагыз, майлы кулларыгызны киемнәрегезгә сөртмәгез.

Аштан соң кул вә авызларыгызны юыгыз, теш арасында бернәрсә калдырмагыз.

Ризаэддин Фәхреддин

Бу кагыйдәләр бүгенге заман табын этикетына туры киләме? Табын артына утырганда син нинди кагыйдәләрне үтисең?

Табын кагыйдәләре

Табында без һәрчак кунак,
Кунак булсаң, тыйнак бул.
Кирәкмәс сүзләр сөйләмә,
Түкмә, чәчмә, җыйнак бул!
Ризыгыңны чәйнәп аша,
Авыз төеп тутырма.
Чапылдатма, күршеләргә
Бәреп-сугып утырма!
Ашаган йөрәккә ятсын,
Яхшырак эшләр башың.
Әйдә, табынга рәхим ит,
Бик тәмле булсын ашың!

Вәсимә Хәйруллина

Оялдык

Ачыгып уеннан кердек,
Өстәлдә ипи күрдек.
Бөтене белән алып,
Тәрәз төбенә салып,
Әй тотындык ашарга.
Төрле яклап өзәбез,
Чеметәбез, изәбез,
Ә үзебез, кызык табып,
Чырык-чырык көләбез.
Шунда кинәт бүлмәгә
Әбием килеп керде.
Әллә ничек моң гына
Ипи янына килде.
— Ач бүреләр шикелле

Ташлангансыз өстенә
Ипекәйне, балалар,
Күр, ничек рәнҗеткәнсез,
Ничек мыскыл иткәнсез,
Бәгырьсез үк икәнсез... —
Диде дә, шелтә белән,
Ипине, ипләп кенә,
Ак ашъяулыкка салды,
Валчыгын чүпләп алды:
— Ипи дигәч ни калды...
Кыен булды безгә бик,
— Әбекәй, — дип, — гафу ит, —
Чүт кенә әйтә алдык,
Шундый да нык оялдык...

Резеда Вәлиева

Минем урын

Уяндым да урынымны җыймадым,
чыгып киттем, озак кына уйнадым.
Кайтып керсәм, үпкәләгән урыным,
идәнгә үк салган мендәр-борынын.
Үпкәләмәс, салмас иде борынын,
үзен үзе җыя алмый урыным,
үпкәсен дә әйтә алмый, сөйләшми,
мин югында и күңелсез дә яши.
Тузып ята чия кызыл юрганым,
ул да миңа бик үпкәли торгандыр.
Бөгәрләнгән ап-ак җәймә, кем белә,
елагандыр, бәлки, миңа үпкәләп.
Үпкәләмә, урынкаем.
...Менә бит —
җыештыргач, ул елмая белә бит!

Рөстәм Мингалим

Кыю малай

Синең чып-чын юлбарысны
Күргәнең юктыр әле,

Каршысында тел күрсәтеп
Йөргәнең юктыр әле!
Азау тешләрен тырпайтып,
Бик каты ырласа да,
Өстемә сикермәк булып,
Койрык болгаса да,
Тамчы да курыкмадым мин!
Ышанмасаң сүземә,
Зоопарк каравылчысының
Барып сора үзеннән!

Резеда Шәрипова

Татар халкы бик җор телле һәм зирәк ул. Аның Хуҗа Насретдин кебек халык герое да бар. Аның мәзкләре белән дә таныш әле. Нинди сабак алырсың?

Беркөнне бер малай Хуҗаның бакчасына алма урларга кергән. Хуҗа малайны тотып алган да, бакчасына рөхсәтсез кергән өчен, җәза бирмәкче булган. Ләкин малайны җәзаларга кызганган. Шуннан соң ул малайга күлмәген салырга кушкан. Күлмәген салдырып алган да агачка элеп куйган. Аннан чыбык алып, малайның күлмәген кыйнарга тотынган. Малай бер читтә көлеп карап тора икән. Үзен кыйнамагач, аңа ни! Аның тәне авыртмый бит. Малайның күлмәгенә берничә тапкыр чыбык белән сыдыргач, Хуҗа күлмәкне малайның үзенә тоттырган.

— Мә, күлмәгеңне кимичә генә кайт. Югыйсә, мин аны бик каты кыйнадым, тәнеңә тидерсәң авыртты¬рыр, — дигән. Малай, бу хәлне бик кызыкка санап, иптәш малайларына сөйләгән. Малайлар шаркылдап көлгәннәр.

— Әйдә, без дә Хуҗа абый бакчасына барабыз, — дигәннәр.

Малайлар Хуҗа бакчасына алма урларга киткәннәр. Алмаларны кесәләренә тутырып кына яталар икән, Хуҗа боларны күреп калган Да, кулына нәзек тал чыбыгы алып, аркаларына чаж-чоҗ сыдырмасынмы!

Малайлар елаша башлаганнар:

— Хуҗа абый, сез бит бер малайның күлмәген генә кыйнап җибәргән идегез.

— Мин сезнең дә күлмәкләрегезне генә кыйнадым ич. Ул малай бер генә иде, ә сез күбәү. Шуңа күрә күлмәкләрегезне салдырырга өлгермәдем, салдырмыйча гына кыйнадым, — дигән Хуҗа.

Бер малай Хуҗаны алдамакчы булган.

— Хуҗа абый, мин кичә зоопаркта бозау хәтле куян күрдем, — дигән.

— Һәй, исең киткән икән, менә бүген анда ат хәтле тиен китерделәр, — дигән Хуҗа.

Малай, Хуҗаның сүзенә ышанып, ат хәтле тиен күрергә зоопаркка йөгергән.

Бер бала:

— Хуҗа абый, мин мәктәптә иң яхшы укучы, иң яхшы җырчы, иң яхшы биюче, — дигән.

— Сезнең мәктәптә бар кешедән уздырган мактанчык кем соң? — дип сорау биргән Хуҗа.

Малай ни әйтергә дә белми кызарган.

— Хуҗа абый, сезнең улыгыз ничәнче класста укый?

— Бишенчедә укый.

— Ә кайчанга кадәр укытмакчы буласыз соң аны?

— Үзем шикелле булыр инде, үзем менә йөзгә җиттем, әле һаман укып туйганым юк.

Дустым, сиңа әлеге хикмәтләр ошадымы?

Аю белән Бабай

(Татар халык әкияте)

Борын заманда Аю белән Бабай яшәгән. Алар икәүләп шалкан чәчкәннәр. Шалкан бик мул булган, уңган.

Бабай Аюдан:

— Син шалканның кай җирен аласың: тамырынмы, яфрагынмы? — дип сораган.

Аю хайваннарның яфракны яратып ашаганнарын күргән дә яфракка кызыккан.

— Мин шалканның яфрагын алам! — дигән һәм яфрагын алган. Бабайга шалканы калган.

Икенче елны Аю белән Бабай бодай чәчкәннәр. Быел инде Бабайдан алдатмам, дип уйлаган Аю.

— Мин быел тамырын алам, ә син сабагын ал! — дигән ул Бабайга.

Бабай бодайны урып алган, ә Аюга камылы калган.

Рөстәм

Беркөн мин улым Рөстәм белән әбиләрдә кунакта булдым.

Самовар, җырлый-җырлый, өстәлгә килеп басты. Самовар артыннан ит сумсалары, алма, карбызлар, конфетлар килеп тулдылар өстәлгә. Алмалары: «Мине ал, мине ал!»; конфетлары: «Кулыңны суз! Ах, тәмле без, ах, тәмле!»; карбызлары:

«Ал-кызыл без! Ал-кызыл! Кап авызыңа, эрербез», — диешә сыман, алдыбызда кызыктырып яталар.

Рөстәм кулын сузарга ашыкмады. Башта миңа карады ул.Аннан әбисенә карады.

Әбисе аның тәлинкәсенә өч сумса салды. Мин бер алма алып бирдем. Апасы аның алдына конфет, бер телем карбыз куйды.

Улым үзен бик әдәпле тотты. Ашыкмый гына ашады, авызын чапылдатмады. Ашъяулыкка карбыз суын агызмады.

Дәржия Аппакова

Ботка нигә тәмле?

Булган, ди, бер кыз. Ул әнисе пешергән рызыкларны ашарга бер дә яратмаган. Кәнфит-прәннек кебек татлыдан-татлыны гына сораган. Әнисе тегеләй әйтеп караган, болай әйтеп караган, кызый:

Моны ашагач эчем авырта! — дип ялганлый икән.

Әнисе аны врачка алып барган. Врач әйткән:

— Сезнең кызыгыз тап-таза, — дигән.

Кыз тагын хәйләгә сабышкан.

— Күзем авырта! — дигән.

Әнисе тагын врачка алып барган. Врач:

— Кызыгызның күзләре сау-сәламәт, — дигән.

Әнисе алдына тагын ашарга куйган. Кыз тәлинкәне эткән дә:

— Колагым авырта! — дип акырып еларга тотынган.

Әнисе аны тагын врачка алып барган. Врач:

— Кызыгыз бик әйбәт ишетә, — дигән.

Шулай булса да әнисе кызына татлыдан-татлы ризык кына ашатырга мәҗбүр булган. Шулай итә торгач, әнисенең ипи алырга да акчасы калмаган. Шуннан әнисе манный боткасы пешереп биргән. Кыз:

— Манный боткасын песнәкләр ашасын! — дип акырып-бакырып еларга тотынган.

Әнисенең ачуы килгән.

— Мин пешергән ризыкларны яратмагач, корт чүпли торган песнәккә әверел! — дигән.

Кыз песнәккә әверелгән, очып киткән, песнәкләр көтүенә кушылган. Тик ул чын песнәк булмаган шул. Песнәкләр яратып ашаган бөҗәкне авызына да каба алмаган.

Шулай йөри торгач, ачыккан һәм үзләренең өенә кайтып җиткән. Ачык тәрәзәдән очып кергән, өстәлдә үзе ашамый калдырган ботканы күргән. Тәлинкәгә очып кунган да ботканы ашарга тотынган. Үзе ашый икән, ә үзе:

— Тәмле, тәмле, нишләп мин моңарчы шулхәтле тәмле икәнен белмәдем икән, — дип сайраган.

Ашый торгач, корсагы шартлап ярылырдай булып тулган. Һәм шуннан кемгә әйләнгән дип уйлыйсыз? Билгеле инде, үзенә?

Шуннан соң әнисе нәрсә пешереп бирсә, шуны ашаган, аны бүтән бимазаламаган.

Сәмига Сәүбәнова

Бергә җайсыз, аерым күңелсез

Бер малай сеңлесенә:

— Минем бөтерчегемә тимә! — ди.

Ә сеңлесе аңа:

— Син дә минем курчакларыма кагылма! — дип җавап бирә.

Балалар икесе ике почмакка утырып уйный башлыйлар, әмма тиздән аларның икесенә дә күңелсез булып китә.

Нигә күңелсез була соң аларга?

Константин Ушинский

Гап-гади Инсаф

Җир йөзендәге барлык малайларның да исемнәре була. Җирән чәчлеме ул, кара чәчлеме, чебен тимәс чер итәрме, каты йодрыклы сугыш чукмарымы — барыбер. Сиңа исемең, туган- чы ук, әллә кайчан табылган. Табылган гына да түгел — тагылып ук куелган була.

Мине тотканнар да Инсаф дип йөртә башлаганнар. Миңа барыбер. Хет әллә кем дип атаган булсыннар иде. Исемнәр күп бит. Дөнья тулы малайлар, дөнья тулы исем. Шулай булса да берсе дә ялгышмый, буталышып бетми.

Хәбир дисәң, Хәбире «ә» ди, Җәмиле тик тора. Җәмил дисәң, анысы «җә» ди, Хәбире тик тора. Бу эти-әниләр шулкадәр исемне кайдан гына уйлап бетерәләрдер — аптырарсың.

Башка малайлар беләләр микән, юк микән, мин үземә нишләп Инсаф диюләрен әллә кайчаннан бирле беләм. Бер елны, мин салкын тидереп авырып ятканда, авылыннан әби килгән иде. Ул шунда миңа, көчли-көчли, әрли-әрли, кипкән җиләк кайнатып эчерде. Инсафның ни икәнен дә ул әйтте. Әбисенең сүзен тыңлап, әче җиләк суын күбрәк, әмма тәрәзә бозын яламый торган әдәпле малайларны Инсаф дип йөртәләр икән.

Һәркем эштә

Борһанетдин: «Мин бүген сабакка бармыйм; анда барганчы, кырларга чыгып уйнармын», — дип, басу капкасыннан җөгереп чыгып китте.

Борһанетдин кырда бер Атны күрде. Ул тиз генә Ат янына барды да: «Әйдә, Бахбай, икәү уйныйк, күңел ачыйк», — диде.

Ат: «Юк, җаным, минем уйнарга вакытым юк; минем сабан сөрәсем бар, Хуҗама хезмәт итеп ризык табасым бар, син үзең генә уйнарсың», — дип җавап бирде.

Бала, моннан киткәч, Умарта кортын күрде. Ул аның янына да барып: «Әй, Умарта корты! Әйдә икәү уйныйк, күңел ачыйк», — диде.

Умарта корты да җавабында: «Юк шул, минем эшем бар, җәй көннәре тиз үтеп китә. Минем көзгә кадәр төрле чәчәкләрдән ашыгып-ашыгып бал җыеп каласым бар, үзең генә уйна», — диде.

Борһанетдин, аптырагач, бер Кош янына барып, аның үзе берлә уйнавын үтенде.

Кош та, Борһанетдиннең үтенечен кабул итмичә: «Юк, бала, минем уйнарга вакытым юк; кечкенә балаларыма ашатыр өчен чебен-черкиләр аулыйсым бар», — диде.

Болай да булмагач, Борһанетдин тирән уйга чумды да тиз генә мәктәпкә таба җөгерде.

Габдулла Тукай

Конфет ашап, тамак туямы?

(Корея халык әкияте)

Көннәрдән бер көнне ярлы агай базарга юл тоткан. Тамагы бик тә ачыккан икән моның. Базарга килеп җитүгә үк, ул дөге көлчәсе сатып алган. Көлчәне ике капкан да бер йоткан, ә тамагы һаман ач икән.

Аннары агай пешкән бәрәңге сатып алган. Әмма аны ашагач та тамагы туймаган. Инде нишләргә? Уйлаган-уйлаган да калган акчасына шикәр белән дөгедән ясалган иң очсызлы конфет сатып алган. Шуны ашавы булган, кинәт кенә тамагы туйган, ди, моның. Шулчак аптыраудан ул, шап итеп, учы белән маңгаена суккан да болай дигән:

— Әй, ахмак та инде мин! Әллә нинди көлчәләр, пешкән бәрәңгеләр ашап бетердем. Юкка акча әрәм иттем. Башта ук конфет алсам, тамагым шундук туйган булыр иде!

Көлчә белән бәрәңге ашап корсагы тулганны һич кенә дә аңламый икән бит бу ахмак бәндә.

Конфет ашап, тамак туймаганны аңламаган кеше тагын кайда бар икән?

Бер әби

Урамнан бер кыз белән бер малай узып бара. Ә бераз алдарак бер әби бара. Аяк асты бик тайгак. Әби таеп китә дә егыла.

— Китапларымны тотып тор әле! — ди малай һәм кызга сумкасын бирә дә әбигә ярдәмгә ашыга.

Ул кире борылып килгәч, кыз аңардан:

— Әллә ул синең әбиеңме? — дип сорый.

— Юк, — дип җавап бирә малай.

— Әллә әниеңме? — дип гаҗәпләнеп сорый иптәш кызы.

— Юк!

— Алайса, апаңдыр? Я булмаса берәр танышыгызмы?

— Юк ла инде, юк! — дип елмая малай. — Бер әби шунда!

В. Осеева

Ярдәм

Бер әби урам буйлап килә. Атлый да туктый, атлый да туктый. Туктый да, ярдәм итәр кеше юк микән дигәндәй, як-ягына карана: кулындагы төенчеге бик авыр бугай... Аруы йөзенә чыккан. Үч иткәндәй, урам буп-буш. Бер малай гына туп куып йөри. Менә малай әбине күреп туктап калды. Әбинең көч-хәл белән төенчек күтәреп барганын шәйләп алды. Уенны ташлап, әби каршына йөгерде.

— Булышыйммы, әби? — дип, рөхсәт иткәнче үк, төенчеккә ябышты. Карчык бераз тын алыр өчен туктады, мөлаем елмайды.

— Исемең ничек синең, бәбкәм?

— Сөләйман...

— Матур исем. Пәйгамбәрләр исеме. Ә мин Галия әби булам.

— Галия әби, әйдә, булышам, — дип кабатлады Сөләйман. — И Алланың рәхмәте төшкере. Бигрәк итагатьле бала икәнсең. Икебез күтәргәч, төенчек тә җиңел тоелыр, миңа да күңелле булыр. Сөләйман елмайды, төенчекне катырак итеп тотты. Менә алар икәүләп, төенчек күтәреп, урам буйлап киләләр. Күптәнге танышлар кебек сөйләшәләр, көлешәләр. Әби кызык нәрсә сөйли, ахры. Адымнары җиңел — кулларында авыр төенчек димәссең. Сөйләшә-сөйләшә, тугыз катлы йорт каршына килеп җитүләрен сизми дә калдылар.

Әбисенең тавышын ишетеп, подъезддан оныгы атылып чыкты һәм бар тавышка:

— Әбекәй, тәмле әйбер бир! — дип кычкырды. Үз яшендәге ят малайны күреп туктап калды. Ник ярдәм итә ул әбигә? Мөгаен, тәмле әйбер алыр өчен күтәрешкән булгандыр. Әбисе юмарт бит аның: кибеткә барып килгәнче оныгын карап торган өчен дә, күршесенә акча бирә. Авызын чалшайтып, усал итеп, ят малайга эндәште:

— «Киндер сюрприз» кирәк булдымыни? Әбием синнән башка да күтәрер иде әле.

Карчык белән Сөләйманның кәефе китте. Көтелмәгән бу сүздән аптырап калдылар. Оныкның сүзе камчы белән яргандай тәэсир итте. Үпкәләде Сөләйман. Ачуы чыгып, йодрыкларын каты итеп йомарлады. Ләкин әбигә хөрмәт йөзеннән тавыш күтәрмәде, тыныч кына:

— Синнән сорамадылар... — дип әйтеп куйды. Оныгы өчен оят булып китте карчыкка, йөрәге сызлап куйды:

— Яхшы малай ул — Сөләйман. — Ярдәмчесен иркәләп, башыннан сыйпады. — Зур рәхмәт сиңа. — Аннары оныгына таба борылып, әйтеп куйды:

— Менә кем белән дуслашырга кирәк! Малай сандалие белән җирне чокый башлады, борынын мышкылдатты.

Кешеләргә рәхмәт өчен генә дә ярдәм итәргә мөмкин икәнен аңлады микән ул? Ул арада Сөләйман, тубын куа-куа, кайту ягына элдертте. Дорфа малай исенә килде, булышырга теләп, әбисе кулындагы төенчеккә ябышты...

Нәкыйп Каштан

Дустым, ничек уйлыйсың, әбиләргә булышу — яхшылыкмы? Синең дә урамда барган таныш булмаган әбиләргә ярдәм иткәнең бармы?

Чәчәк

Булган, ди, бер Чәчәк.

Сабагында утырган-утырган да әйтеп куйган бу:

— Җил мине төрле якка селкетә, кояш кыздыра, ул кыздырганда, күләгәгә дә кереп яшеренеп булмый, туйдым бу сабакта гына утырудан,— дигән.

Бүтәннәр аның белән бәхәсләшмәгәннәр. Аларга сабакта утыру да, җил искәндә чайкалу да, кояшта кызыну да, кичке җиләс һавада, тажларны йомып, йокыга талу да бик рәхәт булган.

Шул арада болынга бер кыз йөгереп килгән дә әлеге Чәчәкне, өзеп, түшенә кадаган. Чәчәк куанычыннан нишләргә дә белмәгән.

— Күрдегезме, мин хәзер барыгыздан да өстәрәк, биектәрәк! Мин кояшка да, җилгә дә якынрак, хәзер мин аларның үзләренең кирәген бирәм! — дигән.

Тик Чәчәк җилне туктата, кояшны суыта алмаган, үзе генә сулган. Кызның түшеннән чүп үләннәре арасына төшеп калгач, җил аны очыртып алып киткән дә кире болынга илтеп ташлаган.

Чәчәкнең күзләреннән яшьләр тамган. Сабагына кире кайтып утырыр иде дә, соң булган шул. Бүтән гөлләр аңа:

— Кояш һәм җил белән кем көрәшә соң? — дигәннәр.— Кояш белән җил булмаса, без беребез дә үсмәс идек. Җил безнең орлыкларны тирә-якка тарата, кояш безнең тажларыбызны кирәк чагында ачтыра, кирәк чагында йомдыра.

Кояш та, җил дә Чәчәкне ачуланмаганнар. Җир аны үз кочагына алган, җил яңгыр чакырган. Яңгыр явып үткәч, бу урында бер генә түгел, әллә ничаклы чәчәкләр үсеп чыккан. Әлеге Чәчәкнең орлыкларыннан үсеп чыкканнар алар.

Сәмига Сәүбанова

Таган

(әкият)

Яшәгән ди бер Таган.

Сәгатьләр буе, көннәр буе, атналар буе, айлар буе, еллар буе балаларны атындыра-атындыра ул бик арып беткән ди.

— Сәгатьләр буе, көннәр буе, атналар буе, айлар буе, еллар буе балаларны атындыра-атындыра мин бик арыдым, минем дә ял итәсем килә, — дигән Таган.

Шуннан балаларны атындырудан туктаган. Сәгатьләр буе, көннәр буе, атналар буе, айлар буе, еллар буе тик кенә тора икән. Шулай тора торгач, күгәргән. Хәзер җил искән саен, балаларны сагынып, чыгыр-чыгыр, чыгыр-чыгыр килә-килә елый да елый ди Таган.

Әхәт Гаффар

Мактанчык алма

Бакчада бер алмагач үсеп утырган. Аның әле бер генә тапкыр да алма биргәне булмаган. Яз җиткәч, бер генә бөртек чәчәк аткан да алмага бөреләнгән. Олы агачлар бик сөенгәннәр, кортлар ияләшмәсен өчен, көндез дә, төнлә дә аны саклаганнар.

Алма көзгә бик матур булып кызарып пешкән. Уңыш җыяр вакыт җиткәч, аны да агачыннан өзәргә булганнар. Ләкин Алма:

— Мин, матур алма, өзеп ашар өчен түгел! — дигән дә яфраклар арасына кереп качкан.

Шулай берзаман бөтен бакчага бер Алма булып калган.

Шуннан соң ул:

— Күрдегезме инде, куркаклар, мин матур гына түгел, батыр Алма да бит әле! — дигән. — Курыкмыйча, шундый зур бакчада минем кебек батырлар гына кала!

Бүтәннәр аның соңгы сүзләрен ишетмәгәннәр. Аларның кышка әзерлек эшләре башланган: яфракларын коясы, ботакларын корткыч бөҗәкләрдән чистартасы булган.

Шул арада күптән инде җай гына чыкканын көтеп торган алма корты сиздермичә генә менгән дә Алманы тешләп алган.

Алма, авыртуына чыдый алмыйча, үрле-кырлы сикергән дә, агачыннан өзелеп, җиргә төшкән. Бер генә түгел, әллә нихәтле корт кимереп бетергән үзен.

Сәмига Сәүбәнова

Утлы йомырка

Безнең әбинең ак тавыгы бар. Ул көн дә кыткылдый-кыткылдый йомырка сала. Әби ак тавыгын бик ярата, аны төрле тәмле җимнәр белән сыйлый, ә йомыркаларын иләккә җыя бара. Ул иләктә ак тавыкның йомыркалары бик күп:

— Бер, ике, өч, дүрт... сигез, тугыз, ун...

Бер дә санап бетерерлек түгел. Ул йомыркаларның ничә икәнен әби үзе дә белми торгандыр әле...

Беркөнне әби, ах-вах итеп, ишектән килеп керде.

— Иләктә унбиш йомырка бар иде. Ундүрткә калган. Унбишенчесе утлы йомырка иде. Мин аны вакытлыча гына иләккә куеп торган идем. Эх, харап булдык,— ди әби.

Мин әйтәм: «Әллә ул янган?» — дим. Әби үзенекен сөйли:

— Күрше карчык биргән иде, берүк сакла, дигән иде. Менә хәзер югалган, ахрысы, кем дә булса берәү алган,— ди.

Мин бер сүз дә эндәшми торам. Ә әби минем күзләремә туп-туры карый. Алай текәлеп карагач, минем күзләрем оялалар. Әби һаман-һаман сөйләнә:

— Башкасы булса бер хәл иде, утлы йомырка бит, утлы йомырка. Ә менә бит пожар чыгачак. Ул авылыбыздагы бөтен өйләрне яндырып бетерәчәк. Йомыркасы аның миңа берни түгел...

Минем колакларым ут кебек яна башладылар. Үземә дә әллә ничек эссе булып китте. Ахры, күргәндер.

— Әйтергәме, әйтмәскәме?

Әйтер идем — ул йомырканы мин сорамыйча алдым, әби орышыр. Әйтмәс идем — ул утлы йомырка белән кибет яначак. Бөтен авыл, безнең өй дә, Җәмилләр өе дә яначак.

Мин йодрыгым белән күзләремне уа башладым һәм

— Әби, утлы йомырканы мин алган идем! — дип елап җибәрдем.

Әби әйтә:

— Харап булганбыз, әйт, кая куйдың? — ди. Мин әйтәм:

— Җәмил белән кибеттән конфет алып ашадык.

Шунда ук әби каядыр чыгып йөгерде. Ахрысы, кибеткә киткәндер. Ә мин оялуымнан көн буе өйгә кайтмыйча йөрдем. Авыл өстендә бер нәни генә төтен күрсәм дә, куркып китәм. Ярый әле, моржадан чыккан төтен була.

Пожар чыкмады. Кич белән генә өйгә кайтсам, әле һаман йокламаганнар. Барысы да өстәл тирәли тезелешеп чәй эчеп утыралар.

Сеңелем Гөлчирә:

— Әнә, утлы йомырка кайтты! — дип көлә.

Ә башкалар көлмиләр. Мине чәй эчәргә чакыралар. Мин, песи кебек булып, бер кырыйга барып утырам.

Әби көлә-көлә чәй ясый:

— Әй юләр, юләр, йомырканың утлы булганын кайчан күргәнең бар? Утлы булгач, аннан чебеш ничек чыксын? Тик зурлардан сорамыйча әйбергә тиергә генә ярамый,— ди.

Ә мин тагын кып-кызыл булам. Нигә сөйли торгандыр бу әби. Әйтерсең инде аны хәзер мин белмим.

Абдулла Алиш

— Син танышкан әкият һәм хикәяләрдә нинди сыйфатлар турында сүз бара? Кайсы сыйфатлар — тискәре, кайсылары уңай сыйфат дип уйлыйсың? Авторлар сезгә нинди булырга өнди?

Тормышта бәхетле булу өчен нәрсә кирәк микән? Алдагы әкият белән таныш. Бәлки бу сорауга җавап табарсың.

Тәмле кабартма

(әкият)

Тычкан баласы кабартма яраткан.

Тычкан баласы кабартма яраткан. Әнисеннән гел кабартма пешерүен сорап аптырата икән. Тик җәен әнисенең мич янында кабартма пешереп торырга вакыты булмаган. Көннәр матур чагында кышка җитәрлек ризык әзерләргә кирәк булган аңа.

Тычкан баласы кабартманы үзе пешерергә булган.

Зур казан алган, аңа су салган, суга чүпрә салып болгаткан, он, йомырка, тоз, сөт, май белән бутаган һәм камыр басар өчен казан эченә сикереп төшкән дә:

Бер сикерәм, бер басам,
Бер басам, бер сикерәм.
Тәмле сумса пешерәм.
Берсе сиңа, берсе миңа,
Берсе була әнигә.
Берсен алам сатарга,
Алып барам базарга.
Тәти кашык алырга.
Майлы сумса кикертә,
Күп ашасаң симертә.
Маймыл кебек сикертә, — дип җырлый-җырлый бии икән.

Сикерә-сикерә бии торгач, үзенең казан эчендә камыр басуын да, кабартма пешерергә җыенуын да онытканн һәм камыр өстендә йоклап киткән.

Камыр исә тычкан баласы биегәндә кытыгы килүгә көчкә чыдап торган. Тычкан баласының йоклап китүе булган, тотынган бу күтәрелергә. Башта казан читенә менгән, аннан бераз карап-карап торган да тычкан баласы кебек биемәкче булган. Тик тычкан баласы кебек үк сикерә-сикерә бии алмаган, кабарына гына икән. Кабара торгач, тычкан баласы камыр эчендә күмелеп, күзе генә күренеп калган.

Ул арада әнисе кайткан һәм әзер камырны күргән. Камыр эченнән тычкан баласын колагыннан тартып чыгарган.

— Кызым эшкә ярый башлады, — дип сөенгән ул.

Әзер камырдан тәмле кабартма пешергән.

Сәмига Сәүбанова

Туңгак балык

(әкият)

Яшәгән ди тагын бер Балык. Җәй көне аңа бик рәхәт булган. Җылы көнне тирән суда йөзгән, суык көннәрдә сай суда йөзгән. Кыш җитәч кенә хәлләре мөшкелләнгән. Балык туңа башлаган. Ә җылынып була торган сай суны боз каплап бетергән!

«Мин туңам бит, инде ничек җылыныйм икән?» — дип уйлаган бу Балык. Бик озак уйлап йөри торгач, ничек җылынырга икәнен уйлап тапкан бит.

Ничек итеп дисеңме? Уйла әле, уйла, Балык ничек итеп җылынды икән?

Белмисеңме? Ярый инде, үзем әйтәм. Боз юрганын ябына икән дә рәхәтләнеп йокыга китә икән бу. Ә юрган ябынып йоклаганда туймыйлар бит, әйеме?

Әхәт Гаффар

Бәхет

Бер шәһәрнең читендә генә өч агай-эне торалар иде. Боларның, нинди генә эшкә тотынсалар да, ни сәбәптәндер эшләре уңга китми иде.

Бу агай-энеләр эшләре уңмавында үз-үзләрен гаепләргә уйлап та карамыйча, һаман Бәхет юклыгыннан гына күрәләр иде.

Берзаман ничектер Бәхет, күзгә күренмичә генә, боларга кунакка килде дә бу өч агай-энегә, нинди генә эш башласалар да, ярдәм итәргә сүз бирде.

Бу вакытта өч агай-эненең берсе сәүдәгәрлеккә тотынган иде. Дәрхаль Бәхетнең ярдәме илә ни сатса — аннан файда, ни алса — аннан табыш итеп,

берничә көндә малы вә хәзинәсенең хисабы булмаган бер зур бай булып китте.

Шул ук Бәхет килгән заманда икенче кардәше мәхкәмәдә кятиб (писарь) иде. Бу да Бәхет аркасында хакимлек дәрәҗәсенә күтәрелде; медальләр бирелде.

Сез инде өченчесенә дә Бәхет ярдәм иттеме, диерсез.

Ник итмәсен, итте: өченче кардәш чебен тота иде. Хәзер, Бәхетнең булышлыгы илә, кулын селтәгән саен чебен тота; һичбер селтәгәне бушка китми.

Бәхет кунакка гына килде, дигән идек бит. Дөрес, Бәхет озакламады, китте.

Ике карендәш зур бай вә дәүләтле булдылар. Өченчесе, һаман явыз Бәхетне яманлап, авылдан авылга, сукрана-сукрана, капчык тотып теләнергә китте.

Габдулла Тукай

Бәхетләләр илендә

(әкият)

Борын-борын заманда, моннан бик-бик күп еллар элек, яшәгән, ди, юмарт, гадел бер патша. Мәмләкәтендә аны барча халык олылаган, ихтирам иткән. Байларга да гади халыкны кыерсытырга ирек бирмәгән, ди, ул.

Шуңа күрә дә падишаһка теш кайраучы, эчтән начарлык теләүче байлар да юк түгел икән. Аеруча явыз вәзир ачу тоткан, ди, аңа. Кулыннан килсә, патшаны күптәннән юк итәр иде дә… Патша малае Арысланбайдан гына шүрләгән. Шаһзадә, яшь булса да, батыр йөрәкле, пәһлевандай көчле, атасыдай миһербанлы егет икән, ди.Эһ, әнә шул патшаның варисыннан котылып булсамы?! Күрсәтер иде падишаһка да, гади халыкка да көчлелекнең кемдәлеген. Вәзир кардәше — сихерче карчык белән киңәшләшеп карарга уйлый. Һәм…

…Менә шатлык, уен-көлке белән шау-гөр килеп торган патшалыкны кайгы баса. һәммә кешенең йөрәген тетрәндереп, илгә коточкыч хәбәр тарала: су керергә киткән җиреннән патша малае юкка чыга. Шул көннән башлап ата кеше дәүләт эшләре белән дә, халкы язмышы белән дә кызыксынмый, үз хәсрәтенә чума. Улы баткан елга буена сарай салдырып, бөтен вакытын шунда үткәрә башлый…

Ә вәзиргә шул гына кирәк тә. Ил дә, патшалык та, ниһаять, аның карамагында. Тели икән астыра, тели икән кистерә, тели икән юкка чыгара.

Болай булса, падишаһлары да озак яшәмәс. Малае сагышыннан барыбер сыгылыр. Бакый дөньяга күчәргә дә күп калмас, шәт, үзенә. Вәзир сакчыларга патша сараен уратып алып, анда беркемне дә кертмәскә әмер бирә.

Шул ук илдә яшәгән, ди, Артыкбикә атлы ятимә бер кыз. Ата-анасын кыз бөтенләй хәтерләми дә икән. Әбисе дә вафат булгач, ятимә авыл читендәге ярым җимерек өйләрендә үзе генә яшәп калган. Артыкбикәне, тырыш, уңган булганга, авылдашлары бик яраткан, ди. Миһербанлы бу кыз балага булышып, ярдәм итеп торганнар. Якын итеп, Чәчкә дип кенә дәшкәннәр, ди, үзенә.

Чыннан да, чәчәктәй матур икән Артыкбикә. Байларның эшен эшләп, игенен урып кайтучы авыл халкы, аның йөзен күреп, арыганлыкларын да оныта торган булган.

Менә кызга тирә-якта явызлыгы, ерткычлыгы белән дан тоткан шушы җирләрнең хуҗасы — шыксыз байның да күзе төшә.

— Кем кызы бу? Ник миңа күрсәтмәдегез аны моңарчы?!

Байга ярарга тырышып, аның янында ялагайланып йөргән старостага шул гына кирәк тә инде.

— Ятимә кыз ул. Әти-әнисе юк, хуҗасы аның хәзер сез! — ди капкорсак, бөгелә-сыгыла.

…Ул көнне бай берни әйтми кайтып китә. Ә үзе юлда уйлап бара: «Бу кадәр чибәр затны читкә җибәрергә ярамас. Берәр ярлы-ябагай кул сузганчы үзенеке итеп калырга кирәк. Алты хатынының алтысыннан бер рәт чыкмады. Алтмышка җитеп бара, ә бер малай сөйгәне юк».

Хуҗа, үз уеннан бик канәгать калып, атларын куалый төшә. «Иртәгә үк, мулла чакыртып, никах укытырга кирәк. Үзе уңган, үзе чибәр, үзе ятимә дә. Беркемгә дә калым бирәсе юк».

Һәм менә Чәчкәне староста бай йортына җилтерәтеп китерә.

— Шатлан, каракаш, мин сине, ятимәне, хатынлыкка алып бәхетле итәргә уйлыйм, — дип игълан итә бай.

Мондый сүзләрдән, кыз бөтенләй югалып кала.

— Әйе, шулай уйлап торам. Староста, син атасы урынына шаһит булырсың. Кызны исән-имин саклаганга, сиңа миннән бер төлке бүрек.

— Рәхмәт, баем, рәхмәт! — Староста өчен бу, чыннан да, зур куаныч. Байның бае «бүләк бирәм» диеп торсын әле. Башка староста, муллаларның борынына чиртә, болай булгач. — Нәрсә балавыз сыгасың, хәерче? Бәхет кошы үзе иңнәреңә кунам дип тора лабаса. Рәхмәтеңне белдереп егыл тизрәк хуҗабыз аягына! — Ул, Чәчкәне кулыннан өстерәп алып, бай алдына ава.

— Син ул кадәр дорфаланма әле, староста! Шатлыгыннан шулай балавыз сыга торгандыр чибәркәй. Үзең уйлап кара. Башка кызларның төшләренә дә керми мондый бәхет. Шулаймы, гүзәлкәй? Кил әле, ризалыгыңны белдереп рәхмәтеңне әйт әле.

— Кодрәтле баебыз! Мин бит бик яшьмен. Унҗидем дә тулмаган…

— Әллә мине бик карт дип әйтмәкче буласыңмы? Кара, кара беләкләремә! Алла боерса, бүген кичкә яшьләребезне бергә кушарбыз да урталай бүләрбез. Икебез дә төгәл бер яшьтә булып калырбыз. Хи-хи-хи!..

— Баем, зинһар, кызганыгыз мине! Барлык авыр эшләрегезне эшләрмен. Аяк астыгызда туфрак булырмын. Авылдашларымнан гына аермагыз.

Бай буыла-буыла елаучы Чәчкәне күтәреп алмакчы була, кыз капылт читкә тайпыла.

— Ә-ә, шулаймыни, бай ярамыймыни әле сиңа?! Минем җиремдә торып, минем ипиемне ашыйсың. Җитмәсә, сүзләремә каршы киләсең? Бәлки, хәерче бетең бардыр? Кара аны, тавышың чыкмасын! Хәерчеләр заманы үтте инде. Сезнең ишеләрне канаты астына алган патшагызның үз кайгысы кайгы. Ил, нинһаять, олуг вәзиребез кулында. Бел, никах бүген үк! — Байның камчысы кызның аркасыннан чыжлап уза. — Ялчылар, алыгыз үзен. Ак өйгә алып чыгып бизәгез дә никах узганчы шунда бикләп тотыгыз. Карагыз аны, кызны нык саклагыз. Ул-бу була калса, тирегезне тереләй тунармын.

Кыз баланы, яңа киемнәргә киендереп, төрледән-төрле чулпылар асып, ак өйгә ябып куялар.Шулай да бәхете бар икән әле Чәчкәнең: ярдәм итүче табыла. Байның беренче хатынныннан туган кызы Гөлшат яшь кәләшнең хәлен ишетә. Ул моннан берничә ел элек атасы ризалыгыннан башка сөйгәне — ярлы егеткә ябышып чыккан була. Бай бик нык тузынса да, берни майтара алмый. Патшадан шүрли. Ә инде ил вәзир кулына күчүгә, бай кызыннан рәхәтләнеп үч ала. Хәерче токымын бетерәм дип, ирен балалары белән бергә коллыкка саттыра. Ә кызын, ялчы итеп, хуҗалыктагы иң пычрак, иң әшәке эшләрне башкарырга мәҗбүр итә.

«Мин бу дөньяда барыбер ярты үлек. Яшь кызны ничек тә коткарырга кирәк. Атам явыздан аз булса да үчемне алырмын», — дип уйлап, Гөлшат, әкрен генә килеп, арткы ишектән Чәчкәне ачып чыгара.

Качуын кача кыз, ләкин озак та үтми, аның юклыгын сизәләр. Чәчкә бар көченә йөгерсә дә, яхшы атларга атланган куучылар эзенә тиз төшә, менә-менә тотып алачаклар… Бердәнбер котылу юлы елга буендагы корылма — патшагалиҗәнаплары сарае. Ил хуҗасын бик гадел, мәрхәмәтле булган диләр.

Әмма корылмаларга якынлашкан саен, качкынның ышанычы бетә генә бара. Сарайны уратып алган сакчылар ул тирәгә беркемне дә якын җибәрми. Инде нишләргә? Явыз байның җиденче хатыны булганчы, үлемең яхшырак. Кыз, йөгереп килгән куәткә, дулкыннар кочагына ташлана.

…Чәчкә, ниндидер каты әйбергә бәрелеп күзләрен ачса, ни күрсен: эреле-ваклы ташлар өстендә ята, имеш. Тирә-ягында төрледән-төрле балыклар йөзеп йөри… Әллә ул су асты патшалыгындамы? Яктылык килгән якка караса… Чү! Коточкыч бер җәнлек аңа таба йөзеп килә… Зур ямьсез күзләре чаткылар чәчеп ялтырый. Мондый ук килбәтсез кыяфәтле җанвар күргәне булмаганга, кыз баланың бөтен тәнен калтырау ала. Йа Ходаем, бетте… Юк, болай гына өркетә алмассың, хәшәрәт. Кыз туп-туры җәнлекнең күзләренә текәлә. Ә теге якынлашканнан-якынлаша. Нәрсә булса, шул булыр. Урыныннан да куз талмаячак! Үзе сайлап алган үлем булгач, үкенәсе түгел. Аннан теге бай бу килбәтсездән дә шыксызрак күренгән иде лә. Аның янауларына да карамыйча качып китә алды түгелме соң?

— Нинди генә иләмсез булсаң да курыкмыйм мин синнән, җанвар. Үлсәм үләм… — дип пышылдый Чәчкә һәм, тирә-ягыннан ташлар алып, һөҗүмгә әзерләнә…

Шулчак су астында мәшхәр купты диярсең. Аның соңгы сүзләре коточкыч дәһшәтле авазларга кушылып юкка чыга. Кыз, караңгылыкка чумып, аңын югалта.

…Кояш нурлары иркәләвен тоеп, кыз әкрен генә керфекләрен күтәрсә, ни күрсен, пәһлевандай гәүдәле егет белән су кырыенда басып торалар. Әйтерсең күршесе аның күзләре ачылуын гына көткән, алдына тезләнеп сүз башлый:

— Курыкма миннән, чибәркәй! Мин шушы илнең патша малае Арысланбай булам. Вәзирнең явыз теләге белән сихерче мине шыксыз су җәнлеге кыяфәтенә кертте. Иөз-килбәтемнең иләмсезлеген беркемнең дә күтәрә алмаслыгына тәгаен ышанып: «Кем дә кем курыкмыйча күзләреңә туры бага алса, шул чагында гына сихердән азат булачаксың!» — дип мәсхәрәләп көлделәр әтиемнең дошманнары, һәм менә шул көннән башлап мин су астын да яшәдем. Баштарак яр буена да чыккалап карадым каравын, тик кешеләрнең мин күренүгә үк өркеп, аңнарын жуюларын күреп, бүтән су өстенә күтәрелмәдем. — Шаһзадә, Чәчкәне ягымлы карашы белән иркәләп, сүзен янә дәвам итә: — Моңа кадәр кыяфәтемне беркем дә күтәрә алмады. Бары син генә миннән курыкмадың, батыр кыз! Кыюлыгың, курку белмәвең

белән син мине коточкыч бәладән арындырдың — мине дә, илебезне дә сихер богавыннан азат иттең! Әгәр риза булсаң, хатыным бул!

Улын көтеп көне-төне су өстен күзәткән патша, яр буенда егет белән кызны абайлап, алар янына ашыга. Тукта, чү! Бу бит аның газизе! Баласын танып, дөньясын онытып, ата бердәнберенең кочагына ташлана.

— Әтием, шатлыгыбыз бик зур. Ләкин улыңны куеныңа кысканчы, иң әүвәл менә бу гүзәлгә рәхмәтеңне җиткер! Мине сихердән коткаручы иң батыр кыз шушы була инде, әткәем.

Нәкъ шулчак шау-шу куба.

— Тотыгыз, тотыгыз качкынны! — дип, байның ялчылары Чәчкәне егет кулыннан каерып алып китмәкче була.

— Нинди качкын, сезгә ни кирәк? Алдыгызда патшагыз торганын күрмисезме әллә? — дип, шаһзадә, коткаручысын аралап, тегеләргә аркылы төшә.

— Патша галиҗәнаплары! Алар дөрес әйтә. Мин, сезнең улыгыз уйлаганча, бернинди дә батыр кыз түгелмен, фәкать бер ятимә буламын. Тирә-якта ерткычлыгы белән дан тоткан карт бай мине хатынлыкка алмакчы булды. Ул картлачның җиденче хатыны булганчы, дип, үлем сайлап, мин су төбенә ташландым. — Кыз, елый-елый, патша алдына ава. — Зинһар, мәрхәмәтегездән аермагыз! Бөтен ышанычым сездә…

— Минем җиремдә шулкадәрле явызлыкка юл куелганмы? Юк, моның булуы мөмкин түгел! Тор, кызым. Моннан соң сине беркем дә кыерсыта алмас. Кайда минем эчкерсез вәзирем?

— Әтием, синең шул мәкерлең һәм кайбер ялагайларың… — Арысланбай да түкми-чәчми атасына үзенең башыннан үткәннәрне сөйләп биргәч, патша җыйналып өлгергән халыкка вәзире белән явыз байларны кичекмичә тотып китерергә әмер бирә. Ә аннан инде улының янындагы кызга шундый да мөлаем итеп карап торганын күреп, ата: — Кыю кыз! Әгәр риза булсаң, бир кулыңны улыма. Бул аның тугры хатыны, — дия.

Чәчкә оялып кына кулын егеткә суза.

— Патшалыгымны сезгә бүләк итәм, балакайларым. Икегез дә гадел булыгыз! Халкым мине яратты, сезне Дә ихтирам итсеннәр. Илебездән явызлык яңадан юкка чыксын! Ә хәзер, әйдәгез, барыбыз да сарайга юнәлик. Туйны бәйрәм итәргә.

Туйларында булган кешеләр, гаҗәп күңелле үтте, дип сөйлиләр. Ә вәзир белән явыз байларга килсәк, халык аларга үзе хөкем чыгарган. Барысын

да, мичкәләргә Утыртып, суга агызганнар. Хәзер бу илдә һәркем үтә дә бәхетле яши, ди.

Нурия Сәйяр

Бәхет төшенчәсе нәрсә була инде? Нинди кеше бәхетле була инде?

Кое суы

Яшәгән ди бер коеда чип-чиста Су. Тирәндә генә, төптә генә җылеп яту аны туйдырган, бер заманны аның өскә менәсе, тузан белән уйныйсы килгән. Тырыша торгач, Кое суы өскә менеп җиткән, җиргә дә түгелгән. Һәм чип-чиста Кое суы пычракка әйләнгән.

Шуңа күрә кирәк-кирәкмәскә сикереп төшмәскә, үз урыныңны белебрәк яшәргә кирәк.

Әхәт Гаффар

Тормышны, дөньяны ярата торган бер Үрмәкүч бар икән. Тик менә аның үзен берәү дә яратмый, ди. Балалар аны күрүгә куркып качалар, ә олылар борыннарын җыералар.

Үрмәкүч

Бу хәл Үрмәкүчне башта аптырашта калдырган, ә аннары бөтенләй дә сагышка салган. «Мин әллә бик ямьсез үрмәкүч микән?» — дип уйлана башлаган ул. Шуннан көзге янына үрмәләп менгән дә үз-үзенә караган.

«Юк инде, алай ямьсез дә түгел, күзләрем әнә ничек матур иттереп карый. Нишләп, алайса, миннән куркалар соң? Бәлки, берәр дус тапсам, ул миңа барысын да аңлатып бирер», — дип уйлаган Үрмәкүч. Шуннан үзенә дус эзләп карарга булган. Тик юк, аны күрүгә, барысы да тизрәк качу ягын карыйлар икән. Дуслашырга теләвен аңлаучы табылмый, ди.

Шулай да Үрмәкүч берәүгә дә үч сакламаган, үз эченә үзе бикләнгән дә караңгы бер почмакта яшәргә булган. Әмма аның күңелендәге сагыш, моң аңа тынгылык бирмәгән. Күңеленең иң түрендә өмет уты яшәгән.

Бер төнне төшендә ул матур рәсемнәр төшереп үрелгән челтәрләр күргән. Йокысыннан уянуга, Үрмәкүч челтәр үрә башлаган. Матур, төгәл итеп үрелгән челтәрләрне күреп сокланмый мөмкин түгел икән. Һәм, чыннан да, бу челтәрләрне күреп, кешеләр, хайваннар, кошлар һәм бөҗәкләр дә сокланган. Хәтта болытлар артына качып моңаеп утырган кояш та, бу челтәрләрне күрергә дип, күк уртасына чыккан һәм елмаеп җибәргән. Кинәт кенә көзге яңгырлар да туктап калган.

Ә Үрмәкүч бар дөньясын онытып үргән дә үргән һәм, үзе дә сизмәстән челтәрләренә ияреп, яктыга чыккан. Шуннан аптырашта калган. Аннан берәү дә курыкмый, ә киресенчә, аңа сокланып карыйлар икән. Аны күрүгә үк кычкырып елый башлый торган кызчык та шатлыгыннан көлеп җибәргән:

— Менә кем үрә икән бу матур челтәрләрне, — дип, кулларын чәбәкләгән.

Үрмәкүч башта оялып куйса да, соңыннан чиксез бәхетлегә әйләнгән. Аны барысы да ярата, дус итә бит. Аңлаган Үрмәкүч: сине яратсыннар өчен үзең генә түгел, ә эшләгән эшләрең дә матур булырга тиеш икән.

Айсылу Имамиева

Эшләмәгән ашамый

(Серб халык әкияте)

Корольнең бик тә чибәр бердәнбер кызы булган, ди. Әмма ул гаҗәеп ялкау: көннәр буе көзге каршында бөтерелүдән башканы белми икән.

Менә кызны кияүгә бирер вакыт та җиткән. Король: «Кем дә кем өч ел эчендә кызымны эшкә өйрәтә, аны шуңа кияүгә бирәм», — дип хәбәр салган. Көннәр үткән, айлар үткән, әмма король сараена кыз сорап килүче күренмәгән. Башка чарасы калмагач, король үзенең яраннарын кызына кияү эзләргә чыгарып җибәргән. Юлда боларга сигез үгез җигеп җир сөрүче егет очраган. Егеткә, тиз генә җыенып, король сараена барырга кушканнар. Нишләсен егет, курка-курка гына сарайга юл тоткан. Король аны хөрмәтләп каршы алган, эшнең нәрсәдә икәнен тәфсилләп аңлаткан. Егет кызны өч елда эшкә өйрәтергә вәгъдә биреп, үзе белән алып киткән. Шундый чибәр кызны иярткән кайтуын күргәч, әнисе сөенеп бетә алмаган.

Икенче көнне иртән егет үгезләрен җигеп, җир сукаларга киткән, ә әнисенә ялкау кызга эш кушмаска әйтеп калдырган. Кич басудан кайтып, ашарга утыргач, әнисеннән ул:

— Бүген кем нәрсә эшләде? — дип сораган.

— Син җир сукаладың, мин өй җыештырдым, ашарга пешердем, — дигән аңа әнисе.

— Әйдәгез, кем эшләгән, шул өстәл янына ашарга утырсын, — дигән егет.

Король кызының, билгеле инде, моңа ачуы чыккан. Ул, үпкәләп, ач килеш йокларга яткан. Икенче көнне дә шул хәл кабатланган. Ә өченче көнне кыз егетнең әнисенә әкрен генә:

— Бу өйдә миңа да берәр эш юкмы? — дип сүз каткан. Әни кеше аңа, утын алып кереп, мич ягарга кушкан. Кичен тагын өстәл янына җыелганнар.

— Әни, бүген кем нәрсә эшләде? — дигән егет. — Өчебез дә эшләдек, — дип елмайган әни кеше.

— Алайса, өчебез дә ашыйбыз инде.

Шулай итеп, алар беренче мәртәбә бергә утырып ашаганнар. Әкрен-әкрен генә король кызы эшкә өйрәнеп, кул астына керә башлаган.

Король өч елдан кызының хәлен белергә килсә, аның җир җимертеп эшләгәнен күреп шаккаткан.

— Ничек болай эшкә өйрәндең син? — дип сораган ул кызыннан.

— Ә бездә тәртип шундый: кем эшләми, шул ашамый, — дип җавап биргән аңа кызы. — Әгәр безнең белән бергә ашыйсың килсә, бар, утын ярып кер, әти!

Король сөенеченнән егеткә үзенең ярты биләмәсен бүләк иткән. Егет белән кыз гөрләтеп туй ясаганнар. Ә король исә шул көнне бөтен илгә «Кем эшләми, шул ашамый!» дигән фәрман тараткан, ди.

Кадаклы аш

(Төньяк Америка халыклары әкияте)

Бер ярлы адәм хәер эстәп йөри икән. Авыл уртасындагы хәлле генә йортка кереп, ашарга сораган бу.

— Өемдә бер тәгам ризык та юк! — дип кырт кискән хуҗа-ның хатыны.

— Миңа ризык кирәк түгел, бер кадак булса, шул җиткән. Кадактан аш пешерә беләм мин, — дигән теләнче.

Моны ишеткән хуҗа бер кадак чыгарып биргән.

— Чүкеч тә кирәк булыр, — дигән теләнче.

Хуҗа чүкеч биргәч, ул учак өстендәге агачка кадак кагып куйган.

— Хәзер инде бер зуррак казан китер, шунсыз тамак туй-мас, — дигән теләнче.

Хуҗа казан китергән, теләнче аны кадакка элеп куйган, ка-занга ярты-лаш су салган.

— Бераз тозыгыз бармы? — дигән ул аннары.

Хуҗа тоз биргәч, теләнче иркен сулап куйган да сүзен дәвам иткән:

— Тоз янына ит тә кирәк инде...

Хуҗа келәттән ит алып чыккан. Теләнче итне казанга салган да болай дигән:

— Бәрәңгесез, кишерсез, сугансыз тормыйсыздыр инде...

Хуҗа теләнче әйткәннәрнең һәммәсен дә китергән. Теләнче, сөйләнә-сөйләнә, учакка утын өстәп торган. Тиздән аш пе-шеп тә чыккан. Бер

кадактан башланган аш бик тә тәмле булган. Теләнчегә дә, хуҗага да, аның хатынына да җиткән. Әле сезгә дә ярты казан калган, ди. Тамагыгыз ачса, кадаклы аштан авыз итергә килегез!

Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар

Күз күреме җитмәслек, очына-кырыена чыгып бетмәслек бик зур бер болында күкрәп үләннәр үскән. Чалгы белән чабарлык булып өлгергәннәр. Төрле төстәге матур чәчәкләр анда хуш исләр таратканнар. Кош-кортлар үзләренең матур сайраулары белән болынны яңгыратканнар.

Менә шундый матур болында ат көтүе йөргән. Дугадай муенлы, стакан тояклы аргамаклар болын үләнен ашаганнар. Туйганчы, салкын чишмә суын эчкәннәр. Бу атларның көтүчеләре булмаган. Бары тик үз араларыннан иң сылу, йөгерек, иң җитез Җирән Кашка гына көтүче хезмәтен үти икән. Ул, муенындагы кыңгыравын шалтыратып, башкаларны үз артыннан ияртә, барысын бергә туплап йөртә икән.

Җирән Кашка беркөнне бик арыган, кичен аның йокысы калган булган. Ул, ятып, бераз хәл җыйнарга, йоклап алырга уйлаган. Иптәшләренең барсын бергә җыйган да әйткән:

— Аерылсагыз, айга җитмәссез, бүленсәгез, бүген бетәрсез, бергә йөрсәгез, рәхәт көн итәрсез, — дигән. Атлар башта гел бергә йөргәннәр. Кичкә таба берничәсе бик начар иткән, көтүдән аерылып киткән. Алар Җирән Кашканың сүзләрен онытканнар. Аның файдалы киңәшен тотмаганнар. Аерылып киткәннәре килбәтсез зур бер Аюга очраганнар, куркуларыннан һушсыз була язганнар, кайту юлына бик тиз борылганнар. Ләкин Аю алар артыннан калмаган. Әй куган, әй куган, хәер, тота алмаган. Әй йөгергәннәр, әй йөгергәннәр атлар, юлларында тау очраган — йөгереп менгәннәр, урман очраган — ерып чыкканнар, чокырдан сикерергә уйлаганнар — булдыра алмаганнар. Тирән чокыр эченә егылганнар, аякларын сындырганнар. Тагын өчесе көтүдән бүленеп киткән булган. Күп тә үтмәгән, алар да Җирән Кашканың туры сүзләрен исләренә төшергәннәр, үзләренең бүленеп китүләренә үкенгәннәр, ләкин инде соң булган. Каршыларына, тешләрен шакылдатып, күзләрен акайтып, бер соры Бүре килеп чыккан. Алар бу явыз дошманны күргәч каушап калганнар, үзләрен үзләре белештерми, ярсып, кайсы кая таралганнар. Бүре шунда ук бер Атның бугазына ябышкан, буып алган, егып та салган. Калганнары качып котылганнар. Җирән Кашка муенындагы кыңгырауның матур шалтыравын ишеткәннәр һәм туп-туры шунда киткәннәр.

Барысы да Җирән Кашкага үз башларыннан үткән хәлләрне сөйләп биргәннәр, аның туры сүзен тотмауларына бик үкенгәннәр. Ә Җирән Кашка башын чайкаган, көчле итеп бер шалтыраткан — көтү бергә җыелган, тагын бер шалтыраткан — көтү бергә җыелган, тагын бер шалтыраткан да сөйләргә тотынган:

— Күрдегезме сүземнең дөреслеген: аерылганнар Аюдан өркеп һәлак булдылар, бүленгәннәр Бүрегә очрадылар, — дигән дә кыңгыравын өченче мәртәбә шалтыраткан һәм барлык аргамакларын болынга җыйган.

Абдулла Алиш

Башмак

(Татар халык әкияте)

Борын заманда бер бабай үзенең улы белән бер начар гына өйдә яши икән. Үләр алдыннан малаена әйтә бу: «Сиңа бер башмак кына калдыра алам инде» — ди.

Менә малай ил гизәргә чыгып китәргә уйлый. Башмакны кигәч, аягына җиңел булып китә, ә башмак музыка уйный башлый. Бара торгач, малайга бер кеше очрый. Ул әйтә: «Бу башмагыңны миңа сат, мин сиңа алтын бирәм», ди. Малай риза була. Теге кешенең башмакны киюе була, шунда ук йөгереп тә китә, һич туктый алмый бу. Көч-хәл белән башмакны салып, кире малайга тоттыра: «Мә, шайтанлы башмак икән» — ди.

Бара торгач, малайга бер әби очрый. «Шәһәрдә нихәлләр бар, әби?» — дип сорый малай. «Унбиш ел элек ханның малае үлгән иде, әле дә халык кайгыда, көләргә ярамый», — ди әби. «Ханны юатырга кирәк, үлгән кире кайтмас, шунда барыйм әле», — ди малай. Шәһәргә музыка уйнатып, уен-көлке белән килеп керә. Кылыч тоткан вәзир моны куа башлый. Шаулашкан тавышка хан үзе килеп чыга да башмаклы егеткә керергә куша. «Бу малай үзе уйнамый, аягындагы шайтан башмагы уйный», — ди вәзир. «Алайса, ул башмакны киеп, син биеп кара әле», — ди хан. Вәзир шулай эшли дә. Тик биемәкче булып бер аягын күтәрә, икенче аягын кузгата да алмый икән.

Шулай итеп, унбиш ел буена көлмәгән ханның күңелен ачкан егет сарайда яшәп кала.

Биш чия

– Асия, Асия!
Кулыңда биш чия.
Калдыр да өчесен,
Бир миңа икесен.

– Юк-юк, – ди Асия, –
Миңа аз өч чия...
Йомарлап нык тотты,
Һәммәсен дә сытты.

– Асия, Асия!
Кайда соң биш чия?
Саранлык алдады –
Берсе дә калмады.

Җәвад Тәрҗеманов

— Акыллым, әйт әле, Асиянең ялгышы нәрсәдә. Бу сыйфат яхшы гадәтләр дөньясында кала аламы?

— ... .

— Әйе, син хаклы. Саранлык монда кала алмый. Ә менә без синең белән хәзер тыңласы хикәядәге малайлар Асиягә һич кенә дә ошамаганнар. Аларда нинди яхшы гадәтләр булуын тыңлагач белербез.

Өч угыл

Бер кешенең өч улы бар иде. Иң кечкенәләре Гали исемле икән. Аталары базардан өчесенә дә берәр алма алып кайтты. Алмалар бик пешкән, татлы, сусыл җимешләр иде.

Берничә сәгатьтән соң аталары, балаларын янына чакырып: «Алмаларны нишләттегез?» — дип сорады.

Өлкән улы әйтте:

— Әти! Мин алмамны ашадым. Эчендәге орлыкларны җыеп куйдым. Бакчабызга чәчеп, алма агачы үстермәкче буламын.

— Яхшы иткәнсең, улым! — диде ата. Уртанчы улы әйтте:

— Мин алманы ашадым. Бик тәмле, татлы җимеш икән. Әтиемә Хак Тәгалә исәнлек бирсен дип дога кылдым.

Атасы янә: «Яхшы иткәнсең, улым!» — диде. Өченче улы Гали атасына карап әйтте:

— Алманың yртысын ашадым. Атасы әйтте:

— Ярtысын нишләттең? Гали куркып, кызарып әйтте:

— Күршебезнең улы Вәли авырып ята. Барып, ярtысын аңа бирдем. Бик куанды, дога кылды.

— Бәрәкалла, улым! Син бигрәк тә яхшы иткәнсең! — дип, атасы Галинең битеннән, күзләреннән үпте.

Дәрдемәнд буенча

— Күрдеңме үскәнем, яхшы эшләр эшләүнең юллары бик күп. Һәр малай аны үзенчә эшләгән. Берсе агач утырту турында уйлаган, икенчесе — әтисенә рәхмәтле булып, аңа яхшы теләкләр теләгән, ә өченчесе — авыру дустын сыйлаган.

— Ә менә эти-әнисенең сүзен тыңламаган, сораусыз өйдән чыгып киткән хикәя героена нәрсә булды икән? Әкиятче Абдулла Алиш сиңа шул турыда әкият язып калдырган. Тыңлап китикме?

— ...

— Яхшы.

Хәрәмләшү

Көз. Апалы-энеле Айнур белән Рафис, йөгерешеп, урамга чыктылар да тау итәгендә үскән агачлар арасына ашыктылар. Исәпләре төрле-төрле агач яфракларын, җыеп, альбомнарына беркетү иде.

Ул яфраклар шундый матур: сары, кызыл, куе кызыл, көрән, тагын әллә нинди төслеләр... «Мине ал!», «Мин менә монда!» дигәндәй кызыктырып чакыралар, җилгә иярeп, аяк астына түшәләләр.

Айнур бик ашыгып җыя, хәтта энесе күреп алган яфракларны да аның кул астыннан ук тартып алырга өлгерә. Энесе, кулын сузган килеш, авызын гына ачып кала һәм тагын тырышатырыша җыярга керешә. Матуррак яфрак тапкан саен, апасы:

— Кара әле, Рафис, мин ниндиен таптым! — дип мактана. Тик үзе, Рафис күреп өлгергәнче, күзләрен елтыратып, тапкан яфрагын тиз генә артка яшерә. Менә Рафис та, бик матур каен яфрагы табып, шатлыгыннан:

— Әй апа, мин синекеннән дә матуррак яфрак таптым! — дип кычкырып җибәрде. Апасы шунда ук, йөгереп килеп:

— Бу миңа, — диде һәм энесе кулындагы яфракны эләктереп алып, үзенекеләре арасына яшереп тә куйды. Рафис гарьлегеннән чүт кенә еламыйча калды. Ул, апасы ягына ачулы күз ташлап:

— Үзеңнеке генә җитмимени? — дип куйды да янәдән җиргә иелде. Бераздан соң Айнур энесен өйгә чакырды.

— Күп булды инде, әйдә, өйгә кайтабыз, — диде. Рафис апасы кочагындагы яфракларга карап көрсенде, ләкин калып җыясы итмәде. Алар

куыша-куыша йөгереп киттеләр. Менә кинәт көчле җил, кузгалып, башта Рафисны йолкынталкып үтте, аннан соң, бөтерелә-бөтерелә, Айнурга килеп җитеп, кызның куенындагы яфракларны очыртып та китте. Айнур, нишләргә дә белмичә, яфракларга ымсынып карап калды. Рафис, йөгергән җиреннән туктап:

— Апа-а-а-а, ни булды? — дип, кире борылып килде. Айнур, яшь аралаш:

— Җил алып китте... — дип кенә әйтә алды.

Рафис караса, күктә апасы хәрәмләшеп җыйган берсеннән-берсе матур яфраклар талпына иде.

Нәкыйп Каштан

Бик яхшы сабак алды ябалак

Зәп-зәңгәр күк итәгенә барып тоташкан, очы-кырые күренмәгән бер кара урман бар. Ул урманда яшел киемле агачлар гөрләп үсәләр, тәмле-тәмле җиләкләр кызарып пешәләр. Анда ерткыч бүреләр, хәйләкәр төлкеләр, куркак куяннар, агулы еланнар яшиләр.

Усал ерткычлар, сайраучы кошлар белән бергә бу урманда ике ябалак та тора. Төскә алар тавык төсле чуар, ә башлары анарның песи башына бик охшый. Күзләре, коточкыч зур булсалар да, көндезләрен күрмиләр, шуңа күрә ауга да төннәрен генә йөриләр.

Кичләрен кошлар сайраудан тынгач, ерткычлар йоклагач, урман эчен мәче мыраулаган, бала елаган тавышлар каплап ала. Бу тавышка кошлар — томшыкларын, ерткычлар борыннарын күтәреп йокыдан уяналар: «Рәхәтләнеп йокларга да ирек бирмиләр!» — дип, ябалаклардан зарланалар.

Бер төнне шулай ябалаклар, балаларын иәртеп, ауга киткәннәр.

Ана Ябалак балаларына шушы сүзләрне әйткән:

— Улларым, кызларым, берүк сүземне тыңлагыз. Бер-берегездән аерыласы булмагыз, көндезгә калмагыз! — дигән.

Балалар арасында бик шугы: «Тукта әле, әни сүзен тыңламасам, ни булыр икән?» — дигән, туганнарыннан аерылып, бер якка карап очып киткән. Ә тегеләр моны югалтканнар, аның өчен бик кайгырышканнар. Эзли-эзли йөдәп беткәннәр, таң тугач, өйләренә кайтып киткәннәр. Кайтсалар, теге шаян өйләрендә дә юк икән. «Улым харап булды, улым харап булды», — дип, Ябалак мескен өзгәләнә икән. Бала ябалаклар да бик кайгырышканнар, елашканнар.

Ә теге шаян бу вакыт аяк бармаклары белән агач ботагына нык ябышкан, кая барырга белми аптырап тик утыра икән.

Беренче булып аны Тиен күргән:

— Минем агачымда нишләп болай кукраеп утырасың? — дигән.

— Тиенкәй-изгекәй, зинһар, мине кума инде, бик азга булса да чыда инде, кич булуга китәрмен, сиңа мең-мең рәхмәтләр әйтермен, — дигән Ябалак баласы.

Ләкин Тиен аның сүзләрен тыңламаган, ялваруларына колак салмаган.

— Әниең сүзен тыңламагансың, менә шушы хәлгә калгансың, үзеңә үпкәлә, андыйларга минем агачта кунак булырга рөхсәт юк, — дип, Ябалак кунаклаган ботакны селкеткән. Мескен Ябалак, ботакларны кабалап-кабалап, башка агачка күчкән. Ләкин кошлар аны бу агачтан да куганнар, хәзер үк күзләреннән югалырга кушканнар. Кайгысыннан Ябалак онытылып киткән. Төн дип белеп очып киткән, канатларын ботакларга бәреп бетергән һәм җиргә килеп төшкән. Ә хәйләкәр Төлкегә шул гына кирәк булган, ул аны байтактан бирле сагалап йөри икән.

Төлке аны әз генә эләктермәгән, теге шаян очып өлгергән, ләкин агач ботагына бик каты килеп бәрелгән. Төлкенең авызында каурыйлар гына калган.

Ябалак ничек кирәк алай көнне уздырган. Менә зарыгып көткән кич тә җиткән. Әнисенең әйткән сүзләре шаян Ябалакның исенә төшкән, ул, мескен, елый-елый арып беткән.

Әнисе белән әтисе шук баланы эзләп тапканнар. Ә адашкан Ябалак баласы өйгә кайтып керүенә шатлыгыннан елап җибәргән: «Инде һәрвакыт әти-әни сүзен тыңлармын», — дигән.

Менә шулай шук Ябалак алган бик яхшы сабак.

Абдулла Алиш

— Нәни дустым, синең белән мондый мажаралар булганы юктыр мөгаен, шулай бит. Чөнки син...., яле әйтеп бетер.

— ... .

— Мин нәкъ шулай уйладым да... Әйе әтиеңнең, әниеңнең сүзләрен һәрвакыт тыңлыйсың. Ә хәзер нишләргә кирәклекне бергәләп кабатлыйк әле: Әти-әни, өлкәннәр сүзен тыңларга кирәк. Афәрин!

Инде менә синең өчен иң кадерле, иң якын тукталышка да җиттек, ул — минем гаиләм дип атала.

МИНЕМ ГАИЛӘМ, ӨЕМ

Без — татарлар. Һәм, әлбәттә, безнең башка халыклардан үзгә якларыбыз бар. Мәсәлән, без якыннарыбызга исемнәре белән эндәшмәскә тырышабыз. Алай гынамы, бөтенләй белмәгән кешегә дә “абый”, “апа” дип әйтәбез әле. Сезнең үзегездә дә таныш булмаган абый-апайларның “энем”, “сеңелем” дип сүз кушканы бардыр.

Туганнарыбызга да “абый”, “апа”, “энем”, “сеңелем” дип эндәшәбез без. Абый-апалар күп булганда элек аларны “Алма апа”, “Бал апа”, “Шикәр апа”, “Дәү абый”, “Бети абый”, “Шәкерт абый”, “Тәти абый” ... дип, аерым атап йөрткәннәр.

Апаның ире — “җизни” була. Абыйның хатыны — “җиңги”... Ә инде җизни һәм җиңгинең әти-әниләре “кода бабай”, “кодагый әби”, туганнары — “кодалар”, “кодачалар”. Аларның үзләренә дә шулай дип дәшәбез.

Иң кадерле кешеләребезгә “әни”, “әнием”. “әти”, “әтием” дибез. Кайбер якларда әниләрне “әнкәй”, “инәкәй”, “нәнә”, “нәнәм” дип йөртәләр. Әтиләргә “әткәй” диләр. Үсеп җиткәч тә “әттә” дип йөрүчеләр бар, ягы-ягы белән.

Әби-бабайларыбызны “әбкәй”, “бабакай” дип яратабыз, “дәү әни”, “дәү әти” дип зурлыйбыз. Безнең телебез тәмле, матур, түгәрәк сүзләргә, әйткәнемчә, бик бай.

Фирая Бәдретдин

— Акыллым, сиңа Фирая апаңның хикәясе ошадымы? Син үзең туганнарыңны ничек атап йөртәсең, шуларны әйтеп үт әле?

— ..., ...

— Булдырдың.Туганнарыңны бик яратасың икән. Ә менә хәзер тыңлап китәсе шигырьнең авторы Габдулла Тукай. Ул татар халкының танылган шагыйре. Балалар өчен бик матур, кызыклы, гыйбрәтле шигырьләр, әкиятләр язып калдырган.

Безнең гаилә

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи —
Безнең өйдә без җидәү: безнең песи — җиденчесе.
Бергә ашый, чәй эчә, безнеңлә бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.

Габдулла Тукай

— Акыллым, әйт әле , бу гаиләдә кемнәр бар?

— ..., ...

— Әйе, әтисе, әнисе, үзе, әбисе, бабасы һәм песиләре. Ә син беләсеңме, татар телендә кем дигән сорау кешеләргә карата гына кулланыла, ә менә песигә карата нәрсә дигән сорау куела. Үзегезнең гаиләгез турында сөйләгез әле, син кемнәр белән яшисең?

— Үскәнем, алдагы шигырьләр аеруча матур. Ни өчен икән? Уйла әле, яме?

Нәсел агачы

Бабам әйтә: “Һәрбер нәсел
Бер мәгърур имән кебек.
Якын ул, газиз, кадерле
Атаң йә анаң кебек.
Ботаклары бихисап күп, -
Бар туганнарың шулдыр.
Шушы нәсел агачында
Син яфрагыңны булдыр!
Бу агачка җылы яңгыр,
Шифалы нурлар кирәк.
Иң мөһиме, бу агачка
Ныклы тамырлар кирәк!
Дөнья синең нәселеңне
Шул тамырлардан таныр.
Иң үзәктә, иң тирәндә
“Татар” дигән җан тамыр”.
Бабам әйтә: “Һәрбер нәсел
Үз агачын үстерә.
Нәсел ныклы булган саен,
Илгә күбрәк көч бирә!”

Галимҗан Гыйльманов

Синең нәсел агачың нинди? Ныклы нәсел ул нинди нәсел? Үзеңнең нәселең турында өлкәннәрдән сораш.

Безнең гаилә

Без мактана алабыз:
Барысы биш малай без,
Барыбыз да бертуган,
Барыбыз да ир туган.

Безнең һәркайсыбызның
Сеңлесе дә бар әле.
Дәү әнине онытып
Торам икән, карале.

Әти белән әнине
Кушсак, ничәү булабыз?
Ник аптырап торасыз?
Ягез, тизрәк уйлагыз.
(Тугыз кеше)

Хәкимҗан Халиков

Өй нигә якты?

– Көн ник якты?
– Кояш елмайганга.
– Төн ник якты?
–Ай елмайганга.
– Өй ник якты?
– Әни елмайганга!

Нәкыйп Каштанов

“Әни” сүзе

“Әни” диеп язып куйдым
Яңа яуган ак карга.
Таптамагыз!
Һич ярамый!
“Әни” сүзен таптарга.

Зәкия Туфайлова

— Ни өчен бу шигырьләр елмаеп, күңелне җылытып тора икәнен белдеңме инде.

— ... .

— Әйе шул, акыллым, алар дөньядагы иң әйбәт, иң изге, иң яхшы, иң якын кешеләр – әниләр турында. Ә хәзер син үзең әниеңә әйтергә теләгән иң матур сүзләрне әйтеп чык әле. Хәтерлисеңме ул сүзләрне?

— ..., ... , ...

— Инде син әйткән сүзләрне бергәләп кабатлыйк: кадерлем, бердәнберем, кояшым, алтыным, җаным, йолдызым. Матур да соң безнең татар теле! Әни турында әле тагын бик матур сүзләр табып әйтергә була. Ләкин матур сүзләр генә әйтү җитми әниләрне сакларга, аларга булышырга кирәк кирәк. Бу турыда шагыйрь абыйларыгызның бик матур шигыреьләре бар, бергәләп тыңлап китик әле.

Әниемә ял кирәк

— Әй, кызлар!
— Әй, малайлар!
— Тик торыгыз, тыныгыз!
Аз гына да чыкмасын!
Сезнең тавыш-тыныгыз!
Кошкай, син дә җырлама!
Пескәй, син дә мырлама!
Бозау, син дә мулама!
Акбай, син дә улама!
Шаулама син дә, тирәк! —
Әниемә ял кирәк!

Роберт Миңнуллин

Әнием

Әнием минем матур,
күзләре якты, көләч.
Шундый күңелле була,
ул өйгә кайтып кергәч.
Мин елышам әнигә,
әни миңа елыша.
Битләре аның кайнар,
ә куллары йоп-йомшак.
Конфет та кирәк түгел,
кирәк түгел курчак та,

чөнки мин әниемне
алдым инде кочаклап.

Ренат Харис

Мин әнигә булышам

Вак итеп, тәмле итеп:
Әни пәрәмәч пешерә.
Без табында чәй эчәбез
Бергәләп, тәмле итеп.

Мин дә булыштым әнигә
Пәрәмәчләр ясарга.
Үзең эшләгәч, тәмле ул –
Кирәк эшләп ашарга!

Әзһәр Габиди

— Акыллым, синең әниеңне бик-бик яратканыңны беләм инде. Ә менә син аңа рәхәт булсын, ул да ял итә алсын өчен нәрсәләр эшлисең соң?

— ..., ...

— Афәрин, бик акыллы, игелекле бала икәнеңне белә идем, шуны расладың. Әле бит иң якын кешеләрдән берсе булган әтиләр турында сөйләшмәдек. Зилә безгә нәкъ шул турыда әйтә.

Зиләнең курчагы

Зиләнең бер курчагы бар.
Сузып кына: «Ән-нә», – ди.
Сеңлем аңа: «Әттәбезне
Яратмыйсың әллә? – ди, –
Сөеп кенә тора безне,
Беләсең бит әтине...»
Йә үпкәләр, аңа да бер
«Әт-тә» диеп әйт инде.

Хәкимҗан Халиков

Шофер булам

Мин дә, әтием шикелле,
Шофер булырга уйлыйм.
Шуның өчен һәрвакыт
Машинам белән уйныйм.
Тизрәк үсеп шофер булсам,
Нишләргә белер идем:
Урамдагы бар баланы
Утыртып йөрер идем.

Зәкия Туфайлова

Чүкеч

Үстең инде, улым, дип,
Эш өйрәнсен кулың, дип,
Әти чүкеч тоттырды,
Бер кадакка суктырды.

Суктым ике, суктым өч,
Дүртенчегә бетте көч.
Көч беткәнен сизептер,
Бармакка төште чүкеч.

Әти сукса, нык суга,
Кадактан да ут чыга.
Каян килә мондый көч,
Тылсымлыдыр бу чүкеч.

Җәүдәт Дәрзаманов

Әти дә көлеп торсын

Кояш көлә, мин елмаям,
Сигезенче март бүген.
Бүген әниләр бәйрәме
Шуңа күңелем шат минем.
Кайсын юам, кайсын җыям,
Чиста булсын, ак булсын.
Әниләрнең күңеледәй,
Бөтен нәрсә пакь булсын.

— Бәйрәм бүген, бәйрәм! — диеп,
Бар дөнья көлеп торсын.
Әни бәйрәме икәнне
Әти дә белеп торсын,
Әти дә көлеп торсын.

Зәкия Туфайлова

Минем сеңлем

Һап, һап, һап кына,
Очар коштай талпына.
— Үчти-үчти итәм, ди,
Тәпи атлап китәм, — ди.
Тәпи-тәпи, тәпи-тәпи...
Минем сеңлем бик тәти.
Бер утыра, бер баса,
Биетим лә, булмаса.
Тып-тып килә ул,
Ничек кенә белә ул!
Бәләкәч кулларын җәеп,
Чарык-чарык көлә ул.
Тыпыр-тыпыр биесен,
Тик куансын, тик көлсен.
Көлсә көлер эше бар,
Ике бөртек теше бар...
Һап, һап, һап!

Резеда Вәлиева

Өйрәнә

Энем йөрергә өйрәнә,
Тотынмыйча йөрергә.
Хәтта йөрергә дә түгел,
Исәбе — йөгерергә!
Матур гына атлап китә,
Бер атлый да абына.
Абына да торып китә,
Тик егыла тагы да.
Торырга кайчан өлгерә?

Егыла кай арада?
Егылып яткан була ул
Кайчан гына карама!
Көн дә шулай өйрәнә ул
Урамда да, өйдә дә.
Йөрергә өйрәнми лә ул,
Егылырга өйрәнә!

Роберт Миңнуллин

Әбиемне яратам

Мин үзем шәһәрдә яшим,
Авылга кайтам җәен.
Чөнки ул авылда яши
Яраткан әбекәем.
Әбием анда ялгыз яши,
Мине сагынып көтә.
Мин кайткач, шатланып йөри,
Мине бик кунак
Мин, үскәч, әбием белән
Авылда торачакмын.
Әбием картаеп киткәч,
Ярдәмче булачакмын.

Гөлшат Зәйнашева

Минем әбием

Әбием күзлек кия,
Чәчләренә чал кунган.
Бер көн дә соңга калмый,
Иртүк тора йокыдан.
Минем әби энемне
Бәй-бәй итә, пәп итә.
Ул йокыдан торганда,
Мәмие пешеп җитә.
Әбекәй, алтыным,
Минем иң якыным.
Яратам, яратам,
Яратам мин аны!

Галимҗан Латыйп

Әбием килгән

Өйгә кайтсам, өй балкыган —
Өйгә нур иңгән!
Ерак җирне якын итеп,
Әбием килгән!
Үзен ничек сагынганны
Белгән ул, белгән!
«Күрим әле улымны!» — дип,
Әбием килгән!

Фирая Зыятдинова

Минем бабай

Минем бабам — капитан,
Сугышта булып кайткан.
Күкрәк тулы орденнар,
Медальләр алып кайткан.
Безнең илдә һәр бала
Уйнап-көлеп йөрсен дип,
Хәвеф-хәтәр күрмәсен,
Тыныч булып үссен дип,
Бик күп сугышкан бабам,
Дошманны җиңеп кайткан.
Үзе белән ул безгә
Тынычлык алып кайткан.

Эльмира Шәрифуллина

Батыр булам

Бабаем медальләрендә
Кояш нурлары уйный.
Аның шикелле үк, мин дә
Батыр булырга уйлыйм.
Ләкин сугышны яратмыйм,
Килми аны күрәсем.
Килми минем япь-яшь килеш
Яу кырында үләсем.
Бабама охшыйсым килә,
Хыялым ерак китә.

Хезмәт батыры булырмын,
Тынычлыкка ни җитә?!

Йолдыз

Картлар нигә шатлар?

Нәрсә булган?.. Тамаша,
Өлкәннәр көч сынаша!
Стадионда карт-коры,
Әби-бабайлар тулы.
Хәй бабай гер уйнта,
Вәли карт сөңге ата,
Нури бабай сикерә,
Әбиләр кет-кет көлә.
Әскап карчык туп куа,
Зәйнәп роликта шуа,
Бабайлар футбол уйный,
Мәрьям чәй белән сыйлый.
Дәү әтием калышмый,
Тиз-тиз чабып барышлый,
Әбиемә күз кыса,
Чәй әзерләргә куша...
Ah! Ура! Җиңде бабам,
Мин читтән кул чабам.
Менә бүләк, тантана,
Дәү әнием шатлана.
Сөенче, әй, сөенче! —
Хәй бабай да беренче!
Зәйнәп әби икенче,
Вәли бабай дүртенче!
Нәрсә соң бу? Ник шатлар
Озын гомерле картлар?
Безгә үрнәк күрсәтә,
Оныкларын кисәтә:
Сәламәтле — спортта,
Кала күрмәгез артта!

Ленар Шәех

Туган көн бәлеше

Томалап килде әти
Мунчабызның төннеген:
— Чабынып кына, улым,
Ята торган көн бүген!..
Арыды ул төзәтеп
Комбайн двигателен.
Алмагач ботагына
Элде юеш күлмәген.
Әни күренде шулчак,
Кулында — ап-ак чүмеч:
— Кара тиргә баткансың,
Мә, тәмләп салкын су эч!
Бәлешем пешеп ята...
Шәпләп мунча керегез,
Чыгып бетсен керегез,
Туган көнең ләбаса,
Соңламагыз, керегез!
Ә әтием елмаеп
Кочаклады әнине,
Башымнан сөйде мине:
— Туган көн килә, китә,
Басуда бодай көтә.
Урасым бар, сугасым,
Бу көнем әрәм үтә...
Кич җиткәндә әтием
Комбайнга җан кертте.
Әтинең туган көне
Ишегалдында үтте.
Инде мунча керәбез.
Бертуктамый көнозын
Эшләгәнгә күрә без,
Әни пешергән бәлеш
Тәмле булыр, беләбез!

Рәшит Бәшәр

Минем бабай

Минем бабай — кояштай,
Балкып тора күзләре.
Җанга май булып ята
Әйткән җылы сүзләре.
Ялкаулыкны сөймми ул,
Үзе шундый сәләтле.
Безгә дә гел өйрәтә
Әйбәт гореф-гадәтне.
Минем бабай — шәп бабай,
Безне шундый ярата.
Иң матур сүзләр әйтү
Тиеш аңа карата.
Озын гомерләр телим,
Бәхетле бул, бабаем.
Исәнлек-саулык бирсен
Алгы көндә Ходаем.

Вәсимә Хәйруллина

Энекәш кирәк миңа!

Сезгә рәхәт! Берегез дә
Минем хәлдә түгел сез.
Беләсезме, өйдә миңа
Кызык түгел, күңелсез.
Елыйсы да килә кайчак,
Уйлап ятам-ятам да:
Юк шул минем абыем да,
Юк шул минем апам да,
Сеңелем дә, энем дә.
Бергә-бергә уйныйсым
Бик тә килә минем дә.
Ә күршеләр гөр килә;
Уйныйлар-шаяралар.
Алар күп шул, күмәк шул,
Шуңа да шаян алар.
Бер иптәш кирәк миңа,
Энекәш кирәк миңа!

Яратыр идем мин аны,
Хәтта елак булса да.
Бакчага да илтер идем,
Хәтта ерак булса да.
Энем белән мин урамга
Уйнарга чыгар идем.
Әгәр мине тыңламаса,
Ничек тә чыдар идем.
Әтиләр бит ничә кабат
Алабыз дип алдыйлар.
Бердәнбер малайларына
Бер энекәш алмыйлар.
Күңелсез өйдә миңа,
Уенчык нигә миңа?!
Бергәләшеп уйнарга
Бер иптәш кирәк миңа.
Берәү генә булса да,
Ямьсез генә булса да,
Елак кына булса да,
Энекәш кирәк миңа!

Роберт Миңнуллин

Энем бар

Шатлыгым бар,
өем бар,
әнием-әтием бар.
Минем гармуным да бар,
гармун хәтле энем бар.
Энем мине ярата,
мине күрсә, гел көлә.
Еласамы?!
Еласа, ул
сызып кына җибәрә
гармун тавышы белән.

Рөстәм Мингалим

Ә синең кемең бар? Энеңме, сеңлеңме? Абыең яки апаңмы? Сез ничек яшисез? Үзең гаиләң турында сөйлә.

Минем гаиләм

Аш кашыгы — агачтан,
Чәй кашыгы — көмештән.
Җиз самавыр кайнап тора —
Суы — изге инештән.
Әбием һәм әнием
Безгә бәлеш пешергән.
Бәлеш уңган, күрәсең,
Өйгә тәмле ис тулган.
Әби-бабай, әти-әни,
Мин, нәни кыз, Наилә.
Менә нинди сокландыргыч
Безнең матур гаилә!

Зәкия Туфайлова

Әни

Көннәр якты булсын өчен, әни кирәк!
Йокы татлы булсын өчен, әни кирәк!
Җил-яңгырдан саклар өчен, әни кирәк!
Усаллардан яклар өчен, әни кирәк!
Ашлар тәмле булсын өчен, әни кирәк!
Дөнья ямьле булсын өчен, әни кирәк!

Роберт Миңнуллин

Дәү әнием

Әниемнең әнисе
Әбием була минем.
Әби генә түгел ул
Ул минем дәү әнием.
Ак ефәктәй чәчләрен
Ул тарап куя үреп,
Чисталыкка өйрәнәм
Мин дә аңардан күреп.
Мин бакчага киткәндә,
Озатып кала мине,
Кайтканда каршы ала,
Бигрәк тә әйбәт инде!

Кызыклы әкиятләр
Сөйли кичләрен безгә,
“Бәбкәм”, — диеп иркәләп
Эндәшә үзебезгә.
Күзлексез күрмәсә дә,
Таяксыз йөрмәсә дә,
Җитмеш яше тулса да,
Бик картайган булса да,
Тәмле ашлар пешерә,
Матур гөлләр үстерә,
Өебезнең нуры ул,
Барыбыздан олы ул.
Җылы оек, бияләй
Бәйли безгә көз җиткәч.
Мин дә аңа бүләкләр
Алырмын үсеп җиткәч.
Өйдә аны һәммәбез
Яратабыз, сөябез:
— Син бик кадерле безгә,
Озак яшә, — диябез.

Әминә Бикчәнтәева

Әбием

— Балакаем, — ди әби, —
— Алмакаем, — ди әби, —
Шикәрем син, балым син,
Иң кадерле җаным син.
Минем хөрмә җимешем,
Челтерәп аккан инешем...
Каян таба сүзләрен,
Тезә тәмле сүзләрен.
Мин алай әйтә белмим:
— Әбием, — дим. — Әбием!

Вәсимә Хәйруллина

Карт әби

Карт әбием күп эшләгән
Яшь чакта, бала чакта.
Машиналар булмаган ди,
Йөргәннәр бары атта.
Ул вакытта мичләр булган,
Якканнар бар да утын.
Лампа яктырткан авылның
Буралы һәрбер йортын.
Әби үз куллары белән
Урак урган, он тарткан.
Иярeп йөргән эсседә
Баласы аның арттан.
Сыер сауган, агач кискән,
Ашаган төрле үлән.
Мин хәзер ул үләннәрнең
Бик азын гына беләм.
Бигрәк батыр, тырыш булган
Карт әбием. Сокланам.
Ә мин бүген туңдырма һәм
Бургер белән тукланам.
Су ташымыйм әби кебек –
Агып тора краннан.
Атлар йөрми (хәтта берәү!)
Шәһәрдәге урамнан.
Пычкы тотып караган бар –
Ләкин озакка түгел.
Телефонга ашкына гел
Минем тынгысыз күңел.
Карт әбине мин дә күрдем,
Йөзгә кадәр яшәде.
Аның кадәр яшәрменме?
Фикерең ни? Әйт әле?

Дания Нәгыйм

Әби-бабай тәрбиясе

Гаиләдә әти-әни белән
Әби-бабай булса, ул бала,
Гомергә онытылмаслык, күркәм,
Иң кыйммәтле тәрбия ала.
Иртә белән әти белән әни
Эшкә китә, нарасый-бала,
Ходайның бирмеш көне буена
Әби-бабай янында кала.
Ир баланы инде бабай кеше
Төрле һөнәрләргә өйрәтә,
Ә кыз бала әбисе янында
Бәлеш серен сорап йөдәтә.
Ашар алдыннан кулларын юа,
“Бисмилла” әйтеп ашый башлый,
Туклангачтын, бала “Амин” белән
“Рәхмәт” әйтеп кузгала башлый.
Әби-бабай йогынтысында ул
Мәрхәмәтле, шәфкатьле була,
Аның тәрбияле булуыннан
Күңелләр шатлык белән тула...
Күркәм тәрбия алган баланың
Дөньялары бәхеткә тулыр,
Әби-бабай дөньядан китсәләр,
Ул аларга догачы булыр...

Нияз Бишбалта

— Әйе, һәркемгә дә әби-бабай тәрбиясендә булырга язсын! Әби-бабайга игътибарлы булырга, хөрмәт күрсәтергә онытмагыз!!!

Өлкәннәргә ышансаң...

Мин, өлкәннәр дөрес сөйли,
Дип уйлый идем элек.
Бабай: “Хезмәт яратам”, — ди...
Тик булмый әле белеп.
Мин аннан: “Сыбызгы ясап
Бир әле!” — дип үтендем.

Үтендем дә үтенгәнгә
Үзем бераз үкендем.
“Кибеттән алыйк, — ди бабай, -
Бераз гына көт әле....”
Ә үзе: “Хезмәт яратам”, —
Дигән була бит әле.

Агния Барто

Безнең гаилә

Без мактана алабыз:
Барысы биш малай без,
Барыбыз да бертуган,
Барыбыз да ир туган.
Безнең һәркайсыбызның
Сеңлесе дә бар әле.
Дәү әнине онытып
Торам икән, карале.
Әти белән әнине
Кушсак, ничәү булабыз?
Ник аптырап торасыз?
Ягез, тизрәк уйлагыз.
(***Тугыз кеше***)

Хәкимҗан Халиков

Гаиләдә иң кадерле һәм изге кеше — ул әни. Юкка гына әниләр турында матур шигырьләр һәм җырлар язылмагандыр. Син дә танышып чык әле.

Әнигә генә

Кар кешене ясап куйгач,
Өйгә кердем мин.
— Апам, әйдә, чыгып шуны
Күрче! — дидем мин.
— Эшем бар әле, үскәнем,
Көт бераз гына! —
Дип, тагын күмелде апам
Гөлләр артына.
Апамның гөл арасына
Нигә качканын,

Әни сизмәсен дип, юри
Китап ачканын
Әллә кайчан белдем инде,
Тик әйтмим генә!
Сигезенче март җиткәчтен
Күрерсез менә!
Апам матур җепләр белән
Чигә дә чигә.
Сер итеп әйттем мин аны
Әнигә генә!

Энҗе Мөэминова

Әнием

Әнием минем матур,
күзләре якты, көләч.
Шундый күңелле була
ул өйгә кайтып кергәч.
Мин елышам әнигә,
әни миңа елыша.
Битләре аның кайнар,
ә куллары йоп-йомшак.
Конфет та кирәк түгел,
кирәк түгел курчак та,
Чөнки мин әниемне
алдым инде кочаклап.

Ренат Харис

Бушлык

Өйнең эче яп-ялангач,
Белмимен әллә нигә.
Кайтып керәсе дә килми
Бүген бөтенләй өйгә.
Бөтен нәрсә үз урынында,
Тик җитешми әллә ни...
Әй, онытып торам икән:
Өйдә юк бүген әни!

Фәнис Яруллин

Әниемнең кызы юк бит

Әниемнең кызы юк бит,
Мин әнигә бер генә.
Кызы да юк, эше дә күп
Әнинең берүзенә.
Әниемнең кызы юк шул,
Мин булышам әнигә.
Аш пешерәм, җыештырам,
Кер юышам әнигә.
Магазиннан сөт апкайтам,
Ипигә дә йөгерәм,
Әниемнең кызы юк та —
Малае бар бер дигән.

Клара Булатова

Әнием

Син, әнием, минем өчен
Бу дөньяда бер генә.
Елмайганда йөзләреңнән
Бар өйгә нур бөркелә.
Тыңлап бишек моңнарыңны,
Елавым басылган бит.
Телем дә минем иң әүвәл
«Әннә» дип ачылган бит.

Заһирә Гомәрова

Иң матур җыр

Күгәрченнәр гөрләшәләр
Язгы кояш нурында.
Алар җырлый иң матур җыр
Минем әни турында.
Күрәсезме, букет итеп
Алсу нурлар бәйләмен.
Кояш котлый март аенда
Минем әни бәйрәмен.
Нинди булган, нинди уңган
Ул һәр эштә, һәр кайда!

Йомшак сүзе, күркәм үзе,
Нурлы йөзе елмая.
Йөрәгемнең иң түрендә
Иң кадерлем — әнием.
Яхшылыкта, матурлыкта
Үрнәк миңа әнием.

Җәвад Тәрҗеманов

Әни

Иң матур юллар —син йөргән юллар.
Иң тәмле сулар — син биргән сулар.
Иң йөмшак куллар — син сөйгән куллар.
Иң якты моңнар — син белгән моңнар.
Иң кайнар эзләр — син баскан эзләр.
Иң моңлы күзләр — син баккан күзләр.
Иң тугры сүзләр — син әйткән сүзләр.
Иң сабыр йөрәк — синең йөрәгең.
Иң талмас беләк — синең беләгең.
Иң изге теләк — синең теләгең.
Иң бөгелгән бил — ул синең билең.
Гөл сибелгән тел — ул синең телең.
Үч тотмас күңел — синең күңелең, Әни!

Фәнис Яруллин

Иң зур кеше

Күпне белгән кеше
Ул зур кеше була.
Күптән күпне белгән
Бик зур кеше була.
Бик зур кешегә дә
Тиң зур кеше була.
Әти-әнидән дә
Зуррак кеше
Булмый.
Шуны белгән кеше
Иң зур кеше була.

Рөстәм Мингалим

Ике әни

Кулларын чәбәкәй итеп,
Әйләнеп йөрибез өйдә.
“Әниебез икәү!” — дигән
Хәбәр салып Зәбидә.
Сеңлебезнең әйткән сүзе
Аңлашылып бетми һич.
Әнинең берәү-бердәнбер
Булганын беләбез ич.
Игътибар белән карагач,
Табышмакка төшендек.
Әнинең көзге икегә
Әйләндергәнен белдек!

Люция Әблиева

Әтием белән бергә

Әтием белән икәү
Без гел бергә йөрибез,
Бергә утын кисәбез,
Бергә карлар көрибез.
Язлар җиткәч, балыкка
Таң аткач ук барабыз,
Тота алмасак, әнигә дип
Сатып кына алабыз.
Әгәр барсак урманга,
Бергә җырлап алабыз,
Яшеренгән гөмбәне
Икәү эзләп табабыз.
Бергә ишкәк ишәбез,
Бергә кәрзин үрәбез.
Бик күңелле яшибез
Менә шуңа күрә без.

Әминә Бикчәнтәева

Җиләк кайда күп?

Әти, әни, мин — өчәү
Йөрибез аланда.
Җыябыз җир җиләк,

Үләнне аралап.
Җиләк бар аланда!
Яхшылап карале:
Очрый ул алда да,
Күренә янда да...
Шулай да җиләкләр
Күб(е)рәк табыла
Әтием янында,
Әнием янында!

Равил Фәйзуллин

Дустым, гаилә турында һәм гаилә кыйммәтләре турында әкиятләр, хикәяләр укып кит.

Өч угыл

Бер кешенең өч улы бар иде. Иң кечкенәләре Гали атлы икән. Аталары базардан өчесенә дә берәр алма алып кайтты. Алмалар бик пешкән, татлы, сусыл җимешләр иде. Берничә сәгатьтән соң аталары, балаларын янына чакырып: «Алмаларны нишләттегез?» — дип сорады.

Өлкән угълы әйтте: — Әти! Мин алмамны ашадым. Эчендәге орлыкларны җыеп куйдым. Бакчабызга чәчеп, алма агачы үстермәк буламын. — Яхшы иткәнсең, угълым! — диде ата.

Уртанчы угълы әйтте: — Мин алманы ашадым. Бик тәмле, татлы җимеш икән. Әтиемә Хак Тәгалә исәнлек бирсен дип дога кылдым. Атасы янә: «Яхшы иткәнсең, угълым!» — диде.

Өченче угълы Гали атасына карап әйтте: — Алманың яртысын ашадым. Атасы әйтте: — Яртысын нишләттең? Гали куркып, кызарып әйтте: — Күршебезнең угълы Вәли авырып ята. Барып, яртысын аңа бирдем. Бик куанды, дога кылды. — Бәрәкалла, угълым! Син бигрәк тә яхшы иткәнсең! — дип, атасы Галинең битеннән, күзләреннән үпте.

Дәрдемәнд

Әтисе белән улы

(Татар халык әкияте)

Бер игенченең кечкенә улы була. Бөтенләй бәп-бәләкәй малай була әле ул. Әтисе аны шундый ярата: улы дигәндә җанын да бирер иде менә! Әти кеше иртә таңнан кара кичкә хәтле кырда эшли. Аз гына буш вакыты булдымы, нәни улы янына йөгерә.

Нинаять, малай үсеп җитә. Ул хәзер инде һәр эштә әтисенә бер дигән ярдәмче була.

Көннәрдән бер көнне карт игенче кырга эшкә китә. Билгеле, үзе белән сөекле улын да ала инде бу. Иңнәренә авыр китмәннәр салып, бик озак бара болар. Бара торгач, карт алҗый башлый.

— Уф, арыдым, — ди ул. — Картаелган шул, тез буыннары тотмый. Булмаса, син мине азрак күтәреп бар, улым. Бераз ял итәрмен, аннары үзем дә барып җитәрмен.

Егет риза була. Алар шулай юлның тагын бер кадәресен узалар. Яшь игенче, кырыкмаса-кырыкка бөгелеп-сыгылып, көч-хәл белән тузанлы юлдан атлый, ә хәйләкәр карт аның җилкәсендә утыра икән.

Болай күңелсез бару картны туйдыра башлый.

— Әйт әле, улым, — дип сорый ул, — нинди кошчык пырхылдап узды ул куаклар арасыннан?

Улы моны бөтенләй ишетмәмешкә салыша. Аның саен:

— Ә анда, юл читендә, нинди агач үсә соң әле? — дип, әтисе улына нич кенә дә тынгылык бирми икән.

Бу сорауларны ишетеп, ачуы килеп барган егетнең кашлары җыерылып-җыерылып куя, ди.

Менә болар бер чишмә янына килеп җитәләр.

— Инде тукта, улым, су эчеп алыйм! — ди карт.

Егет, нидер мыгырданып, әтисен, он тутырылган капчыкны ыргыткандай, җиргә ташлый.

— Эч, әмма дә ләкин тизрәк селкен, әти!

Карт улына карап-карап тора да татлы салкын чишмә суын эчә. Аннары, көлемсери төшеп, болай ди:

— И улым! Син әле минем кебек бик тә кечкенә һәм җиңел чакта, ә мин нәкъ синең шикелле таза һәм көчле вакытта, без бу юлны икеләтә тизрәк үтә идек. Шуның өстенә, синең барлык сорауларыңа да җавап бирергә һәм теләкләреңне үтәргә дә өлгерә идем. Әйт әле, улым, шуны хәтерлисеңме син?

Оялуыннан егетнең битләре ут яна. Ә карт җиңел генә тора да, улына әйләнеп тә карамыйча, тиз-тиз атлап китеп бара.

Канатлы ай

Кич. Авыл тынлык куелыгына чумган. Үзе шундый җылы. Өйгә нич керәсе килми. Капка төбендәге утыргычта, кичке шәфәкъ матурлыгына хозурланып, әнисе белән нәни кыз Фирая сөйләшеп утыралар. Утыралар

дигәч тә, утыргычта әнисе генә утыра, ә Фирая аның итәгенә менеп кунаклаган.

Күк гөмбәзендә, учлап сибелгән энҗе-мәрҗәннәрдәй, йолдызлар җемелди. Аларның барысын да уздырып, түм-түгәрәк ай көмештәй нурларын җиргә сибә, гүя ул шулай Фираяны сөеп елмая. Айның ике ягында да аккош канатларыдай, нәфис каурый болытлар йөзеп йөри. Тулган, менә-менә канатланып очып китәрдәй тоела. Әнисенең итәгендә иркәләнеп утырган Фирая да, әлеге сихри күренештән әсәрләнеп, соклану тулган күзләрен күк гөмбәзеннән ала алмыйча:

— Әни, әни, әнием, кара әле! — ди. — Кара... әнә анда, күктә, аккоштай ак канатлы ай йөзә. — Талпына-талпына, нәни кулларын чәбәкли. — Канатлы ай!..

Әнисе дә айга карый.

— И-и-и кызым, рәхмәт төшкере! Искиткеч нурлы икән шул кичке ай. Гаҗәп икән. Кызлар шикелле елмая. Гомеремдә дә мондый айны күргәнем юк иде. Бәхеткә генә була күрсен мондый хозур, мондый матур күренеш, — дип, үз нәүбәтендә хыялый, күбәләктәй канатланган нәни кызына карап, нурлы айдай елмая.

Әйе шул, әниләр янында ай да канатлы.

Нәкыйп Каштанов

Әби белән онык

Бер әбинең оныгы булган. Кечкенә кызчык йоклаган да йоклаган. Әбисе бөтен эшне үзе эшләгән: кызчык өчен икмәк пешергән, өй җыештырган, юган, теккән.

Тора-бара әбисе картайган. Ул мич башына менеп яткан. Инде хәзер әби йоклаган да йоклаган. Ул арада оныгы үсеп җиткән. Әбисенә ул икмәк пешергән, өй җыештырган, юган, теккән.

Мәҗит Гафури

Әбиләрдә кунакта

Беркөнне әни миңа:

— Кызым, Гөлгенә, яратканым син генә, кил әйдә, киен әйдә, әбиләреңә барабыз, бүләк илтеп кайтабыз, — диде.

Мин бик шатландым. Шатлыгымнан җырлый да баш ладым.

— Барабыз, барабыз, әбиләргә кунакка!

Әни дә мин, без икәү, киттек әбиләргә, әбиләр бездән ераста торалар.

Безнең капканы чыгасың — бер, Маратлар капкасы — ике, Хәлимнәрнеке — өч, Гарифларныкы — дүрт, Асияләрнеке — биш. Ә аннан соң бик күп, бик күп капкалар бар.

Безнең урам белән туп-туры барасың, барасың да сулга борыласың. Аннары тагын барасың-барасың да уңга боры ласың. Аннары бер урамга борылып керәсең дә, кырыйдан бер йорт кала, икенчесен дә үтәсең, өченчесенә дә кермисең, дүр тенчесен дә узып китәсең, ә бишенче йорт — әбиләрнеке.

Беркөнне мин бик яхшы билгеләп кайттым. Аларның йорты каршында гына трамвай туктый. Бик билгеле урында безнең әбиләр йорты!

Әбиләр тора торган йорт бик зур. Түбәндә бер тәрәзә бар, аның өстендә тагын бер, аның өстендә тагын. Кул бармак ларының барысын да берәм-берәм бөгеп бетерәсең: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү... тәрәзәләренең очына чыга ал массың.

Әни әйтә:

— Әбиләрең бишенче катта торалар, — ди.

Без баскычлар буйлап шул бишенче катка атлыйбыз.

Берне менәбез, икене, өчне менәбез, дүртне, бишне. Бик күп баскычлар менсәк тә, әле без бары беренче катта гына. Ә безнең әбиләр бишенче катта торалар.

Ял итәбез дә тагын менәбез: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү... тагын бик күп баскычлар менәбез. Бу әле бары тик икенче кат кына. Ә безнең әбиләр бишенче катта торалар.

Тагын баскычның бер басмасы артта кала, ике басмасы, өч, дүрт, биш басмасы. Без әле бары өченче катта гына. Ә безнең әбиләр бишенче катта торалар.

Без тагын менәбез, тагын менәбез. Беренче катны менгәч ял итәбез, икенчене, өченчене, дүртенчене менгәч ял итәбез дә бишенче катка менеп җитәбез. Безнең әбиләр менә шушы бишенче катта торалар.

Анда ишекләр бик күп: берәү, икәү, өчәү, дүртәү, бишәү...

Ә ишек яңагында бер түм-түгәрәк әйбер бар, аның урта сында бер төймә дә бар, әни шул төймәне бармагы белән басарга тотынды. Бер мәртәбә басты, эчтә «чылтыр!» итте. Икенче мәртәбә басты — тагын «чылтыр!» итте, өченче мәр тәбә баскан иде, берәү:

— Кем бар? — дип сорады. Әни әйтте:

— Кызым Гөлгенә дә мин генә.

Ишек ачылды. Аннан әби килеп чыкты, ул көлә иде. Ул мине күтәреп алды.

— Ай, кызым Гөлгенәм килгән икән, бик сагындырдың, бер атНа бит инде сине күргәнем юк,— диде.

Без өйгә кердек.

Мин әнидән әкрен генә сорадым:

— Әни, атна нәрсә соң ул? — дидем мин. Әни әйтте:

— Җиде көн, — диде. — Дүрткә берне кушсаң — биш була бит. Бишкә берне кушкач, алты көн була, алты көнгә тагын берне кушсаң, җиде көн була. Менә шул бер атна инде.

Әби безгә чәй эчертте. Безне коймак белән сыйлады. Мин биш коймак ашадым. Әни биштән дә күбрәкне ашады.

Мин бер чынаяк чәй эчтем, әни өчне эчте, ә әби биштән дә күбрәк, җидедән дә күбрәкне эчте.

Без әбигә бүләгебезне бирдек. Алар кып-кызыл алмалар иде. Әби ике кулына икешәр алма тоткач та, өстәлдә әле та гын да биш алма калды. Барысы күпме булгандыр, мин бел мәдем. Биштән дә күп, җидедән дә күбрәк.

Аннары без өебезгә кайтып киттек, әби безне озатып калды.

Абдулла Алиш

Баланың ата-анасын сөюе

Ун яшьлек бала — Шәмсетдин, үз авылларында бер бай кешегә барып, үзенә хезмәт сорады.

Бай кеше моны хезмәткә алырга риза булды вә әйтте: «Ярар, мин сине хезмәткә алырмын, көтү көтәрсең һәм, әгәр син яхшы хезмәт итсәң, аена алты тәңкә бәһа куярмын».

Шәмсетдин моңар каршы: «Ярар, мин кулымнан килгән хезмәтне кызганмам, ләкин син минем айлык бәһамне һәр атна саен бүлеп бирерсең. Чөнки өебездә әткәем, авырып ятканлыктан, эшли алмый, шул сәбәптән һәр атна саен аңар ризыкланырлык акча алып кайтып бирәсем килә», — диде.

Бай кешегә сабый бала Шәмсетдиннең атасына бу кадәр саф мәхәббәт кыйлуы бик ошады. Ул, Шәмсетдиннең сүзенә «баш өсте» дип разый булуы өстенә, аның айлык бәһасен дә арттырды.

Ике кыз

(Татар халык әкияте)

Борын-борын заманда яшәгән, ди, карт белән карчык. Аларның ике кызы булган. Олы кызлары усал да, ялкау да, саран да икән. Шуның өчен аны беркем дә яратмаган. Кече кызы үги булган. Аның уңганлыгына, аның булганлыгына кешеләр сокланып туя алмаганнар. Үги ананың моңа бик эче поша икән.

Көннәрдән бер көнне карчык иренә әйткән: «Урманга алып барып адаштыр ул кызыңны!» — дигән. Карт, ат җигеп, кызын урманга алып киткән. Барып җиткәч: «Бар, кызым, син җиләк җыя тор, мин бераз утын әзерлим», — дигән. Кыз, җырлыйжырлый, җиләк җыярга керешкән:

Җиләк җыям, как коям
Әниемә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк микән?

Җыйган-җыйган да кыз, тырысы тулгач, әлеге урынга килсә, атасы юк, ди. Ары сугылып, бире сугылып йөри торгач, бик арыган, бик талчыккан кыз һәм бер каен төбенә тамак ялгарга утырган. Үги әнисе биреп җибәргән бер телем икмәкне чыгарып ашыйм гына дисә, моның янына Куян килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым түтекәй,
Бирче азрак ипекәй, — дигән Куян.

Кыз аңа икмәген бүлеп биргән. Куян икмәк сыныгын тәмләп кенә ашап куйган да: «Яхшылыкка — яхшылык», — дип, аңа куян бүреге китереп биргән.

Куян киткәч, икмәген ашыйм гына дисә, Төлке килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй, — дигән Төлке.

Кыз аңа да икмәген бүлеп биргән. Төлке икмәк сыныгын тәмләп кенә ашап куйган да: «Яхшылыкка — яхшылык», — дип, аңа төлке туны китереп биргән.

Төлке киткәч, икмәген ашыйм гына дисә, Бүре килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,
Бик ачыктым, түтекәй,
Бирче азрак ипекәй, — дигән Бүре.

Кыз аңа да икмәген бүлеп биргән. Бүре икмәк сынығын тәмләп кенә ашаган да: «Яхшылыкка — яхшылык», — дип, кызга бүре туны китереп биргән.

Бүре киткәч, икмәген ашыйм гына дисә, Аю килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,

Бик ачыктым, түтекәй,

Бирче азрак ипекәй, — дигән Аю.

Кыз аңа да икмәген бүлеп биргән. Аю икмәк сынығын тәмләп кенә ашаган да: «Яхшылыкка — яхшылык», — дип, бер тәпән бал китереп биргән.

Аю киткәч, икмәген ашыйм гына дисә, Көтүче килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,

Бик ачыктым, түтекәй,

Бирче азрак ипекәй, — дигән Көтүче.

Кыз аңа да икмәген бүлеп биргән. Көтүче икмәк сынығын тәмләп ашаган да: «Яхшылыкка — яхшылык», — дип, бер көтү мал куып китергән.

Көтүче киткәч, калган икмәк сыныкларын кабып җибәрим генә дисә, моның кулбашына Сандугач килеп кунган.

Бик талчыктым, түтекәй,

Бик ачыктым, түтекәй,

Бирче азрак ипекәй, — дигән Сандугач.

Кыз учыннан аңа калган икмәк валчыкларын чүпләткән. Сандугач икмәк валчыкларын тәмләп кенә чүпләп бетергән дә:

«Яхшылыкка — яхшылык, нинди теләгең бар, түтекәй, хәзер үтим», — дигән. Кыз әйткән: «Минем өйгә кайтасым килә, әткәемә генә барып хәбәр салчы, Сандугачым», — дигән.

Кош очып киткән. Ул, авылга җитеп, аларның өй каршындагы агачка кунып:

Чут, чут, чут,

Түтәйнең маллары күп,

Килеп алучы юк, юк, —

дип сайрарга тотынган.

Атасы моны ишеткән һәм, атын җигеп, урманга киткән.

Кызның бөтен байлыкларын төяп, көтүләрне куып алып кайтканнар. Үги әни, моны күреп, ачуыннан нишләргә белми, ди.

«Үз кызыңны баеттың, инде минем кызымны да бает, урманга алып барып адаштыр!» — дип, картына бәйләнә икән.

Карт ат җигеп, бу кызны да урманга алып киткән. Барып җиткәч: «Бар, кызым, син җиләк җыя тор. Мин бераз утын әзерлим», — дигән. Кыз җиләк җыярга тотынган. Бер җиләкне савытка, өч җиләкне авызга салып йөри-йөри, тырыс төбе каплангач, әлеге урынга килсә, атасы юк, ди. «Әйдә, ярар, монда гынадыр әле, мине ташлап әллә кая китә алмас, югыйсә әнием аның кирәген бирер», — дип уйлаган кыз һәм каен төбенә ашарга утырган. Әнисе җибәргән төргәкне чишеп, нигъмәтләрне җәеп куюы булган, моның янына Куян килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,

Бик ачыктым, түтекәй,

Бирче азрак ипекәй, — дигән Куян.

«Кит! Сиңа түгел, үземә дә аз әле монда!» — дигән кыз һәм таяк белән башына суккан. Куян ачу итеп, кызның күлмәген ертып, җиләген түгеп киткән.

«Их, котылдым бу арык Куяннан!» — дип уйлаган кыз һәм тынычлап ашый гына башлаган икән, Төлке килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,

Бик ачыктым, түтекәй,

Бирче азрак ипекәй, —дигән Төлке.

«Кит! Сиңа түгел, үземә дә аз әле монда!» — дигән Кыз һәм Төлкенең башына таяк белән суккан. Төлке ачу итеп, кызның яулыгын ертып, тырысын тетеп киткән.

«Их! Котылдым бу ач Төлкедән! — дип уйлаган кыз һәм тынычлап ашый гына башлаган икән, Бүре килеп чыккан.

Бик талчыктым, түтекәй,

Бик ачыктым, түтекәй,

Бирче азрак ипекәй, — дигән Бүре.

«Кит! Сиңа түгел, үземә дә аз әле монда!» — дигән кыз һәм Бүренең башына таяк белән суккан. Бүренең моңа бик каты ачуы килгән һәм кызны кабып йоткан, ди.

Бу вакытта карт өйдә икән. Карчыгы: «Бар инде, кызым баегандыр, тизрәк алып кайт!»— дип әрләшә, ди. Карт атын җигеп урманга барса, кызы юк. Тетелгән тырысы гына җирдә аунап ята, ди. Карт шуны арбасына салып кайтып киткән. Ишегалдына килеп кергәч, карчыгы йөгереп чыккан. Арбада кызының тетелгән тырысын күргән һәм хурлыгыннан егылып үлгән, ди.

Үги кыз әле дә булса матур гына гомер итә, ди.

Өч кыз

(Татар халык әкияте)

Борын-борын заманда булган икән, ди, бер Хатын. Аның булган, ди, өч кызы. Бу Хатын, кызларымның өсте бөтен, тамаклары тук булсын, дип, көне-төне эшләгән, ди.

Менә кызлар үсеп буйга да җиткәннәр. Алар берсеннәнберсе матур, ди, бер битләре ай, бер битләре кояш, буй сыннары карлыгачтай сылу, ди. Өч кыз, бер-бер артлы кияүгә чыгып, берсе артыннан берсе китеп тә барганнар.

Менә бер ел үткән, ике ел, өч ел үткән. Шулай матур гына яшәгәндә, әниләре авырып киткән. Күрше урманда Тиен дусты бар икән, шуны дәшеп әйткән:

— Тиен дустым, барсана, кызларыма әйтсәнә, хәлемне белергә килсеннәрче, — дигән.

Тиен шунда ук чыгып чапкан. Тиен барып тәрәзә какканда, Олы кыз җиз ләгәннәр чистартып торадыр иде, ди.

— Һай, — дип әйткән, ди, Олы кыз, — бик барыр идем дә бит, аңарчы менә шушы ләгәннәрне чистартып бетерәсем бар иде шул, — дигән, ди.

Тиен моңа бик ачуланган да әйткән:

— Алайса, син шушы ләгәннәреңнән мәңгегә аерылма! — дигән.

Тиеннең шулай дип әйтүе булган, ике ләгән кызны ике яктан китереп тә кысканнар.

Олы кыз егылган да шунда ук гөберле бакага әверелгән.

Тиен Уртанчы кызга чапкан. Уртанчы кыз, бу кайгылы хәбәрне ишеткәндә, киндер суга икән. Тиенгә әйткән:

— Һай, — дигән, ди, — әнием янына хәзер үк чыгып йөгерер идем дә бит, менә ярминкәгә киндер сугып өлгертәсем бар иде шул, — дигән.

Тиен бик ачуланган да әйткән:

— Алайса, син гомерең буе киндер сугып кына тор! — дигән.

Уртанчы кыз шунда ук үрмәкүчкә әверелгән.

Тиен тәрәзәсен какканда, Кече кызның камыр баскан чагы икән. Ул бер сүз дә әйтмәгән, камырлы кулларын да сөртеп тормаган, чыккан да әнисе янына йөгергән.

Тиен Кече кызга әйткән:

— И сөекле бала, гомер буе игелек күр, кешеләрне бәхетле ит, аларга куаныч та, юаныч та бул. Кешеләр дә сине сөярләр, синең яхшылыгыңны мәңге онытмаслар, — дигән.

Кече кыз, чыннан да, бик рәхәт гомер кичергән, халык аны бик яраткан, ди.

Хәйләкәр чегән малае

(Чегән халык әкияте)

Әниләре балаларын чакырып алган да:

— Кемгә аш салып бирим? — дип сораган.

— Миңа! — дип кычкырып җибәргән өлкән улы. — Миңа күбрәк сал! Бик ашыйсым килде.

Балалар чөгендер шулпасын ялт иттереп куйганнар. Шуннан әниләре алардан

— Кемгә ботка бирим? — дип сораган.

— Миңа, миңа ботка! — дип янә кычкыра башлаган өлкән улы.— Күбрәк сал, әни, яме!

Балалар ботканы да сыптырып куйганнар. Инде әниләре сорый икән:

— Йә, кайсыгыз ат көтәргә бара?

— Без, без! — дип кычкырышалар балалар, абыйлары исә дәшми тора икән.

— Ә син ник дәшмисең, улым? — дип сораган өлкән улыннан әнисе.— Ашаганда барысыннан да күбрәк ашадың, эшкә дигәндә, авызыңа су капкандай торасың.

— И, әни, — дип үпкәләп җавап биргән өлкән улы. — Мин ике эшеңне дә башкаларга караганда күбрәк эшләдем, инде өченчесен дә миңа кушарсыңмы тагын?

Әлифба

Бер бала атасына:

— Әти, син үзең күзлек киеп китап укыйсың бит, миңа да бер күзлек алып бирсәнә, мин дә китап укыр идем, — диде.

Атасы:

— Ярар, угылым, мин сиңа күзлек алырмын, ләкин ул балалар күзлеге генә булыр, — дип, угылына бер әлифба китабы алып бирде.

Габдулла Тукай

Канатларың булса...

Бер кечкәнә кыз кошларның канатлы булуына кызыгып яшәгән.

— Ник минем канатларым юк икән? — дигән бу кыз әнисенә.

— Кошларның канатына кызыгасыңмы? — дигән әнисе.

— Әйе, бик кызыгам, — дигән кыз.

— Канатың булса нишләр идең, балам? — дигән әнисе. — Әллә очып китәр идеңме? Мине калдырып.

— Очып китәр идем дә... Очып кайтып та җитәр идем, сине сагынып, — дигән бу кыз.

Әнисе кызын кочагына алган. Кыз да әнисен кочаклаган.

— Канатларың булса, кулларың булмас иде. Син мине болай кочаклый алмас идең, кызым, — дигән әнисе.

Кыз шунда әнисен тагын да кысыбрак кочаклаган. Моннан соң ул кошларның канатлы булуына да кызыкмаган. Аларга ул бик яратып карый, кызганып та куя икән. Үзенең бердән-бер әнисе, әнисен кочакларга ике кулы булганы өчен шатланып яши, ди.

Рөстәм Мингалим

Шук йомгаклар

(әкият)

Йомгаклар үзара сөйләшә башлаганнар, ди.

Әби җеп эрли икән. Эрли дә йомгакка урый, эрли дә йомгакка урый һәм шкаф өстенә куя, ди. Шулай итә торгач, йомгаклары күбәеп киткән моның. Алар үзара сөйләшә башлаганнар.

— Мин йомгак, мин җылы бияләй булам, — дигән берсе.

— Ә мин — оекбаш, — дигән икенчесе.

— Мин җылы башлык булам, — дигән өченчесе.

— Мин шарф булам! — дигән дүртенчесе.

Тик әби һаман эрләгән, бәйләргә ашыкмаган. Йомгаклар бер урында озак тора алмыйча тыпырдаша башлаганнар һәм кайсы кая — берсе — карават астына, берсе — шкаф эченә, берсе исә почмакка кереп качкан. Ә иң шук йомгак исә өстәл өстенә менеп киткән.

Шкаф өстендә йомгаклар янында йокымсырап яткан, үзе дә йомгактай песи баласы күзләрен елтыратып шук йомгак артыннан сикереп өстәл өстенә менгән. Йомгак тагын шкафка менгән, аннан идәнгә төшкән, песи баласы да аның белән бергә сикерә-сикерә уйнарга тотынган. Шулай сикереп арыгач, әбинең алдына ук менеп утырган һәм ашарга сорап мырлый башлаган.

Әби җеп эрләвеннән туктап, аларны берәм-берәм җыеп алган һәм оныгына берсеннән оекбаш, берсеннән бияләй, берсеннән башлык, ә берсеннән шарф бәйләгән. Ә оныкка эләксәң, күңелсезләнергә һич тә мөмкин түгел инде. Ул аларны песи баласыннан да ныграк сикертә-сикертә уйнаган. Оекбашка, бияләйгә, башлыкка, шарфка бер дә күңелсез булмаган.

Сәмига Сәүбанова

Ана йөрәге

Танылган риваятькә нигезләнеп язылган әкият.

Яшәгән, ди, бер егет. Аның сөйгән кызы булган. Бу ике яшь йөрәкнең бер-берсенә мәхәббәте җырларга салырлык, риваять-легендаларда сөйләрлек матур һәм көчле булган.

Ләкин кара эчле, хөсетле бәндәләр егетнең сөйгәнен кара сихер белән сихерләгәннәр, һәм кыз беркөнне, кечерәеп, уймак кадәрле генә булып калган. Никах мәҗлесенә әзерләнеп йөргән егет кара кайгыга баткан. Бөтен тирә-юньнән сихер кайтаручы имчеләрне эзләтә башлаган. Ниһаять, табылган шундый карчык. Ул бу кызны элеккеге рәвешенә кайтарырга риза булган. Егеткә:

— Әниеңнең йөрәген алып китер, шуның бәрабәренә сөйгәнеңне кеше кыяфәтенә кайтарырмын, — дигән.

Егет сөйгәнен бик нык яраткан булган шул... Әнисе янына киткән. Әмма аңа бу хакта әйтергә кыюлыгы җитми тора икән. Улының борчылып йөрүен күргән ана үзе сораган:

— Улым, башыңа нинди кайгы төште? Нигә болай боек йөрисең? Берәр хәлгә дучар булмагансыңдыр бит?

Егет әйтергә мәҗбүр булган:

— Бәхетем бәрабәренә синең йөрәгеңне китерергә куштылар, әнием...

Ана кеше озак уйлап тормаган.

— Мә, балам, ал йөрәгемне, синең бәхетең өчен йөрәгем дә кызганыч түгел, — дигән.

— Юк, әнием, — дигән егет. — Мин синең йөрәгеңне бәхетемә алыштыра алмыйм.

Ана, үз баласының бәхетсезлеген күреп, бик борчылган һәм булачак киленен бөтен җан тылсымы, изге теләк-догалары белән имли-өшкерә башлаган. Кыз шунда ук үз хәленә кайткан.

Егет имче карчык янына килеп, аны ачуланган:

— Мин синең өчен әниемнең йөрәген ала яздым, юньсез карчык! — дигән.

— Хаксызга ярсынма, улым. Анаң, чыннан да, сиңа үз йөрәген бирде. Әмма сихри өмет-хыяллар, изгелек, илаһи мәхәббәт рәвешендә бирде ул аны. Ә син, шуны аңламыйча, анаңны харап итә яздың. Мин сиңа шуны аңларга ярдәм иттем.

Егет моңа каршы ни әйтергә дә белмәгән, оятыннан җир тишегенә кереп китәрдәй булган. Кереп тә киткән булыр иде, тик аның әнисе һәм сөйгәне белән бәхетле гомер кичерәсе бар шул.

Галимҗан Гыйльманов

Алтын балык

Әтисе, Сәйдәшне ияртеп, балык тотарга китте.

— Әтием, — диде Сәйдәш, — безнең кармакка Алтын балык эләгерме?

— Алтын балык әкияттә генә була, — диде әтисе.

— Ә үзең, — дип эләктереп алды Сәйдәш, — әкият тормыштан алып языла, дисең.

— Элек, — диде әтисе, яхшылап аңлатырга тырышып, —матур, алтынсыман балыклар күп булган...

— Элек булган, ни өчен хәзер беткән? — дип төпченде Сәйдәш.

— Ул суның чисталыгана бәйле, улым. Нәзберек, затлы балыклар пычранган, тынчыган суда яши алмый. Шуңа күрә кайбер балыклар хәзер бөтенләй юкка чыккан.

— Алтын балык тамы?

— Алтын балык та.

— Киләчәктә «Алтын балык турында әкият» тә булмасмы?

— Әкияте булыр...

Әти кеше бераз уйланып торды да:

— Әгәр син, зур үскәч, күп итеп чәчәкләр, агачлар утыртсаң, олы абыйлар елга-күлләргә агулы калдык-постык, әшәке чүп-чар ташламаса, алтын балыклар, бәлки, терелер, — дип җавап бирде.

— Ә мин чәчәкләрне хәзер үк утырта алам. Минем көчем күп, менә кара... — диде ул, ашыгып. Әтисенә беләкләрендәге мускулны күрсәтте. Шатлыгы хәрәкәтләренә, тавышына күчте.

— Әкрен, улым! Балык тотканда тавышланырга ярамый, — диде әтисе.

Алар күп кенә балык тотты.

Өйгә кайткач, чәчәк орлыкларын кайдан алу, кайда утырту турында да сөйләште алар. Кич белән бер-берсенә хәерле төн теләп йокларга яттылар.

...Төшендә Сәйдәш янына Алтын балык йөзеп килде.

Дөресрәге, ул чын алтынсу төстә түгел. Җитмәсә, бик күңелсез иде. Сәйдәш аңа үзе үстергән кашкарый чәчәкләрен бирде. Кашкарый чәчәкләре ал, кызыл, сары, зәңгәр, шәмәхә, алтынсу төстә иде. Алтын балык чәчәкләрне алды. Сәйдәшкә рәхмәт әйтте. Һәм Сәйдәш бүләк иткән кашкарый чәчәкләреннән күз ачып йомганчы такыя үреп киде. Иң алга алтынсу төстәгеләрен куйды. Алтынсу төстәге кашкарыйлар ялык-йолык килә. Алардан төшкән нур балыкны да алтын төскә мана...

— Алтын балык терелде, Алтын балык терелде!.. — дип кычкырып җибәрде Сәйдәш, йокысыннан тора-торышка. Һәм тиз генә әтисе янына килде.

— Әти, әтием, мин Алтын балыкны коткара алам! — диде ул, үзенә нык ышанып. — Безгә кашкарый чәчәкләре утыртырга кирәк. Бүген үк, хәзер үк! Аның чәчәкләре алтынсу төстә булырга тиеш!..

Әтисе кечкенә Сәйдәшне, күтәреп, күкрәгенә кысты.

Битләреннән үпте дә:

— Бик матур төш күргәнсең, ахры, улым! — диде.

Эльмира Шәрифуллина

Өстәл янында

Без энем Равил белән бик тату уйныйбыз. Ат-ат уйнаганда энем ат була, мин дилбегә тотам. Энем чапканда егылмасын дип, дилбегәне каты тартмыйм. Равил бик каты йөгерергә ярата. Ул башын артка чайкалдырып чаба, гел яхшы ат кебек. Без чирәмле җирдә генә уйныйбыз, юл уртасында бер дә уйнамыйбыз. Әнием анда уйнарга кушмый. Анда машиналар йөри, ди. Йөгереп уйнап арыгач, өйгә ашарга керәбез. Бик әйбәтләп кулны юабыз. Кул сөртергә икебезнең дә кечкенә сөлгебез бар. Равил сөлгесендә чия, минекендә алма рәсеме чигелгән. Кечкенә апам чигеп бирде. Без урамнан пычранып кайтсак, түргә дә уздырмый ул. Юынып керегез, ди. Безнең зур апабыз да бар әле. Ул инде сигезенчедә укый. Кечкенә апабыз — Сәлимә исемле. Дәү апабыз — Хәлимә. Дәү апа һәрвакыт аш өстәлен әзерли. Кечкенә апа безнең өстәл янында ничек утыруыбызны тикшереп кенә тора. Әнием белән әтием өйдә булганда, безнең барыбызны да күзәтеп торалар.

— Өстәл янында тыныч кына утырып ашагыз, дәү үсәрсез, — ди әтием. Әнием дә шулай ди. Дәү апа белән кечкенә апа да шулай әйтергә өйрәнеп беткәннәр. Равил дә, мин дә аларның сүзен бик тыңлыйсыбыз килә. Тик кайчагында тик кенә утырып булмый. Шул чагында дәү апа кара чия төсле күзләре белән безгә туп-туры карый. Кечкенә апабыз тиз генә җиңебездән тартып куя.

— Тик кенә утырыгыз инде, — ди. Үзе әле әтигә, әле әнигә карый. Апаларым бөтенләй тәртипкә өйрәнеп беткәннәр. Әти дә, әни дә аларны ачуланмый. Без дә кечкенә түгел бит инде. Равил дүрттә, мин алтыда. Ә безнең шаярасы гына килеп тора. Мин Равилнең кашыгын алам да әкрен генә аның башына сугам. Дәү апам урыныннан тора да минем кашыкны алып куя.

— Авырттырмадым ич, уйнап кына, әкертен генә, — дим. Равил дә үпкәләми, елмая. Ә шулай да мине шелтәлиләр.

— Кашык ашар өчен куелган, аның белән чәч тарамыйлар, — ди әнием. Кайвакыт Равил өстәл астыннан минем аякка төртә. Мин дә аңар тибеп куям. Шаяра торгач, өстәлдә тәлинкәләр селкенә башлый.

— Болай шаярсагыз, мин сезне циркка алып бармам, — ди әтием. Без бер вакытта туктап калабыз, шаярмаска сүз бирәбез. Менә аш артыннан әнием өстәлгә карбыз китерә. Карбыз утлы күмер кебек кып-кызыл. Үзе бер дә эссе түгел, сап-салкын, үзе шикәрле. Безнең алдыбызга әнием карбыз телемнәре куя. Мин Равилнең карбызына карыйм да:

— Минем кечкенә, Равилнеке зур, — дим. Равил кулындагы карбыз телемен миңа бирә.

— Мә, апам, дәүрәге сиңа булсын. Минем карбызым кечкенә булса да, үзем зур буласым килә. Ә сиңа зур карбыз булсын. Үзең кечкенә булып калырсың, — ди Равил. Миңа бик-бик оят була. Әтием дә, әнием дә, апаларым да Равилне мактап башыннан сөяләр.

Әминә Бикчәнтәева

Заманча ноу-хау

Азатның беркайчан да шултикле почмакта басып торганы юк иде — 4 сәгать торды, ык та итмәде. Итәрсең монда! Чиреккә әдәбияттан чыгасы «2»ле өчен өйдәгеләр тарафыннан бирелгән иң җиңел җәза иде бу. Әтисе янәшәдә генә компьютердан ниндидер эшлекле семинарда катнашты, тавыш-тыныңчыкса, башкача сөйләшербез, дип йодрык кына күрсәтте.

Почмакта торуның да файдасы булды үзе — тормыш өчен кирәкле әллә нинди заманча ноу-хаулар ясап яталар икән дөньяда. Әтисенең семинары нәкъ шул хакта иде. Ясалма фәһем, ягъни нейрочелтәр дигән яңа табыш рәсемен дә ясый, мисалын да чишә, хәтта үзе китап та яза башлаган, ди. Азатның исе-акылы китте. Әти-әнисе чәй тирәсендә кайнашканда, гаилә башлыгының ачык калган ноутбугыннан видеоларны үзенә йөкләп алды да бер төндә барысын да өйрәнеп чыкты. Планнар зурдан иде!

Белем файдалы булсын өчен, аны тормышта кулланырга кирәк, ди әтисе. Менә Азат та тизрәк кулланып карарга булды. «2»ле чәпәргә торган Энҗе Фарисовнага ялларда беренче нейрохат язып салды: «Азатыбыз «2»ле өчен бик борчылды, инде ашамас булды». Дәрестә узган соңгы темаларны шартлаттырып сөйләгән видеосын да беркертте. Анысы бигрәк уңайлы икән — теләсә нинди видео йөкләп, китап текстын программага кертәсең дә теге нейрочелтәр дигәннәре синнән коеп куйган вундеркинд ясый да куя...

Озак та үтмәде укытучыдан: «Гафу итегез, баланы ача алмауда минем гаеп бардыр», — дигән җавап килде.

Шушы көннән Азат юлында очраган һәркемне телефонына төшерә-яздыра башлады — ясалма фәһемне шуннан башка эшкә җигәм димә!

Күптән ачуын китергән отличник Ландыш нейрочелтәрнең икенче корбаны булды, Азат аңа директор исеменнән видеосәлам юллады:«Мәктәп диварындагы «Безнең горурлык» стендыннан синең фоторәсемне алып куярбыз дип торам. «5»легә уку гына җитми, киң күңелле, кешелекле дә булырга кирәк. Сыйныфташың Азат тагын бер ел утырып калырга тора, ә син эгоистларча һаман үзең өчен генә тырышасың. Йомшаграк иптәшләреңә булышырга кирәк». Шул көннән Ландыш Азатка бөтен өй эшләрен күчертә, контроль эшләрдә аныкын да эшләп бирә башлады...

Азатның бар дөньясы 180 градуска үзгәрде дә куйды — отличник булырга да күп калмады монда! Ә беркөнне, көтмәгәндә-уйламаганда, мәктәпнең игъланнар тактасында яңа бәйге турында мәгълүмат барлыкка килде. Мәктәп турында иң шәп әкият язучыга бүләккә — соңгы айфон, ди. Бер генә түгел, дистәләгән матур әкият яздырды Азат нейрочелтәргә. Һәм барысын да уптым-илаһи шул ук көнне конкурс почтасына юллады. Җавап хаты да көттермәде: «Сез — абсолют җиңүче! Бүген 14.00 сәгатьтә директор кабинетында көтеп калабыз».

Директор кабинетына керер алдыннан янә телефонын кабызды Азат — гомердә беренче тапкыр бәйгедә җиң дә, тантананы телефонга төшермә ди инде! Әниләре ышанмас тагын! ...Тик видеоязмалар кирәк булмады — директор бүлмәсендә өйдәгеләр дә, отличник Ландыш та, укытучы апасы, хәтта полиция хезмәткәре дә утыра иде. Имәндә икән чикләвек дип уйлап, тизрәк таярга ымсынган иде, әтисенең чытырдатып кыскан йодрыкларын күргәч, коелды да төште. Бүген өйдә малайны яңа «тәрбияви ноу-хаулар» көтәчәге көн кебек ачык иде...

Алинә Бикмуллина

Мыеклы «фәрештә»

Ришат уеннан һәрвакыт караңгы төшкәч кенә кайтып керә. Дөресрәге, аны дәү әнисе табып алып кайта. Шунсыз булмый, кечкенә Ришат, уен белән мавыгып, караңгы төшкәнне дә, йоклар вакыт җиткәнне дә сизмичә кала. Бүген дә дәү әнисе чакырып алганда аның иптәшләреннән аерыласы килмәде.

— Дәү әни, әкрен генә кайтабыз, яме.

Ришат, бер кулы белән дәү әнисенең куштан итәгенә ябышып, чак кына артка калган килеш, каерылып күккә карап бара. Әнә, өй янында бер йолдыз да кабынды.

— Дәү әни, дәү әни дим! Ә йолдызларны кем яндыра? Кем анда ут кабызып йөри?

Дәү әнисе туктап хәл алды:

— Фәрештәләр яндыра, балам, фәрештәләр.

— Ә синең фәрештәне күргәнең бармы, дәү әни?

— И-и, балам, шулай сөйләргә ярыймыни? Күзгә күренеп йөрми алар!

Ришат тагын нидер әйтмәкче булып авызын ачкан иде, өйгә кайтып җиткәннәр икән.

— Ник ут алмадылар соң болар, — дип сөйләнә-сөйләнә, дәү әнисе оныгын ияртеп өйгә керде. Ришатның әнисе белән мыдыр-мыдыр нидер сөйләшеп алдылар да, әби малайга ни булганын аңлатып бирде:

— Иликтырның әллә кай төше бозылган ди. Әтиең шуны төзәтүчене чакыра киткән.

Ул арада ишектән кемнәрнеңдер кергәне ишетелде. Әтисе калын тавышлы бер абый белән кайткан.

Нәрсәдер эшләделәр шунда, караңгы булгач Ришатка күренмәде. Кинәт лампочка гөлт итеп кабынып китте. Ришат утны кабыза алган абыйның үзен дә күреп алды. Кап-кара мыеклы, дәү итекле. Малай аңа күзләрен зур ачып карап торды, йөзе олыларныкы кебек җитди, тик авызын гына ябарга оныткан, кулларын әтисе кебек артка чалыштырып, түшен киереп, аякларын аерып басып тора. Кара мыеклы абый аны шаяртып, үчекләп алды, Ришат йөгереп барып дәү әнисенә сыенды. Алай да сорап куйды:

— Ә син йолдызлар да кабыза беләсеңме?

— Беләбез, улым, без булдырмаган эш бармыни! — диде абзый, күзен кысып. Саубуллашып, малайга кулын бирде. Ишек ябылгач, Ришат әбисенең колагына пышылдады:

— Мин фәрештәне күрдем. Ә син, күренмиләр, дисең...

— Ниткән сүз ул? Кайчан күрдең син аны?!

— Озын мыеклы, калын тавышлы, итеге дә зу-ур... Утлар кабызып йөри!

Дәү әнисе яулык чите белән ирен почмагын каплап, кеткелдәп көлүдән башка берни дә әйтә алмады.

Ләлә Сабирова

Кем тизрәк үскән?

Матур, кояшлы яз. Кечкенә Фәритнең әтисе — бакчачы. Ул бакчасына помидор, кыяр, шалкан, кәбестә һәм тагын әллә нинди яшелчәләр утырта.

Менә кәбестә үсентеләре. Әтисе аларны рәт-рәт итеп утыртып бара, әнисе аңа ярдәм итә, Фәрит кечкенә чиләк белән кәбестә утыртасы чокырларга су сибә. Әтисе моңа бик шат. Алар кәбестәне кичке якта утырталар — кояш көйдереп алмасын үзләрен. Эшләрен бетергәч, күтәрелеп карасалар, кәбестә үсентеләре матур булып, рәт-рәт тезелеп утыра! Аларның үсәселәре килә. Әнисе шунда:

— Улым, кем тизрәк үсәр икән: синме, әллә кәбестәләрме? — дип шаярта. Фәритнең дә, тиздән үсеп, әтисе кебек бакчачы булырга теләвен белә ул.

Фәрит, әти-әнисенә карап:

— Кәбестә, — дип елмая. — Көз килер, күрербез диген, улым, — ди әтисе. — Алдан кычкырган күкенең башы авырта, ди халык.

Фәрит кәбестәләргә көн дә су сибә. Көндез кәбестәләр кояшка елмаеп карыйлар, һаман кояш нурларына сузылалар. Кояш аларны алтын нурлары белән иркәли. Кайчак болытлар да Фәриткә ярдәмгә килә, кәбестәләрне шифалы тамчылары белән сыйлый. Яңгырдан соң көн тагын да ямьләнә, үсентеләр дә яшелләнеп, матураеп китә.

Көн артыннан көн үтә, көз килеп җитә. Кәбестәләр баш кадәрле булып үскән. Кул белән кыскаласаң шыгырдап торалар. Үзләре катлы-катлы, сусыл, тәмле. Аларга күзләр, борын, авыз ясап куйсаң, «Без инде үсеп җиттек!» — дияр кебек.

Әти-әнисе белән бергә Фәрит тә шатлана. Әнисе, кәбестә үсентеләрен утырткандагы сүзләрне искә төшереп:

— Улым, йә, кем тизрәк үскән? — дип елмая. Фәрит зур булып үскән кәбестәләрне күтәрергә тырышып карый да:

— Кәбестәләр! — ди. Аннан соң, җәй буе аларга су сибә-сибә, үзенең дә буйга сузылганын, күлмәк җиңнәренең кыскарып калганын күреп:

— Мин дә! — дип өсти.

Нәкыйп Каштан

Эх, бик кызыклы һәм эчтәлекле тукталыш булды бу! Килешәсеңме? Гаилә ул — иң зур байлык! Бер-берегезгә һәрвакты игътибарлы булыгыз!

МИНЕМ ДУСЛАРЫМ

Үскәнем, дуслар дөньясына алып барган тукталышны узып китмик. Бик кызык дөнья бит ул. Синең дусларың бармы? Аларның исемнәре ничек? Сез алар белән урамда уйныйсызмы? Ничек уйныйсыз? Бу шигырь сезнең турыда түгелме?

Бәлки, җавап бирерсез?
Ләйлә чыкты урамга,
Сәйдә чыкты урамга.
Сәйдәнең көрәге бар,
Ләйләнең чиләге бар.
Ләйлә уйный комлыкта,
Сәйдә уйный комлыкта.
Тик бергә уйнамыйлар,
Тик бергә уйламыйлар.
Ләйлә уч белән комны
Тутыра чиләгенә,
Сәйдә көрәге белән
Тутыра күлмәгенә.
Ләйләнең кулы кара,
Ә Сәйдәнең – итәге.
Уйнадылар,
Уенның
Булмады һичбер тәме...
Бәлки, җавап бирерсез,
Уенның кая яме?

Эльмира Шәрифуллина

— Сезнең турыда түгелме?

— ... .

— Юктыр шул. Әйт әле, ни өчен уенның тәме булмаган соң ? Уйнау кайчан күңелле була?

— ... .

— Әйе, акыллым, бергә, дус, тату булып уйнаганда күңелле була.

Һәркемнең тормышта дуслары була. чөнки дуслардан башка яшәү күңелсез. Әйдә, дуслар һәм дуслык турында сөйләшеп алыйк.

Дусларың гына булсын!

Егылсаң, торып була,
Торсаң, йөгереп була,
Йөгерсәң, җитеп була –
Дусларың гына булсын!
Сөйләшеп, уйнап була,
Күп нәрсә белеп була,
Шаярып-көлеп була –
Дусларың гына булсын!
Күңелле яшәп була,
Үсеп һәм ныгып була,
Дошманны егып була –
Дусларың гына булсын!

Рөстәм Мингалим

Дуслык, чын дуслык!

Иптәшләрең әйбәт булса,
Кыскара озын юл да.
Бергә булыйк, бердәм булыйк
Дуслыкның көче шунда.
Киңәшле эш һич таркалмас,
Куллар көч бирсен кулга.
Бергә булыйк, бердәм булыйк
Дуслыкның көче шунда.
Ярдәмләшеп, җырлап-көлеп
Яшик кояшлы елда.
Бергә булыйк, бердәм булыйк
Дуслыкның көче шунда.
Юлдаш булып йөр, дуслык,
Илче булып кил, дуслык,
Һәрбер өйгә кер, дуслык,
Безнең белән тор, дуслык,
Дуслык, дуслык, чын дуслык!

Эльмира Шәрифуллина

Дуслар

Камил белән Шамил
Тауга менеп бара.
Камил алга чыкса
Шамил артта кала,
Шамил алга чыкса
Камил артта кала.
Шамил белән Камил
Җитәкләшеп бара.
Тауга менгән чакта
Җитәкләшми кара.
Шамил артта калса
Камил тартып ала,
Камил артта калса
Шамил тартып ала.
Ике малай бергә
Тау башына менә.
Камил белән Шамил
Чын дуслар гомергә!

Зөләйха Миңһаҗева

Дус кызлар

Нигә син куандың,
Әйт әле, Гөлгенә,
Күзең дә, йөзең дә
Шатлыклы күренә.
Уйнарга курчаклар.
Алдымы әтиең?
Үзеңә күлмәкләр
Тектеме әниең?
Шатланып, куанып
Тордыңмы, матурым?
Сөйләче барын да
Син миңа, акыллым!
— Юк, апа, мин хәзер
Курчаклар уйнамыйм.
«Тәтиләр кирәк!» — дип

Мин хәзер, еламыйм.
Беренче мәртәбә
Мин барам мәктәпкә,
Бик тырыш укучы
Булырмын, әлбәттә.

Әминә Бикчәнтәева

— Акыллым, әдәпленең күлмәге сәдәфле, үзе матур гадәтле, ди безнең халык. Итәгатьле, матур, әдәпле итеп сөйләшә белү баланың тәрбиялелегеннән тора. Дустым! Яшьтәшләреңнән мөнәсәбәтең күп очракта сиңа бәйле. Син бик гыйлемле, эрудицияле була аласың. Тик дусларың белән аралаша белмәсәң, алар белән уртак тел таба алмаска да мөмкинсең. Һәр кешегә, ничә яшьтә булуга карамастан, тәрбияле, әдәпле кеше белән аралашу күңелле. Шуңа да аралашу кагыйдәләрен искә төшерү зыян итмәс.

Әйтик, партадашыңның дәфтәреннән күчерү матур гадәт түгел. Кешенең шәхси әйберләренә рөхсәтсез кагылырга, хатларны, көндәлекләрне укырга ярамый. Компьтерда эшләгән кешенең артында басып тору, шулай ук, әдәпсезлек билгесе. Дусларыңа кушаматлар тагып, исемне ямьсезләп эндәшү дә начар гадәт.

Гыйльми

Минем дустым бар, —
Тискәре Гыйльми:
— Кит! — дисәң, китми,
– Кил! — дисәң, килми.
Ә без шулай да
Дус аның белән.
Тискәрелекнең
Мин җаен беләм.
— Кит! — дип кычкырам,
Бик тиз кирәксә,
— Кил! — дип кычкырам,
Китми йөдәтсә.
Кем әйтә аңа:
«Кит-кит, Гыйльми», — дип,
Ә кемдер әйтә:

«Кил-кил, Гыйльми», — дип.
Кем нахак әйтә
Һәм кем хак әйтә, —
Гыйльми үзе дә
Төгәл белми бит.

Флера Гыйззәтуллина

Рәсем ясадым

— Рәсем ясадым, әткәй!
— Килештергәнсең бит, әй,
— Тәрәзләре бик матур.
— Аларын сызды Мансур.
— Рәшәткә дә ошады.
— Ансын Рәшит ясады.
— Кирпечләре тип-тигез.
— Ансын ясашты Илгиз.
— Чын шикелле моржасы.
— Мортаза эше ансы.
— Шулаймыни? Ә кран?
— Ясап бирде Әкрам.
— Ә нишләде соң Марат?
— Без икәү тордык карап.

Шәүкәт Галиев

Синең дусларың бармы? Аларны санап кит. Ни өчен тормышта дуслар кирәк?

Дустың булмаса — эзлә, тапсаң — югалтма, ди татар халык мәкале. Димәк, дуслар белән яхшы мөнәсәбәттә булырга кирәк. Аларның кадерен белергә кирәк.

Ничек уйлыйсың, кеше генә дус була аламы? Алдагы шигырьләрне укып, шуны ачыкла.

Иң гадел дус

Әйтә алмыйм, ниндидер ул
Синең өчен?
Яхшы китап — иң гадел дус
Минем өчен:

Күзгә карап әйтә миңа
Иң дөресен,
Ачып сала серләренең
Бөтенесен.
Яратмасаң — үпкәләми,
Алдашмый да…
Аның белән дус булганнар
Адашмыйлар.

Хәкимҗан Халиков

Дусларым

Өебез урман буенда —
Якты Идел ярында.
Каргалар да, чыпчыклар да
Минем белән дус монда.
Һәм җиләкләр, һәм чәчәкләр,
Дус каеннар, имәннәр
Безнең капка янына ук
Мине эзләп килгәннәр.
Килеп чыга төлке дус та
Минем хәлне белергә.
Мин чирәмдә кырын ятам
Ак казлар белән бергә.

Рөстәм Мингалим

Кайт, песием!

Ачтым өйнең ишеген —
Чыкты качты песием.
Күр әле син бу мутны —
Җирән купшы койрыкны!..
Эзләдем, арып беттем,
Әллә кайларга җиттем.
Юк кына бит песием,
Инде хәзер нишлием?!
Баш ватам да баш ватам:
Кайларда булган хатам?
Әллә инде мут кынам,

Җирән-ут койрык кынам
Эшсезлектән туйганмы?
Йоклап гарык булганмы?
Оятына көч килеп,
Эшләп ашыйсы килеп,
Орышмасыннар диеп,
Эш эзләп киткән мәллә
Күселе берәр өйгә?
Песи, песи, пескәем,
Яшел ялкын күзкәем,
Нишлим соң инде синсез?
Синсез шундый күңелсез!
Өйләрнең дә яме юк,
Ашларның да тәме юк.
Йөрмә инде мутланып,
Койрыгың сыртка салып.
Кайтып кер инде өйгә,
Болай йөрүләр нигә?
Эшне үзем табармын,
Сөеп кенә багармын
Яшел ялкын күзеңә,
Кайт, песием, кайт өйгә!

Фирая Зыятдинова

Актырнак һәм Балык

Мин Актырнак исемле бер эт белән таныш. Ул һәр көн саен нинди дә булса мажаралы хәлгә юлыга. Ә мин бу мажараларны күңел дәфтәремә җыеп барам. Берсен сезгә дә сөйлим әле...

Беркөнне Актырнак, үз ишегалдын калдырып, ерак сәфәргә кузгала. Дөнья карап кайтасы килә аның.

Көне буе Актырнак алга карап бара да бара. Кырдагы иген басуын, болындагы гүзәл чәчәкләрне, тау итәкләрендә челтерәп аккан тылсымлы чишмәләрне күреп соклана. Шуннан тау башына менеп карарга була. «Нәрсәләр бар икән бу биек тау башында?» — дип уйлый ул. Тиз-тиз атлап, бер сәгать дигәндә менеп тә җитә. Мондагы саф һавадан Актырнакның башы әйләнеп китә. Ә тауның бу як итәгеннән башланган гүзәл үзәннең матурлыгын күреп бөтенләй дә шакката. Үзәнне тутырып төрле төсле

чәчәкләр, хуш исле җиләкләр үсә. Үзәннең нәкъ уртасында түп-түгәрәк күл ялтырап ята икән. Нинди матур дөнья дип уйлый да Актырнак, җитез генә йөгереп, шул күл янына килә. Ә күлдән аңа бер Балык карап тора икән.

— Һау-һау, исәнме, Балык! — дип өреп куя Актырнак.

— Сәлам, — дип җавап бирә Балык күңелсез генә.

— Нәрсә булды? — дип сорый аптыраган Актырнак.

— Менә мин туганнан бирле шушы күлдә яшим. Беркая да чыкканым юк, дөньяны бөтенләй белмим, — дип уфтана Балык, моңсу гына итеп.

— Һәй! — дип куя Актырнак. — Тапкансың борчылып утырыр сәбәп. Хәзер мин үзем сиңа дөнья турында сөйләп бирәм.

Шуннан Актырнак урман, кырлар-болыннар, авыл һәм үзе яшәгән ишегалды турында сөйли башлый. Җир шарының бик матур, искиткеч зур булуын аңлата. Балык бу хәлләрне, әкият тыңлагандай, авыз ачып тыңлап тора. Шуннан тагын да күңелсезләнә.

— Менә шул, хәзер син барысын да беләсең, — дип сүзен төгәлли Актырнак.

— Син мине кызыктырдың, минем барысын да үз күзләрем белән күрәсем килә, — ди Балык.

— Нәрсәгә, син миңа ышанмыйсыңмыни?

— Ышанам!

— Шулай булгач, шушы-шушы җирләрдә булдым дип күз алдыңа гына китер. Менә мин дә су төбендәге дөньяны күрә алмыйм бит, аңа карап кына күңелсезләнеп утыра башласам, нәрсә була инде ул, ә? Әйдә, миңа үз дөньягыз турында сөйлә әле, — ди Актырнак.

Шуннан Балык аңа су асты дөньясы, кызыл, зәңгәрсу суүсемнәр, су ияләре төзегән патшалыклар, кабырчыклар эчендә ялтырап яткан энҗе ташлар, төрле төсле балыклар турында сөйли. Актырнакның исе китә.

— Сиңа дөньяны белмим дип әйтергә ярамый. Син бит могҗизалар дөньясында яшәп ятасың, — ди ул Балыкка.

— Чыннан да, мин дә бик матур дөньяда яшим икән бит! Безнең күл төбеннән дә матуррак урын юктыр ул! — дип сөенә Балык. — Тизрәк өемә кайтыйм. Рәхмәт сиңа! Сау бул!

— Сау бул, матур гына яшә! — ди Актырнак, көмеш тамчылар чәчрәтеп күл төбенә сикергән Балыкка карап, һәм шул мизгелдә үз ишегалдын сагынуын тоя.

Авылга таба йөгергәндә, Актырнак үзе яшәгән ишегалдының дөньядагы иң матур урын булуы турында уйлап куя. Шулай булмаса, бер көн эчендә шулкадәр сагынмас та иде!

Айсылу Имамиева

Димәк, китаплар, хайваннар һәм үсемлекләр дә дус була икән! Гаҗәп бит! Ә синең шундый дусларың бармы?

Кем кем була?

Илшат мөгаллим була,
Илдар зур галим була.
“Кибет ачам берүзем!” —
Диеп куйды Гөлйөзем.
“Бизнесмен!” — диде Марат,
Хәйләкәр генә карап.
Депутат була Таһир,
Күп сөйләргә маһир...
Үскәнен көтә-көтә,
Илгиз автобус “йөртә”.
Айгөл билет сатачак...
Йолдыз өйдә ятачак...
Ник эндәшмисең? Нигә?
Озак уйлый бу Динә...
Менә ул телгә килде:
“Мин — Динә булам!” — диде.

Ленар Шәех

Аңламадым

Өр-яңа күлмәгем белән
Мактаныйм дип кызларга,
Күбәләк тоткан шикелле
Йөгереп чыктым урамга.
Мине күреп шаккаттылар,
Хәтта телсез калдылар.
Әйләндереп-тулгандырып,
Күлмәгемне карыйлар.
— Чү, дим, ипләп! Берүк ипләп,
Пычрата күрмәгез,

Читтән генә сокланыгыз,
Кырыема килмәгез!
— Әй! — диеп торып чаптылар,
Ялгызым басып калдым.
Нәрсә булды соң кызларга,
Һич берни аңламадым!

Резеда Шәрипова

Дустым, ә син аңладыңмы? Дус кызлар ни өчен китеп барганнар? Дуслар белән ничек булырга кирәк?

Нинди кешенең дуслары була алмый икән?

Ә хәзер инде әкият белән дә таныш.

“Дуслык турында” әкият

Бервакыт чучка баласы Мырык Сарбай дусты янына кунакка барырга җыенган. Юлда аның каршысына соры бүре килеп чыккан.

— Әй, симезбикә, кая китеп барасың? — дип сораган ул, тәмләп сагыз чәйни-чәйни.

— Дустымның туган көненә... — дигән Мырык, тотлыга-тотлыга.

— Туган көн шәп нәрсә инде ул, анда төрле тәмнүшкәләр була торгандыр, — дигән бүре, ялана-ялана.

Аннары ул Мырыкның кәрзинен күреп алган.

— Нәрсә бар анда синең? — дип сораган.

— Татлы сумсалар, дустым бик ярата аларны...

— Нәкъ минем кебек икән! — дип, ямьсез тешләрен ыржайтып көлгән бүре. — Мин дә ашарга яратам! — дигән дә, Мырыкка ташланган.

— А-а-а! Коткарыгыз! — дип чинаган дуңгыз баласы, һәм, бүре тырнакларыннан ничек кирәк шулай ычкынып, кычкыра-кычкыра чабып киткән.

Аның тавышын Сарбай ишетеп алган да, дустына ярдәмгә ашыккан. Бәләкәй генә булса да, чын этләр кебек тешләшә белә икән ул. Бүренең койрыгына чытырдап ябышкан да, аны уңга-сулга айкый башлаган.

— Ах, син, әнчек, күрсәтәм мин сиңа хәзер! — дип үкергән бүре, аның ягына таба ыргылып.

Шулчак Мырык атылып килгән дә, бүренең ачык авызына сумса тутырылган кәрзинен китереп тыккан.

— Мә, аша, безгә генә тимә!

— Фу, тәмсез! — дип ырылдаган да бүре, алгы тәпиләре белән Мырыкны эләктереп тә алган. — Ә менә син тәмле!

Ул арада агачлар арасыннан аю-милиционер килеп чыккан. Тәртипсез бүренең аякларын бәйләп, зоопаркка алып киткән. “Менә шушы читлектә утыр, без сине тәрбияләячәкбез!” — дип янаган.

— Рәхмәт сиңа, Сарбай, — дигән Мырык, бераз тынычлангач.

— Мин сине туган көнең белән котлыйм. Тик менә бүләгем генә юк, аны бүре ашады...

— Борчылма, син үзең бүләк, — дигән Сарбай, аны үзенә кунакка алып китеп, сөтле чәй белән сыйлаган.

Инде төн җиткән булган, күктә йолдызлар кабынган.

— Беләсеңме нәрсә, — дигән Мырык, бераз уйланып утыргач.

— Әйдә, ә-әнә теге йолдызга синең исемне кушабыз, батырлыгың өчен сиңа йолдыз тиешле!

— Рәхмәт! Тик аның ялгызына гына күңелсез булыр, әйдә, янәшәсендәген синең исем белән атыйбыз! — дигән Сарбай.

Алар күңелле итеп көлешкәннәр, матур җырлар җырлаганнар, аннары, йомшак чирәм өстенә җайлап утырып, төнге күккә караганнар. Ә анда Мырык һәм Сарбай исемле ике якты йолдыз, җемелдәшеп, аларга күз кыса икән...

Илдар Нәфиев

Көзге һәм Маймыл

Маймыл, көзгедән үзенең сурәтен күргәч, әкрен генә янындагы Аюга аягы берлән төртеп: «Кара әле, иптәш! Көзгедә нинди кыяфәтсез, нинди ямьсез бер хайван күренә. Кара әле, аяклары нинди кәкре, кара әле, йөзе нинди килешсез! Әгәр мин шул көзгедә күренгән нәрсәгә аз гына охшасам да, хәсрәтемнән буылып үләр идем.

Хәер, әйтергә мөмкин, минем иптәш вә дустларым арасында да бу көзгедә күренгән хайван төсле ямьсезләр биш-алтылап бар, хәтта мин аларны бармак берлән санап күрсәтә алам», — диде.

Аю моңар җавапта: «И Маймыл иптәш! Син иптәш вә дустларыңны санап мәшәкатьләнгәнче, бер мәртәбә үзеңә генә карасаң булмасмы?» — диде.

Габдулла Тукай

Тавык белән үрдәк

Бер тавык бер үрдәк белән бергә торып,
Бер курада бергә ашап, бергә йөреп,
Бара торгач, бер-берсенә дуслаштылар,
Берсен-берсе туган төсле якын күреп.
Үрдәк бара көн саен бер күл буена,
Аннан кайткач, йортта тора көн буена;
Тавык өйдә ялгыз торып калган чакта,
Төрле күңелсезлек төшәдер уена.
Беркөнне диде тавык: «Дускаем,
Кая барып кайтасың син һәр көн саен?
Миңа монда ялгыз тору бик күңелсез,
Синнән башка торып һичбер ямь тапмаем».
Диде Үрдәк: «Барамын мин һәр көн күлгә,
Күлдә йөрсәм, рәхәт буладыр күңелгә;
Анда мин йөзәм, чумам, кагынамын,
Тазарам, матурланам йөзеп күлдә».
Тавык сорый: «Ул матур күл кайсы җирдә,
Моңарчы син ник әйтмәдең миңа бер дә?
Мин дә барып, рәхәтләнеп йөрер идем,
Йөзеп, чумып уйнар идек бергә-бергә».
Үрдәк әйтә: «Барам дисәң, ярый, бик хуш;
Ник бармаска, безнең төслүк син дә бер кош.
Йөзеп, чумып, юынып, тазарып кайтырсың,
Көн буена бикләнеп, тик торганчы буш».
Киттеләр болар күлгә иртүк торып,
Тавык бара йөзәр өчен план корып;
Бару белән, үрдәк күлгә төшеп китте,
Чума, йонын юа башын борып-борып.
«Ник карыйсың? Әйдә инде син дә төш», — ди;
Шулай дигәч тавык суга барып төште.
Төшү белән тавык суга бата башлап,
Ихтыярсыз байтак кына су да эчте.
Чыгарга әйтә, үзе һаман китә эчкә,
Аягы җитми торган тирән төшкә,
Үрдәк тә хәйран булып карап тора,
Якын дусты дучар булгач мондый эшкә.

Тавык мескен үлмәс өчен чабаланды,
Җаныннан өмет өзде, гажиз калды.
Ярый әле шул вакытта берәү күреп,
Кызганып, бу тавыкны төшеп алды.
Тавык өйгә кайтып керде көчкә-көчкә,
Гадәттән тыш су тулган булган эчкә;
Үкенде батырчылык кыйлганына
Кулыннан килми торган моңдый эшкә.

Мәҗит Гафури

Кечкенә Ринат

Ринатның әнисе китапханәче булып эшли. Еш кына әнисе белән кечкенә Ринат та китапханәгә бара. Ул анда китаплар карый. Әнисе аңа әкиятләр укый. Әкият тыңларга бик ярата шул малай.

— Үскәч, дәү булгач, мин дә сиңа укырмын, әнием, яме, ул чакта син тыңлап кына утырырсың! — ди.

— Ярар, улым, — ди әнисе, улының маңгаеннан үбеп.

Ринат янә китаплар карый башлый. Бер дә ертмый ул аларны. Бу хакта — китапны ертырга ярамаганны — дусларына да әйтә.

— Китапны ертмагыз! — ди.

Кайберәүләр кебек түгел шул ул, кечкенә булса да, китапны ертырга ярамаганын, синнән соң башкаларның да аны укыйсын белә ул.

Рафис Гыйззәтуллин

Песнәк белән Әнисә

Кыш көне иде. Көннәр үтә салкынаеп китте. Суык бабай стеналарга китереп суга, шарт-шарт итә. Тышка чыксаң, борынны чеметә.

Кошларның хәле бик авырайды. Аларга ашарга табу кыенлашты.

Беркөнне Әнисәләрнең тәрәзәсенә сары түшле песнәк килеп кунды. Тәрәзә пыяласын чукырга тотынды.

— Әни, песнәк нигә тәрәзәне чукый? — дип сорады Әнисә.

— Күрәсең ич тышта нинди салкын. Аның ашыйсы килгән, — диде әнисе.

— Алайса, мин аны ашатыйм, — диде Әнисә, форточканы ачты да бер кисәк туңмай куйды. Песнәк бик шатланды. Канат кагып, Әнисәгә рәхмәт әйтте. Күз ачып йомганчы майны ашап та бетерде.

Шул көннән алып, песнәк бик ияләшеп китте. Көн саен бер вакытта тәрәзәгә килеп куна торган булды. Тора-бара ул ачык тәрәзәдән өйгә дә керә башлады.

Гасыйм Лотфи

Ашка — куян

Беркөнне Төлке Куянны ашка чакырган. — Куян сеңлем, мин бит сине бик яратам, бүген кич миңа ашка кил, — дигән. Куян моңа шатланган. Тиз генә җыенган да Төлкегә кунакка киткән. Барып керсә, Төлке учакка казан элеп булыша икән.

— Исәнме, Төлке апа, менә килеп тә җиттем. Рәхмәт чакыруыңа, — дигән Куян.

Төлке җавап биреп тормаган, Куянны, колагыннан алып, казанга китереп тә салган.

— Нишлисең син, Төлке апа, мин бит сиңа ашка килдем, кызган мине... — дип ялварган Куян.

Төлкегә шул җитә калган.

— Әйе шул, ашка чакырдым, шуңа да син ашта инде, — дигән.

Галимҗан Гыйльманов

Велосипедлы Мөнир

Мөниргә әтисе магазиннан өр-яңа велосипед сатып алды.

Мөнир велосипедын җитәкләде дә урамга чыкты. Аның тирәсенә шундук иптәш малайлары җыелды.

— Мөнир, йөреп торырга миңа да бирерсең әле велосипедыңны? — диде Илдус.

Бүтән малайлар да:

— Эх, нинди ялтырап тора!

— Бер генә тотып карыйм әле, — диештеләр

Мөнир велосипедын бик кызганды. Аның үз әйберсенә беркемне дә кагылдырасы килмәде.

— Теләнмәгез дә, берегезгә дә бирмим, — диде ул, кырт кисеп.

Ләкин Мөнир велосипедта йөри белми иде. Шуңа күрә аны, велосипедка утыргач аумас өчен, арттан кем дә булса тотып барырга тиеш иде.

— Ярар инде, алайса, син генә йөреп карарсың, — диде ул Илдуска. — Тик мин утыргач, син велосипедны тотарсың...ычкындыра күрмә... Басуга чыгып, әнә теге чыршы турысына җиткәч, мин төшәрмен дә син китәрсең.

Илдус бик шатланып риза булды. Мөнир киртә янына килде дә велосипедның ияренә атланып утырды. Илдус велосипедны тотып торды.

Менә алар әкрен генә кузгалып киттеләр. Велосипед баштарак әле бер якка, әле икенче якка кыйшайды. Әгәр Илдус ныгытып тотмаган булса, Мөнир шундук егылып төшкән булыриде. Шулай да ул бераздан тигезлеген саклый ала башлады,һәм велосипед такыр юлдан җиңел генә тәгәрәп китте.

Тиздән иптәшләре дә, авыл да артта калды. Алар юл буендагы чыршы турысына да якынлаштылар. Илдус бик кызу йөгерүдән тирләп чыкты, кызарды.

— Тукта инде, Мөнир... — диде Илдус, ялгыз чыршыны узып киткәч.

Мөнир туктамады, киресенчә, тагын да кызурак бара башлады.

— Мөнир, йөрерсең дип үзең әйттең ич... тукта инде, — диде Илдус, кызганыч тавыш белән. — Туктамасаң ычкындырам. Кит үзең генә.

— Ычкындырсаң әллә! Бар, китә бир, — диде Мөнир, бер дә исе китмичә. — Мин инде синнән башка да йөри алам.

Илдус бик хурланды. Мөнирнең велосипедын ычкындырды да, кире борылып, авылга таба йөгерде. Мөнир, иптәшеннән котылуына сөенеп, тагын да кызурак китте. Бара торгач, юл кисәк кенә түбәнәя башлады. Велосипед, тигезсез юлда дыңгырдап, һаман шәбрәк тәгәрәде. Хәзер инде педальгә басарга да кирәкмәде. Мөнирнең колак төбендә җил сызгырды, йөрәге куркудан жу итеп китте: велосипедның йөрешен әкренәйтү өчен, тормозга басарга кирәклеген ул белми иде.

Велосипед очты гына. Мөнир үз алдында берни дә күрмәде, куллары, аяклары тыңламас булды. Һәм коты алынган малай, үзе дә сизмәстән:

— Илдус! Тот, ычкындырма! — дип кычкырып җибәрде.

Зырылдап әйләнеп барган алгы тәгәрмәч кинәт читкә кереп китте, һәм Мөнир велосипеды-ние белән юл читендәге чокырга мәтәлеп төште.

Аның янында беркем дә юк иде.

Нурихан Фәттах

Габдулла абыебыз Тукай дуслык турында нәрсә язган икән? Әйдәгез, таныйшыйк әле.

Юмарт дус

Без үземезгә кирәк булуы мөмкин булмаган нәрсәне кешегә бик җумартланып бирәмез. Менә шул сүзне куәтләр өчен, монда бер мисал да китерәмен.

Бер Төлке, Тавык ояларын актарып, туйганчы ризыкланып, ашаганнан артканын запаска калдырып, аны бер җиргә күмеп, үзе бер печән кибәне төбенә килеп яткан иде.

Берзаман Төлке яткан җиреннән генә ерактан үзенә таба бер карамчык килгәнен күрә; бу карамчык, һаман якынлаша-якынлаша, Төлкенең янынук килеп җитте. Төлке, караса, күрә ки — бу үзенең Бүре дусты икән.

Бүре, килеп җиткәч үк, дусты Төлкегә, бүген иртәдән бирле иснәнеп йөрсә дә, ашарлык бернәрсә дә таба алмаганлыгын, Көтүчеләрнең дә йокламаганлыкларын, Этләрнең дә усаллыкларын бер-бер бәян итеп, Төлкедән бераз ашарга өмид итте.

Төлке нигә кызганмасын — үзенең дусты ич! Бүре үзенең ихтыяҗын сөйләп тәмам иткәч, Төлке Бүрегә хитабән: «И газиз дустым! Шулай ук ачыктыңмыни? Алай булса, менә шушы бер кибән печәнне рәхим итеп ашасаңыз ла! Сез ачлыктан хәлас булсаңыз, мин бик шат булыр идем», — диде.

Бу хәйләкәр теге яшереп куйган запас хакында бер генә сүз әйтсә, Бүре өчен нинди зур бәхет булыр иде.

Габдулла Тукай

Кунак ашы — кара-каршы

(әкият)

Мәликә белән Сания — туганнар да, күршеләр дә, уку алдынгылары да. Үзсүзлерәк булганга, Санияне Мәликә алай ук өнәп бетерми. Туганы булгач нишләсен… Аннары, бер сыйныфта укыгач, мәктәпкә дә бергә баралар, бергә кайталар.

Әнә дүртенче сыйныфны уңышлы тәмамлаулары белән котлап, әниләре аларга бүләкне дә бер үк төрлене алган. Җиләккә йөрергә дип, кәрзин бүләк иттеләр. Кәрзиннәре шулкадәр дә матур ки, уймак кебек, ди. һәм шуңа да җиләккә төшүне кызлар аеруча түземсезлек белән көтеп алганнар, ди.

Әти-әниләре, аларны урманга озатканда:

— Кәрзиннәрегезне тутырсагыз, шәһәрдән килгән курчак театрына җибәрербез үзегезне, — дип, вәгъдә биреп калалар.

Кызларның бәхетләре бар икән. Урманга кереп озак та бармыйлар, шундый зур җиләклеккә тап булалар. Күз ачып йомганчы кәрзиннәрен тутырып та куялар. Әле, әниләрен куандырырга дип, чәчәкләр дә җыялар.

Җырлый-җырлый кайту юлына чыкканнар гына иде, аларга таба чабып килүче куянны күреп туктап калалар. Ә Озын Колак кызу йөгерүдән көч-хәл белән генә сулыш ала, ди. Үзе:

— Кызлар, акыллыларым! Зинһар өчен, ярдәм итә күрегез! — дип ялвара. — Өемә зур кайгы килде — балаларым чирләп китте. Хәлләре бигрәк мөшкел. Җиләк ашыйсыбыз килә, аннан авыз итсәк терелер идек, диләр. Өметем сездә генә… Ярдәм итә күрегез инде бәләкәчләремә… Яхшылыгыгызны онытмам, — ди икән.

— he, акылың ука икән! Синең балаларыңның җиләк ашыйсы килгәнне безнеке килмиме? — ди Сания, чытлыкланып.

— Тукта әле, Сания! Кырт кисәргә ашыкма. Бәлки, чыннан да…

— Кара-кара! Әллә куянны яклап маташасың инде? Ни сөйләмәс ул Озын Колак. Бер дә балаларына түгелдер әле.

— Их, кызлар, кызлар! Ышанмыйсыз икән, әйдәгез, барып карагыз. Тилмерешеп яталар бит җанкисәкләрем… — ди куян, еларга җитешеп.

Хәйләкәр дә инде бу Озын Колак. Мәликә кебек беркатлыларны, бәлки, ышандыра да алыр, ә Санияне кармагына каптыра алмас!

— Ихлас авырыйлар икән, бар, үзең җый. Әнә тегендә генә җиләклек. Шулкадәрле күп, тәгәрәп кенә чүплисе.

— Бәләкәчләремне калдырып китә алсам икән! Сезнең алга да менә йөгерә-йөгерә генә чыктым. Яман каты йөткерәләр шул сабыйларым.

Җиләк тулы кәрзинен Мәликә куянга суза.

— Мә, йомшаккай, шифасы тисен. Балаларың тизрәк терелсен.

Ә Озын Колак, кәрзинне кулына алуга, рәхмәтен дә әйтергә онытып, шунда ук, куаклар арасына кереп, күздән дә югала.

— Җүләр, тиле! Өеңдә нәрсә әйтәсең инде? Болай булгач, курчак театры, тю-тю, тәтемәячәк үзеңә!

— Театр дип, авыру куяннарны тилмертеп булмый ла инде. Чыннан да, җиләк — йөткерүдән иң файдалы шифа. Салкын тидерсәм, әнием дә һәрчак парлап эчертә миңа аларның кипкәннәрен.

— Әллә чынлап ышандыңмы шул алдакчының сүзенә? Күрмәдеңмени, кәрзинеңне эләктергәч тә тизрәк шылу ягын карады.

— Сабыйлары янына шулай ашыкты ул. Җиләкләремнең файдасы гына тисен!

— Шөрепләрең бушаган, ахры, синең? Дус күреп йөрим тагын үзеңне. Бүтән синең белән беркая да бармыйм!

— Ялыныр дисеңме әллә? Ярар, барма!

Авылга кергәнче, алар башка сөйләшмиләр. Сания юл буе эченнән генә Мәликәне тиргәп кайта: «Шулкадәр дә ышанучан булыр икән! Беркатлы!»

Мәликәнең үз уе: «Курчак театры, имеш. Анда бармаганнан әллә ни булмас анысы. Ә менә әнисе ни дияр? Шунысы гына шүрләтә шүрләтүен. Кәрзине бигрәк уймак кебек иде шул. Юк, ул барыбер дөрес эшләде. Өйдәгеләре ачулансалар ачуланырлар инде…»

Ишектән керүгә, кулының буш икәнлеген күреп, чыннан да, әнисенең йөзе бераз кырыслана төшә:

— Эh, кызым, кызым! Күпме хыялланган идең, кәрзин алып бирсәгез, көн саен җиләк белән сыйлармын, дип. Ярый әле савытыңны гына югалткансың, үзең адашмагансың.

Мәликә исә, әнисенең кочагына сыенып:

— Ачуланма инде, әнием. Урманда җиләк күп, гажәп күп. hичшиксез, мин ал арны сезгә иртәгә үк җыеп кайтырмын. Ә кәрзинемне югалтмадым мин. Куянның авыру балаларына калдырдым. — Ул түкми-чәчми әнисе белән әтисенә урмандагы хәлне сөйләп бирә.

Сүзен тәмамларга да өлгерми, әтисе аны күтәреп үк ала:

— Менә нинди булып үсеп килә безнең кызыбыз, әнисе! Булдыргансың, булдыргансың, балакаем! hәрвакытта да шулай мәрхәмәтле, ярдәмчел бул! — ди ул.

Ә әнисе янчыгыннан җәhәтрәк акчасын алырга ашыга:

— Бик дөрес эшләгәнсең, кызым! Без дә сүзебездә торабыз. Чәй эчеп алыйк та, билетка йөгерерсең. Мә, менә акча.

Алар гөрләшеп табын артына утыра. Әнисе пешергән тәмле пәрәмәчләре булганда, җиләксез дә бик тәмле.

Ярый, Мәликәне калдырып торыйк. Саниягә килсәк… Ул, эре кыяфәт белән генә түргә үтеп, җиләк тулы кәр-зинен өстәлгә китереп куя. Әнисе шулкадәр сөенә ки:

— Әтисе, кара әле, кара! Кәрзинен тутырып ук кайткан лабаса кызыбыз! Вәт булдыргансың, балакаем!

— Йә, ярый, әни. Күп сөйләшергә вакытым юк. Билетка йөгерәсем бар. Чәеңне китер тизрәк.

Әнисенең тәм-томнары әзер иде. Җиләкне өстәлнең иң түренә куеп, чәй табынына җыйналалар.

— Нәрсә, кызым, Мәликә бөтенләй дә җыя алмадымыни? Кулында кәрзине дә күренмәде.

— И-и, җүләр лә ул… — Сания куян очратуларын, аның белән булган әңгәмәне бәйнә-бәйнә тезеп китә.

Ул сөйләгән арада, әтисенең йөзе караңгыланганнан-караңгылана бара. Әнисенең күзендә дә яшь бөртекләре чалына. Тик Саниянең әлеге үзгәрешкә бер дә исе китми. Әнисенең уфтанып:

— Әй кызым, кызым… Авыру балаларга җиләгеңне кызгандыңмы? — дигәненә игътибар да итми, дорфа гына кулын селти:

— Куй әле, әни. Ярый, мин тукландым. Клубка ашыгыйм… — дип, үзенә тиешле акчаны сорый. — Алгы рәтләргә билет беткәнче алып калырга кирәк. Йөгерим…

Мәгәр әтисенең кырыс тавышы аны бүлдерә:

— Әнисе, бернинди театр да юк аңа! Башта гаебен танырга өйрәнсен. Миһербансыз бала үстергәнбез икән ләбаса.

— Әй кызым, кызым!.. — ди әнисе дә, күз яшьләрен сөртә-сөртә.

…Шул көннән соң күпмедер вакыт узгач, Мәликә, ниндидер шакылдау ишетеп тәрәзәдән караса, ни күрсен… Бәй, теге куян килгән түгелме соң? Янында балалары да сикерешә.

— Рәхмәт сиңа, юмарт кыз! Кечкенәләремә салкын тигән булган. Җиләкләреңнең шифасы үтә дә булышты. Инде менә сихәтләнделәр дә. Ягез әле, балакайларым, рәхмәт әйтик әле апагызга бергәләшеп. Менә сез дә аның кебек мәрхәмәтле, ярдәмчел булып үсегез.

Куяннар бер-бер артлы Мәликәгә баш ия. һәркайсының карашында мөлаем елмаю.

— Ә менә бу кәрзиннәрдәге җиләкләр бездән сиңа күчтәнәч, шәфкатьле кыз. Берсе үз кәрзинең булса, калганнарын кечкенәләр, сиңа бүләккә дип, үзләре үрде.

Рәхмәтләрен кат-кат әйтә-әйтә, тирә-як күршеләрне гажәпкә калдырып, куяннар, берсен берсе узарга теләгәндәй сикерә-йөгерә, йөгерә-сикерә, җиләкле урман ягына китеп баралар.

Һәм, Сания ишеләргә яхшы сабак булып, Мәликәләрнең тәрәзә төбендә җиләк тулы җиде кәрзин генә торып кала.

Нурия Сәйяр

Иң гадел дус

Әйтә алмыйм, ниндидер ул
Синең өчен?
Яхшы китап — иң гадел дус
Минем өчен:
Күзгә карап әйтә миңа
Иң дөресен,
Ачып сала серләренең
Бөтенесен.
Яратмасаң — үпкәләми,
Алдашмый да…
Аның белән дус булганнар
Адашмыйлар.

Хәкимҗан Халиков

Дуслар

Кич якынлашып килә иде. Алан әйләнәсендәге агачларның күләгәләре озыная барды. Менә алан өстендәге кояш, агачлар артына тәгәрәгәндәй булып, күздән югалды. Күләгәләр барысы да бергә тоташып җәелделәр, урман эче караңгылана башлады.

Көне буе, кич җиткәнне көтеп, куак астында яткан ана Куян урманда йөреп кайтмакчы булды. Киткән чакта, ул үзенең балалары Шалпан колак белән Кечкенәгә әйтте:

— Сез шунда гына уйнагыз. Ерак китмәгез! Чирәм үсеп куелана төшкәч, мин сезне үзем урман белән таныштырырга алып чыгармын. Аңарчы сез тиз йөгерергә дә өйрәнерсез.

Урыныннан кузгалып, бер-ике сикергәч, ул тагы, артына әйләнеп:

— Шалпан колак, син Кечкенәне кыерсытма, — дип кычкырды. Аннан агач арасына кереп югалды.

Бу Куян балалары яз көне икесе бервакытта туган булсалар да, берсе никтер нәни иде. Шуңа күрә дә аңа әнисе Кечкенә дип исем кушты.

Әниләре киткәч, Шалпан колак белән Кечкенә ду килеп куышып йөгерергә тотындылар. Түгәрәк алан әйләнәсендә йөгереп арыгач, алар кайчандыр яшен сугып аударган имән агачы төбе янына барып ял иттеләр. Ауган агачның үзен инде күптән кешеләр ягарга алып киткән. Ә төбе алан уртасында кара утыргыч төсле булып торып калган иде.

— Әйдә, шул төп аша сикереп уйныйбыз! — диде Шалпан колак, бераз ял иткәннән соң.

— Әйдә-ә! — диде Кечкенә. Алар сикереп уйнарга керештеләр. Йөгереп-йөгереп киләләр дә шул агач төбе аша һоп!

Шуннан ерак түгел ямь-яшел яфраклы каен агачы үсеп утыра. Анда бер ана Песнәк, оя ясап, йомырка салган да шул йомыркалардан нәни песнәкләр борынлап чыкканны көтеп утыра иде. Песнәк Куян балаларының йөгереп, сикереп уйнаганнарын оясыннан күреп, сокланып утырды.

— Менә озакламый минем дә нәни кошчыкларым булыр. Канат чыккач, алар очарга өйрәнерләр, — дип уйлап куйды. Шулвакыт Шалпан колак ерактан йөгереп килеп сикерим дигәндә генә, агач төбе өстендә кәкре коры чыбык, кинәт кузгалып, яртылаш үрә торды. Шалпан колак, куркып, колакларын торгызып, кырыйга сикерде. Башта әле ул бернәрсә дә аңлый алмый аптырап торган иде. Аның коры чыбык дип уйлаган әйбере, ысылдап, чирәмгә төшкәч аңлады.Ул чыбык түгел, агулы кара Елан икән. Ул арада кара Елан, чирәм өстеннән шуышып, туп-туры әлеге Песнәк оялаган каенга таба китте.

Өстән аны күреп торган бичара Песнәкнең йөрәге ярылырга җитеште. Ул, акыллы кош, еланнарның гадәтен белә иде. Менә хәзер Елан аның оясына үрмәләп менәр дә йомыркаларын ватып эчәр! Песнәк бик борчылып чыелдап кычкырды:

— Коткарыгыз! Шалпан колак белән Кечкенә эшнең нәрсәдә икәнен аңлап җиткермәделәр җиткерүен. Шулай да ысылдаган кара Еланның берәүгә дә зарары тимәгән кошка явызлык эшләргә җыенуын сизенделәр.

— Ничек коткарырга соң ул кошчыкны? — диде Шалпан колак. Кечкенә:

— Тукта! Әни кайтып килмиме икән? Мин барып карыйм әле. Ул кайтса, берәр нәрсә уйлап табар, — дип, әнисе киткән якка чапты.

— Ярый, син ул якка бар. Мин бу яктан карап килим! — дип, аланның икенче ягына йөгерде. Кечкенә сикерә-сикерә йөгереп, агачлар арасына барып керүгә, тәпиенә нәрсәдер кадалып кычкырып җибәрде:

— Ой, ой, ой! Караса, анда Керпе йомарланып яткан икән.

— Нәрсә шулчаклы, күзеңә ак-кара күренми, мәтәлә-кадала чабасың? — диде Керпе, Кечкенәгә ачуланып. Йөгереп килеп сулышы беткән Кечкенә аңа:

— Елан! Елан! — дип кенә әйтә алды.

Керпе: — Фу-фу! Төлке куа икән дип торам тагын! Кайда ул Елан, күрсәт, — дигәч, Кечкенә, шатланып, аны иәртеп китте. Алар бик вакытлы

барып өлгерделәр. Керпе, аланда каен агачына үрмәләп менәргә җыенган Еланны күрүгә, йөгерүен кызулатты һәм, вак-вак атлап, тиз генә барды да, Елан өстенә ташланып, башының арт ягына тешләрен батырды.

Арттарак калып, бу хәлне карап торган Кечкенә, Керпе өчен куркып, күзләрен йомды хәтта. Ул күзен ачканда, Керпе еланны буып салган иде инде. Ул арада Шалпан колак та, әнисен эзләп таба алмыйча, әлсерәп кайткан иде. Еланның кузгалмый сузылып ятканын күргәч, ул да иреннәрен кыймыл-кыймыл иттереп, шаккатып торды.

— Фу! Шулмы курыккан еланыгыз? Фу! — диде Керпе эре генә. Оясында тынын алырга да куркып утырган Песнәк шатлыгыннан ни эшләргә белми чутылдады:

— Рәхмәт, сиңа, Керпе. Бу яхшылыгыңны гомердә дә онытмам. Бәлки, кайчан да булса минем дә сиңа файдам тияр. Керпе аңа бернинди дә җавап бирмәде.

— И мескен кошчык! Син кемгә ярдәм итә аласың соң? — дип, авыз эченнән генә пырхылдап көлеп, үз юлына китте. Озакламый Песнәкнең нәни кошчыклары булды. Алар әле бернәрсә дә эшли белмиләр. Әниләре азык алып кайтканны көтеп, авызларын ачып, тик чыелдашып яталар иде. Беркөнне Песнәк, гадәтенчә азык эзләргә чыгарга җыенгач, аланда уйнап йөргән Шалпан колак белән Кечкенәгә әйтте:

— Куянкайлар! Мин юкта, сез минем кошчыкларга күз-колак булсагыз иде. Алар бик тынгысызлар. Егылып төшеп имгәнмәгәйләре дип куркам. Сез аларга кычкыргалап торыгыз, оядан башларын чыгарып сузылмасыннар, — диде.

Шалпан колак белән Кечкенә:

— Ярый, ярый. Без шунда каен төбендә генә уйнарбыз. Кошчыкларың егылып төшә башласа, йомшак тәпиләребез белән тотып алырбыз. Җиргә төшеп имгәнергә ирек бирмәбез! — диделәр.

Песнәк тынычланып очып китте. Бераз очып, азык алып кайтып килешли, ул бер Төлкенең шыпырт кына куак артына яшеренгәнен күреп алды.

— Кемне сагалап посты икән бу явыз? — дип борчылып, як-якка каранса, текер-текер атлап килеп яткан таныш Керпене күрде. Керпе сусаган булган, күрәсең, яңгырдан соң тирән чокырга җыелган суга таба бара иде. Төлке шуны сагалап поскан икән. Коры җирдә Керпе, йомарланып ятып, Төлкегә бирешмәсә дә, су аның өчен куркыныч. Төлке аны суга тәгәрәтеп

төшерә дә, Керпе җәелеп йөзә башлау белән, буып ашый ала. Песнәкнең шундый хәлне күргәне бар иде. Ул, шунда ук түбән төшеп, акрын гына:

— Төлкедән саклан! Төлке сагалый! — дип чыелдап, Керпенең өстеннән очып үтте. Керпе, кире борылып, бөтен көче белән йөгерергә тотынды. Төлке эшне аңлаганчы, ул әллә кая, чытырман арасына качып өлгергән иде инде. Бераз бөгәрләнеп ятканнан соң, ул чирәм арасыннан башын чыгарып карады һәм Төлкенең, бик кәефсезләнеп, борынын салындырып, икенче якка ауга киткәнен күреп тынычланды.

— Фу! Менә сиңа кечкенә кошчык! Тукта, барып хәлләрен белим әле үзләренең, — дип, аланга таба тәпиләп китте. Көннәр үтте. Песнәкнең балалары да үстеләр. Канат чыгарып очарга өйрәнделәр. Үз-үзләренә көн күрә башладылар. Шалпан колак белән Кечкенә дә зур куян булдылар. Тик аларның берсенең дә шул аланнан китәселәре килмәде.

Керпе дә башка җирдә ямь тапмады, һаман кыштыр-кыштыр шул тирәдә йөрде. Кышын песнәкләргә урманда туенып тору читен булачак иде. Шуңа күрә, көз җитү белән, алар кая булса да кешеләр тора торган җиргә китәргә җыендылар. Керпе, Шалпан колак һәм Кечкенә шул алан тирәсендә кышларга булдылар. Алар песнәкләрне:

— Яз җиткәч, тагын шунда килегез! Без сезне көтәрбез! — дип озатып калдылар.

Сәрвәр Әдһәмова

Гладиолус — дуслык билгесе

Гладиолус чәчәгенең дуслык, тугрылык билгесе икәнен барыбыз да беләбез. Кайчан барлыкка килгән соң аның легендасы? Бер падишаһ хәтәр яуда ике батырны әсир итә. Ләкин тиз генә үтертми әле. Җиңелгән батырларның кулына кылыч тоттыра да мондый шарт куя: алар бер-берсе белән көч сынашырга тиеш. Кем җиңә, шул егеткә падишаһ үзенең кызын бирәчәк, имеш.

Ләкин егетләр үз дуслыкларына тугры булып калалар. Кылычларын җиргә кадап, алыштан баш тарталар.

Ачуы чыккан падишаһ батырларның икесен дә үтерергә боера. Соңыннан бу ике дусны бер кабергә күмәләр. Җиргә кадалган ике кылыч урынында ике кызыл гладиолус чәчәге үсеп чыга.

Галимҗан Гыйльманов

Кыңгырау чәчәк

Яшел нарат урманында, аның иркен аланында бик нәфис, бик назлы бер Кыңгырау чәчәк үсеп чыккан.

— Абау ла, бигрәк матурсың! Исәнме, Кыңгырау чәчәк! Бик тә ошыйсың син миңа. Әйдә, икәү дус булабыз! — дигән Куян баласы.

— Дус булабыз? Ә ничек була соң ул дус булу? — дип сораган Кыңгырау чәчәк. Ул бит әле яңа гына туган булган, шуңа күрә дуслыкның нәрсә икәнен белмәгән. Урман ягыннан бер Малай килеп чыккан. Килеп чыгуга ук, ул:

— Күр инде, нинди матур чәчәк! — дип, Кыңгырау чәчәкне өзәргә кулын сузган. Әмма кулын сузуы булган, шунда ук ялт иттереп тартып алган. Кемдер авырттырып тешләп алган икән аның кулын. Караса, кечкенә генә Куян баласы.

— Тимә Кыңгырау чәчәккә! Ул — минем дустым! — дигән Куян баласы, малайга ачу белән карап.

— Кит, кагылма аңа! Кыңгырау чәчәкне өзәргә ярамый.

— Ә! Мин белдем! Белдем дуслыкның нәрсә икәнен! — дип, шатланып чыңлап куйган шулчак Кыңгырау чәчәк һәм талгын җилдә әкрен генә зәңгәр башын чайкый-чайкый җырлап җибәргән: Дуслык ул — яхшылык, Дуслык ул — яктылык. Дуслык ул кояштай нур чәчә. Син мине саклаучы, Яшәүне яклаучы, Яшә син, Куян дус, Мең яшә!

Резеда Вәлиева

Чукмар белән Тукмар

Бер әбинең ике әтәче булган. Аларның берсе — ак, икенчесе кара булган. Әтәчләр күп вакытларын сугышып үткәрәләр икән.

Әби ак әтәчкә — Чукмар, карасына Тукмар дип исем кушкан.

Чукмар чукырга бик оста, ә Тукмар бик ник тукмый икән.

Әби аларны ашатырга тотынса: «Җимне миңа әзрәк бирдең», «Ник минем өлешемә кердең?» — дип кычкырыша башлыйлар икән әтәчләр. Әйтешеп кенә калмыйлар, шунда ук сугыша да башлыйлар икән. Чукмары канга батырганчы чукырга, Тукмары күгәргәнче тукмарга тотына икән.

Әби килеп җитсә, Чукмар исемле ак әтәч:

— Әби, әби, кара әле, Тукмарың тукмый-тукмый бөтенләй күгәртеп бетерде, — дип әләкли икән.

Тукмар исемле кара әтәч тә энесеннән калышмый:

— Башымны кара әле, әби. Чукмарың чукый-чукый канатып бетерде, — ди икән.

Әби аларның әләкләшүләреннән дә туйган булган. Ул бер сүз дә әйтмәгән. Тукмарны култыгына кыстырган да каядыр күтәреп алып киткән. Тукмар бик курыккан. Әби аны күршеләргә кертеп торган. Тукмар анда өч кич кунган.

Ялгыз калгач, Чукмарга бик күңелсез булган. Юньләп ашый да, эчә дә алмаган.

Әбигә ул:

— Тукмарны алып кайт, бүтән сугышмабыз! — дип ялынган.

— Ярый, — дигән әби, — алып кайтсам кайтыйм, әгәр тагын сугыша торган булсагыз, ул вакыт тотам да берегезне бөтенләй юк итәм! — дип куркытып та куйган. Шуннан Тукмарны алып кайткан.

Тукмар да Чукмарны бик сагынган булган. Алар кочаклашып исәнләшкәннәр.

Хәзер инде алар бик тату яшиләр икән. Тик исемнәре һаман шулай Тукмар белән Чукмар булып калган.

Абдулла Алиш

— Я, нәни дустым, аңладыгызмы? Үзара дус булып яшәр өчен нинди булырга кирәк?

— ..., ...

— Шулай, бик дөрес, акыллым. Зирәк тә инде үзең. Ә менә хәзер тыңлап китәсе шигырьдәге Бәкер мөгаен сиңа ошагандыр, үзеңне танырсыңмы икән?

Басмада

Тәлгать басмага басып
Сикерә дә сикерә.
Чирәмлектә уйнаган
Бәкердән үзе көлә:
— Бәкер, Бәкер, мине күр,
Курыкмасаң, син дә кер!
Менә дигән таган бу!
Икебезгә таман бу!
Бәкер әйтә:
— Юк, кермим,

Мин әнкәйгә сүз бирдем.
Тәлгать үрти:
— Куркак син,
Куян кебек өркәк син!
Ә мин курыкмыйм судан,
Үскәч капитан булам.
Шул да булдымы гадәт —
Мактана торгач, Тәлгать
Таеп китте тактадан,
Барып төште басмадан.
Батып үлә дигәндә,
Әйтәлмичә дә сүзен,
Бәкер кереп тиз генә
Коткарып калды үзен.

Нур Әхмәдиев

— Таныдыңмы?

— ... .

— Ә Тәлгать кебек малайлар белән очрашканың бармы? Ул нинди малай?

— ... . (Юк, ул — мактанчык).

— Мин нәкъ шулай дип уйладым да. Синең тирәдә андый мактанчыклар юктыр.

МИНЕМ УЕНЧЫКЛАРЫМ

Акыллым, әле без иң кызыклы тукталышка — уенчыклар дөньясына тукталышына туктамадык бит. Син бу тукталышны бик яхшы беләсең инде. Аның турында үзең дә бик күп кызыклар сөйли алыр идең, шулаймы? Әйдә танышыйк әле.

Курчаклар

Бар бик күп курчаклар.
Аларны без саклап,
Кадерләп йөртәбез,
Битләрен сөртәбез,
Буялсалар-нитсәләр,
Мунчага кертәбез.
Бәрмибез, атмыйбыз,
Ватмыйбыз — саклыйбыз...

Бари Рәхмәт

Минем кызым — курчагым

Әй, акыллы курчагым,
Йом күзеңне, бәлли-бәү.
Башка бер сүз дә дәшмим,
Йоклап алыйк без икәү.

Җәвад Тәрҗеманов

Үзебез ясаган машина

Шәп машина ясадык:
Кабинасын ясадык,
Әрҗәсен дә ясадык,
Ясадык фарасын да.
Машинага ни кирәк —
Ясадык барысын да!
Ялт итте машинабыз,
Йөрергә ашыгабыз!
Машинаны без йөртеп
Карадык әле генә

Тик йөрми әле менә.
Шуңа этеп йөртәбез,
Әй артыннан этәбез,
Этәбез дә төртәбез,
Арып-талып бетәбез,
Тик барыбер этәбез.
Йөрер өчен машина,
Тиеш йөри белергә.
Шуңа күрә без аны
Өйрәтәбез йөрергә!

— Бу нинди тукталыш булыр?

— ... . (Уенчыклар тукталышы).

— Әйе шул, акыллым. Синең яраткан уенчыкларың тукталышы. Ә синең иң яраткан уенчыгың нинди уенчык?

— ... .

— Алай бик яраткач, син аны бик саклыйсың, кадерлисеңдер инде, шулай бит?! Әминә апагыз да сезгә шундый бала турында язып калдырган.

Йокла инде, курчагым

Зәңгәр күзле курчагым,
Әлли-бәлли ит әле,
Синең бит йоклар чагың,
Тәмләп йоклап кит әле.
Аргансың инде, җаным,
Йокла, минем матурым,
Мин дә синең яныңа
Ял итәргә ятармын.
Йокла инде, курчагым,
Йомылмаса да күзең,
Сине йоклата торгач,
Йоклап китәм бит үзем.

Аюым

Йом күзеңне,
Аюым,
Көтмә кояш

Баюын.
Әлли-бәлли
Бәлли-бәү,
Йом күзеңне,
Аюым.
Һаман ачык
Күзләреңә,
Ник йоммыйсың
Үзләрен?
Әлли-бәү,
Бәлли-бәү,
Тыңламыйсың
Сүзләрем,
Күзлисең
Күк йөзләрен.
Һаман ачык
Күзләреңә.
Җырлый-җырлый
Әлли-бәү
Йомылган
Үз күзләрем...

Җәүдәт Дәрзаман

Иң матуры — мин!

Бүген минем туган көн.
Булсын иде ул һәр көн!
Матур бүләк алып килде
Мине котларга һәркем.
Аю, куянны ошаттым,
Сокланамын этемә.
Хәзер бүлмәм охшап калды
Уенчык кибетенә.
Уенчыклар җанлы түгел,
Еламыйлар, көлмиләр.
Иң матуры — мин үзем бит,
Никтер шуны белмиләр.
Ә әнием беләчәк,

Хәзер йөгереп киләчәк.
Ул гына аңлаячак:
Иң матурлар арсыннан
Тик мине сайлаячак.

Йолдыз

Бөтерчекләр

Бөтерчекне бөтерәм,
Бөтергечне бөтерәм,
Бөтерәм бергә-бергә,
Бөтерәм берәм-берәм,
Бөтергәләп бетерәм.
Үзем дә бөтереләм -
Мин бөтерелә беләм.
Бөтереләм дә торам,
Бөтереләм дә торам,
Бөтереләм дә торам -
Әйләнеп бөтен дөньям,
Шап идәнгә утырам...
Мин үзем тик утырам,
Әйләнә бөтен дөньям,
Әйләнә бөтен дөньям.
Әйләнә бөтен деньям,
Тотынып кына торам.
Бөтергечне бөтермим,
Бетерчекне бөтермим,
Нигә һаман бөтерим.
Бераз ял да иттерим.
Артыграк бәйләнгәнмен -
Башлары әйләнгәндер!...

Шәүкәт Галиев

Туп-туп тубыбыз

Туп-туп тубыбыз,
Син безнең матурыбыз,
Тишмәбез дә югалтмабыз,
Оста тота кулыбыз.

Рөстәм, сиңа да бирәбез,
Әйдә уйныйбыз бергә,
Кирәк аны, чөеп-чөеп,
Тотып ала белергә.
Туп сикерә, син дә сикер,
Тыпыр-тыпыр тыпырда,
Дуслар белән уйна бергә,
Читтә генә утырма.
Туп-туп тубыбыз,
Сикерәбез, көләбез,
Югары оч, түбәнгә төш,
Без тотып өлгерәбез.

Атынам

Һич кенә дә китә алмыйм,
Үзем алга талпынам.
Ничек инде китә алыйм —
Мин таганда атынам.

Курчак өем
Нинди матур, күрәсезме, курчак өем,
Җыеп куйдым аны чиста, пөхтә итеп.
Курчакларны тезеп куйгач матур итеп,
Песием дә карап тора исе китеп.

Әминә Бикчәнтәева

Һәр баланың яраткан уенчыклары була. Ә синең андый уенчыкларың бармы? Сиңа аны кем бүләк итте?

Уенчыкларны да саклап тотарга кирәк. Артык күп уенчык җыю да яхшы түгел. Үзеңә кирәкмәгәнен башкаларга бирергә була. Ә инде уйнап туйгач, аларнытиешле урынга җыеп куярга кирәк!

Уеңда — уен гына

Нинди генә хайваннар юк
Каюмнарда.
Жираф та бар, дөя дә бар,
Аюлар да.

Каюм кулга өйрәткән шул
Һәммәсен дә.
Арысланны, бүрене дә,
Кәҗәсен дә.
Бергә йоклый Каюм белән
Крокодил да.
Ул әйткәнне сүзсез тыңлый
Хәтта фил дә.
Тыңламый тик аны бары
Муйнак кына.
Һич аңламый, йөри бары
Уйнап кына.
Мөмкин түгел өйрәтергә
Һич берничек!
Уенчык эт түгел шул ул,
Ул — чын көчек!

Рафис Корбан

Ул шуңа кечкенә

Әнием гел миңа:
— Үскәнем минем, — ди.
Ник минем курчакның
Үскәне күренми?
Әй, минем курчагым
Ашамый һич кенә.
Ул шуңа үсми шул,
Ул шуңа кечкенә.

Заһирә Гомәрова

Түз инде

Куянымның бер колагын,
Белмим, кайсы өзгәндер.
Бик тә авырткандыр инде,
Белмим, ничек түзгәндер...
Түзүен дә түзгәндер ул,
Инде менә моннан соң
Мин сөйләгән шигырьләрне
Ничек итеп тыңлар соң?

Әни эштән кайтсын инде,
Түз, куяным, түз генә,
Әниемнән яңа колак
Тектермен үзеңә!

Рафис Корбан

Уенчыклар

Без уйныйбыз залда,
Ни генә юк анда:
Тун кигән аюлар,
Кыланчык маймыллар,
Тиеннәр, керпеләр,
Мөгезле пошилар,
Мыеклы песиләр,
Куяннар, төлкеләр,
Әтәчләр, тавыклар,
Кәҗәләр, сарыклар.
Батыр без — курыкмыйбыз
Аюдан, маймылдан,
Кочаклап алабыз
Маймылның муеныннан.

Бари Рәхмәт

Юмартлар

Апамның зур курчагы
күзләрен йома белә.
Минем шаян маймылым
эченә төртсәң көлә.
Апамның телефоны —
өреп тутыра торган.
Минем автомобилем —
ачкычын бора торган.
Апам белән без дуслар,
уенчык алмашабыз.
Икебез дә без юмарт —
беркайчан талашмабыз.

Ренат Харис

Курчакларым

Курчакларым кечкенә,
курчакларым туңмасын.
Шуның өчен аларга
шакмаклардан өй ясыйм.
Өйләренә өстәл дә
конфет куям өстәлгә.
Конфетлары аз калса,
әзер торам өстәргә.
Чәй китереп өлгерәм,
рәхәтләнә тегеләр...
Безгә рәхәт, димиләр,
рәхмәт әйтә белмиләр:
курчакларым сөйләшмиләр,
шуңа күрә үсмиләр.

Рөстәм Мингалим

Шамкайның шары

Шамкайның булган шары,
Тары бөртеге бары.
Шамкай аны кабарткан,
Ул өргәнче, таң аткан.
Бер сулыш һава тулган,
Йомырка чаклы булган.
Шамкайны өскә чөйгән,
Күк түбәсенә тигән.
Бәрелгәч, шар “бум” иткән,
Шамкай мәтәлеп киткән.
Күлдәвеккә ул төшкән,
Каргаган шарын эчтән...
Әле һаман утыра,
Төшенә алмый тора.
Аңлый алмый берничек —
Шамкайның башы тишек.

Ленар Шәех

Кәгазь Очырткыч

Балалар җибәргән кәгазь Очырткыч, югары һавадан, җирдән аз гына күтәрелеп очкан Күбәләкне күргәч: «Мискин, ышанамсың, син миңа аз гына күренәсең бит. Син, бичара, минем бу кадәр югары очканыма, әлбәттә, көнләшә торгансың», — диде.

Күбәләк җавапта: «Юк, бер дә көнләшмим аның өчен, син никадәр югары очсаң да, бәйләүдә генә очасың; минемчә, мондый гомер итү бәхеттән бик ерак булырга тиеш. Әмма мин никадәр түбән очсам да, бәйләүдә очмыйм; минем үз иркем — теләсәм кая барам. Мин синең төсле, бөтен гомеремне берәүнең кәефе өчен фида итмим», — диде.

Габдулла Тукай

Минем батыр куяным

Бу әниләр,
Бу әтиләр,
Бу әбиләр:
— Һәрнәрсәдән курка инде,
Бигрәкләр дә куркак инде,
Куркак инде куян! — диләр...
Ә мин менә,
Ә мин менә,
Ә мин менә
Һич ышанмыйм куяннарның,
Шундый йомшак наяннарның
Бигрәк куркак икәненә...
Минем әнә,
Минем әнә,
Минем әнә
Өйдә матур куяным бар,
Ап-ак, батыр куяным бар,
Булса да бик нәни генә!
Курыкмый ул,
Курыкмый ул,
Курыкмый ул
Минем бармак янавымнан,
Чиертеп алсам танавына,
Селкенеп тә карамый ул.

Кишер сорап,
Кишер сорап,
Кишер сорап,
Минем кыю, шук куяным –
Минем уенчык куяным! –
Күзләремә карап тора.

Ләбиб Лерон

Туп

Сикерә минем алда
Акыллы туп,яңа туп –
Аның әле бер кат та
Тәрәзә ватканы юк!

Григоре Виеру

Туп

Туп сикерә «туп» та «туп».
Булмый гына туктатып!
Идәннән дә сикерә,
Түшәмнән дә сикерә,
Сикерә дә сикерә —
Бар өйне ду китерә.
Чалтырт!
Көзге көл булды.
Туп та шунда шым булды.
Безнең туп бик чая ул,
Шәп сикерде бая ул,
Эзлик әле, кая ул?
Түшәмдәме?
Туп бит ул -
Идәндә дә юк бит ул!
Тәрәзәне күр анда:
Ишек ясап буранга,
Туп сикергән... урамга!

Җәүдәт Дәрзаман

Курчак

Таңсылуның курчаклары,
Белмим, ничә дистәдер...
Киштәләргә тезеп куйсаң,
Әллә ничә киштәдер.
Кара, сары, кызыл чәчле,
Зәңгәр чәчле курчаклар...
Таңсылу бүген кайсысың
Кулга алыр, кочаклар?
Күлмәкләре - ялтыр-йолтыр,
Озын, кыска итәкле.
Алкалары, йөзекләре...
Сумкалары бизәкле...
Ул аларны киендерә,
Юындыра, ашата...
Тагын нәрсә эшлим диеп,
Озак кына баш вата.
Жырлар жырлый; әкиятләр,
Шигырьләр дә сөйли ул.
Таңсылуның сөйләме дә
Әкрен, матур, көйле ул.
Бергәләшеп, бу курчаклар
Машинада жилдерә.
Атка да атланып чаба,
Уйнап кала җил генә.
Курчаклары Таңсылуга
Һәр эштә дә булыша.
Уенчыкларны җыйганда
Курчаклар да тырыша.
...Әнисе урыннар җәя.
Кай арада кич җиткән?..
Таңсылу курчакларыннан
Алданрак йоклап киткән!

Ленар Шәех

— Дустым, уен турында уйлап китап укуны онытып җибәрмә, яме. Укуга да, уенга да вакыт булырга тиеш.

Кадерлә син китапны

Китап — киңәшчең синең,
Дустың, ярдәмчең синең,
Ул хөрмәткә бик хаклы,
Кадерлә син китапны.
Почмакларын бөкләмә,
Битләрен дә ертма син,
Керле кулың белән аны
Беркайчан да тотма син.
Ул яратмый пычракны-
Керне, тузанны, тапны,
Саф, керсез күңелең белән
Бик чиста тот китапны.
Көн дә укы син аны:
Китап — якын дустың ул,
Синең сорауларыңа
Җавап биреп торыр ул!

Хәсән Шабанов

Курчак

Алиянең туган көненә әтисе белән әнисе матур курчак бүләк иттеләр. Курчак шундый гүзәл иде. Беренче көнне Алия аннан күзен алмый карап торды. Ул курчакның бишеге дә, аны төрергә, киендерергә киемнәре дә бар иде. Аларның матурлыгына таң калырлык. Бишек аллы-гөлле итеп бизәлгән, үзендә, салават күперендәге кебек, әллә нинди төсләр бар. Бишек-арба ялтырап тора. Аны тоткан саен тотасы, уйнаган саен уйныйсы килә. Алия бүләкне бик яратты, кая барса да, аны кулыннан төшермәде. Башка балалардан яшереп тотты, алар тиярләр дә, курчагы ватылыр дип курыкты. Берничә көн узгач, Алиягә ялгызы гына уйнау күңелсез була башлады. Курчагы да ул кадәр матур күренми, аның бишеге дә һуш китәрлек түгел икән. Ул хакта ул әнисенә дә әйтте. Әнисе елмайды, кызының башыннан сыйпады:

— Кызым, сиңа ялгызыңа гына күңелсездер?
— Күңелсез!
— Кызым, ә син башклар белән кушылып уйна.
— Минем бит курчагым бер генә.
— Бер курчак барыгызга да җитә.

— Башкалар аны ватарлар.

— Алар да аны синең кебек саклап тотарлар.

— Юк, минем курчагымны беркемгә дә бирәсем килми.

— Дусларың белән бергә уйна. Шул чагында сиңа да, дусларыңа да күңелле булыр.

Алия әнисе белән ризалашты. Ул ишегалдына чыкты. Аны ишегалдындагы барлык бала-чага әйләндереп алды. Барысы да курчакны мактадылар, аның матурлыгына сокландылар. Алиянең яңа курчагы белән ишегалдындагы бөтен бала уйный башлады. Курчакны дус кызлары алмаштилмәш тирбәттеләр, бишек-арбаны да бергәләп этеп йөреп карадылар. Бөтенесе дә шат иде. Алия дә шатланды, бер курчак бөтенесенә җитте.

Чыннан да, бергә күңелле икән шул.

Илүсә Нәбиуллина

Минеке, тимә!

Гөлгенәнең уенчыклары бик күп. Тик бергә уйнарга иптәше генә юк. Бүген әбисе аның белән уйнарга күрше малае Фәритне чакырды. Алар башта бик тату уйнадылар.

Шунда матур бер уенчыкка Фәритнең күзе төште. Аны кулына алды. Ә Гөлгенә чырылдап кычкырып җибәрде:

— Минеке, тимә!

Аш бүлмәсеннән әбисе килеп чыкты.

— Алай ярамый, Гөлгенә! Бергә уйнагыз. Уенчыкларыңны бир, — диде ул.

Гөлгенә, теләмичә генә, бер кулы чыккан, бер аягы сынган курчакны Фәриткә сузды. Тик кулсыз курчак Фәритне тиз туйдырды. Ул икенче уенчыкка үрелде. Гөлгенә яңадан чырылдый башлады:

— Минеке, тимә! Үзем уйныйм!

Гөлгенәнең әбисе тагын килде.

— Алай ярамый, кызым. Бергә уйнагыз дим бит инде! Һай, кемгә охшап болай комсыз соң син? — диде ул.

Көтмәгәндә Гөлгенә уенчыкларын җыеп алды да кочаклап күтәрә башлады.

— Әйдә, теге бүлмәгә чыгып уйныйк, — диде ул.

Фәрит әйбәт малай икән. Гөлгенәгә булышам дип, берничә уенчыкны ала башлады.

Гөлгенәнең чырае сытылды.

— Минеке, тимә! Үзем күтәрәм!

Ул бөтен уенчыкларын да үзе күтәреп китәргә азапланды. Шулай кылана торгач, әнисе бүләк иткән алтын тоткалы бәләкәй чәйнеген төшереп ватты. Ватты да бик ямьсез итеп еларга кереште.

Тагы әбисе килеп җитте.

— Һай, харап иттең ич! Үзең генә уйнагач, үзең генә күтәргәч, шулай була инде ул! — диде.

Абдулла Әхмәт

Синең нинди уенчыкларың бар? Син аларны саклап тотасыңмы? Дусларың белән бүлешәсеңме? Ничек уйлыйсың, матур уенчыклар белән үзең генә уйнау яки башкалар белән бергәләшеп уйнау күңеллеме икән?

Әлбәттә, уенчыкларны кадерләп тоту — дөрес. Ләкин башкалар белән уенчыкларың белән бүлешү, бергәләп уйнау — иң дөресе. Саран булмаска кирәк!

— Акыллым, ә син уенчыкларың белән нинди уеннар уйныйсың?

— ..., ...

— Булдырасың. Үскәнем, ә уенчыксыз уйный беләсеңме соң син? Уенчык булмагач нинди уен булсын инде дип уйлыйсың инде син, шулай бир? Бар шул уенчыксыз да уйнап була торган уеннар бар. Мин бәләкәй чакта без бик еш кына бармак уеннары уйный торган идек. Сине дә таныштырасым килә. Син каршы түгелдер бит?

— Юк.

— Акыллым, татар телендә бармак уеннары бик күп. Әйдә әле, башта бергәләп бармакларның исемнәрен әйтеп чыгыйк. Әйе, әйе, бармакларның да кешеләрнеке кебек үк исемнәре бар: кырыйдагы иң калын бармак — баш бармак, аның янында имән бармак, аннан соң — урта бармак, аннан — атсыз бармак һәм кырыйдагы иң кечкенәсе чәнчә бармак. Әйдә әле тагын бер кабатлыйк: баш бармак, имән бармак, урта бармак, атсыз бармак, чәнчә бармак. Исеңдә калдырдыңмы? Ярый бик яхшы. Инде, акыллым, бармак уеннары уйнап карыйк. Син дә кабатла яме?

Баш бармак бау ишә,
Имән бармак имән кисә,
Урта бармак утын кисә,
Атсыз бармак ат җигә,
Чәнчә бармак чәй эчә.

— Бармак, бармак, кайда булдың?

— Бу абый белән урманга бардым.

— Бу абый белән кырда йөрдем.
— Бу абый белән ботка ашадым.
— Бу абый белән җыр җырладым.

Олыга — утын ярырга,
Ә сиңа — чыгып алырга,
Уртага — мичкә ягарга,
Ә сиңа — казан асарга,
Чәнчигә — җырлый башларга,
Дусларның күңелен ачарга.

Баш бармагым туп була,
Имән бармак — бөтерчек.
Урта бармак була шакмак,
Атсыз бармак — сикергеч.
Чәнти бармак — барабан,
Сана, әйдә, яңадан.

Фәрсия Зиннурова

Карга килде — казан асты,
Торна килде — тоз салды,
Саескан килде — салма салды,
Күгәрчен килде — күп ашады.
Кечтеки бәби туймый калды.
Кетер, кетер, кетер,
Казан төбен кимер.

Карга килер — казан асар,
Торна килер — тоз салыр,
Саескан килер — токмач салыр,
Песнәк килер — пешерер,
Чыпчык килер — төшерер,
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Моңа бирер, моңа бирмәс,
Кечкенә түти туймый калыр,
Кетер, кетер, кетер,
Казан төбен кимер...

— Син бу әйтешләрне иптәшләреңә дә өйрәт, әти-әниең белән дә, әби-бабайларың белән дә кабатла, яме? Ә хәзер әйдә әле, акыллым, бергәләп туп-туры уеннар тукталышында төшик. Ул тукталыш “Мин уйнарга яратам” дип атала.

МИН УЙНАРГА ЯРАТАМ

— Акыллым, ә син беләсеңме, уеннар дөнья белән, тирә-як белән танышырга ярдәм итәләр. Татар халкының җырлы-биюле уеннары бик күп. Хәзер мин сине шулар белән таныштырам. Уйнап та карарбыз. Әйдә, уеннар дөньясына!!!

Чума үрдәк, чума каз

Уйнаучылар кара-каршы ике рәт булып тезеләләр, парлашып кулга — кул тотыналар. Рәт башында бер ялгыз уенчы басып тора. Балалар барысы бергә җырлыйлар:

Чума үрдәк, чума каз,
Тирән күлне ярата ул, ярата.
Әлфия үзенә иптәш эзли,
Белмим, кемне ярата шул, ярата.
Илназны ярата шул, ярата.

Уйнаучылар, җыр ритмына туры китереп, хәрәкәтләнеп торалар. Ялгыз бала, рәт арасыннан узып, үзенә бер иптәш сайлый һәм аны җитәкләп ахырга барып баса. Үз парыннан аерылган уйнаучы рәт башына китә.

Уен шулай дәвам итә.

Кунаклар

Балалар, кулга — кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Кырыйдагы балалар түгәрәк буенча әйләнеп җырлыйлар:

Ямьле бәйрәм көн килде,
Чакырдык без кунаклар;
Кунакларны сыйларга,
Салдык майлы коймаклар.
Чыж-пыж итеп коймаклар
Җәелде, әй, җәелде.
Менә тагын кечкенә
Булып калды, җыелды.
Җыелды, әй, җыелды.
Аннан ары кабарды,
Кабарды, әй, кабарды.

Шиңде, юп — юка калды.
Пеште инде коймаклар,
Сыйландылар кунаклар,
Сыйландылар кунаклар.
Тордылар, баш иделәр,
Таралдылар, әй, шатлар,
Биилəр, ай-яй, шатлар.

Кулларын як-якка җәяләр. Кысылалар. Кулларын югары күтәрәләр. Чүгәлиләр. Эчләрен сыпыралар. Баш ияләр. Биилəр.

Түбәтәй

Балалр түгәрәкләнеп басалар. Түбәндәге җырны җырлый-җырлый, түбәтәйне бар-берсенә бирәләр:

Түбәтәеңне кигәнсең,
Бик ераклардан килгәнсең,
Төскә матурлыгың белән
Шаккатыряйм, дигәнсең.
Кушымта:
Түп – түп-түбәтәй,
Түбәтәең укалы.
Чиккән матур түбәтәең
Менә кемдә тукталды.

Җыр ахырында түбәтәй кемдә калса, шуңа җәза бирелә (бии, җырлый, әтәч булып кычкыра н. б.). Уен шулай дәвам итә.

Зәңгәр чәчәк

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала, чигүле кечкенә мендәр тотып, уртага чыгып баса. Балалар түгәрәк буенча җырлап әйләнәләр:

Юл читендә зәңгәр чәчәк
Якты нурлар тарата.
Безнең кызлар һәм малайлар
Зәңгәр чәчәк ярата.

Тукап биеп-җырлап торалар, ә уртадагы бала, мендәр тотып, түгәрәк буенча биеп йори:

Якын дуслар арасыннан
Берсен сайлап ал әле.

Тезләреңә ипле булыр -

Мендәреңне сал әле.

Мендәр тоткан бала мендәрен бер бала алдына куя һәм, тезләнеп, аңа кулын бирә. Ул бала аның тирәли әйләнә, башкалар кул чабып торалар.

Балалар түгәрәккә басалар. Берәү, күзен бәйләп, түгәрәк уртасына утыра. Балалар, кулга-кул тотыгнышып, түгәрәктә җырлап әйләнәләр:

Утыр, утыр, Мәликә,

Алмагачның төбенә,

Кем утырган каршыңа,

Әйтеп бирче тиз генә.

Берәү аның янына килп утыра. Уртадагы бала аны капшап танып исемен әйтергә тиеш. Әгәр белмәсә, аңа җәза бирелә. Уен шул рәвешчә дәвам итә.

Ак калач

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Берсе уртага чыгып баса. Түгәрәктәге балалар, җырлый-җырлый, калачның ничек пешүен, җәелү-кысылулуарын кул хәрәкәтләре белән күрсәтәләр:

Булатның туган көненә

Без пешердек ак калач;

Менә шулай ул биек,

Менә шулай тәбәнәк,

Менә шуның киңлеге,

Менә шуның тарлыгы.

Ак калач, ак калач,

Теләгәнеңне сайлап кач!

Бала үз урынына берәүне сайлап чыгара да түгәрәктәгеләргә кушыла. Уен-җыр шулай дәвам итә.

Түбәтәйле

Уртада 5-6 урындык тора, урындыкларга түбәтәйләр куела. Балалар урындыклар тирәли басалар һәм, көй башлануга, җиңелчә йөгерә башлыйлар. Көй туктауга, түбәтәйләрен кияләр, шул арада урындыкларга утырып өлгерергә тиешләр. Кем урынсыз кала, шул уеннан чыга. Икенче мәртәбә уйнаганда. Уртада өч урындык кала, уйнаучылар саны артыграк була. Соңга таба бер урындык калдыралар. Шулай итеп, иң игътибарлы, җитез бала билгеләнә.

Агыйдел

Балалар, парлашып, бер бер артлы басалар. Бер бала парсыз кала, ул алга чыга. Кушымтаны җыр таганда, балалар кулларын бер-берсенә тотынган килеш өскә күтәрәләр (күпер ясыйлар). Шул вакытта парсыз бала күпер аркылы чыга һәм үзенә ошаган баланы сайлый. Уен дәвам итә.

Агыйделнең суларында
Ак чиләгем күмелде.
Әйдә, дустым, безнең якка,
Безнең яклар күңелле.

Кушымта:
Зәңгәр чәчәк жыя-җыя,
Зәңгәрләттем чиләкне.
Бергә-бергә уйныйк әле,
Бир дускаем, кулыңны.

Әйт, күгәрчен!

Балалар түгәрәккә басалар. Ике бала уртага чыгып баса. Алар уенны алып баручылар һәм җыр башлаучылар булалар. Балалар салмак көйгә түгәрәк буйлап җырлап әйләнеп йөриләр. Җыр эчтәлегендә нәрсә турында сүз барса, шул хәрәкәтне бергәләп башкаралар:

Әйт, күгәрчен, син генә,
Яшь кызлар ничек йөри?
Ул шулай да, ул болай,
Яшь кызлар йөри шулай.

Балалар яулык очларын тотып йөриләр.

Әйт, күгәрчен, син генә,
Куяннар ничек йөри?
Ул болай да, ул шулай,
Куяннар шулай йөри.

Куян кебек сикереп йөриләр.

Әйт, күгәрчен, син генә,
Үрдәкләр ничек йөри?
Ул болай да, ул шулай,
Үрдәкләр шулай йөри.

Як-якка янтаеп, алпан-тилпән йөриләр.

Миңлебай

Балалар түгәрәк уртасына бер бала сайлап чыгаралар. Үзләре кулга-кул тотынышып, түгәрәк байлап жырлап йөриләр:

Без йөрибез әйләнеп,
Син уртада, Миңлебай,
Син нишләсәң, ни кылансаң,
Без кыланырбыз шулай.

Кырыйдагы балалар туктап калалар, уртадагы бала, җырлый-җырлый, нинди дә булса, хәрәкәт күрсәтә:

Бер болай, бер болай,
Иә, кылыныгыз шулай.

Балалар аның җырын, ул ясаган хәрәкәтләрне кабатлыйлар:

Бер болай, бер болай,
Моны эшләү бик уңай.

Уртадагы бала түгәрәктән берәүне уртага чыгара да, бергә әйләнеп, үзе аның урынына баса.

Уртага кыз бала чыгарылса, түбәндәгечә әйтәләр:

Без йөрибез әйләнеп,
Син уртада, матуркай.
Син нишләсәң, ни кылансаң,
Без кыланырбыз шулай.

Яулык алыш

Бу уен күбесенчә кыз балалар тарафыннан уйнала. Кызлар бер урынга түгәрәкләнеп басалар һәм бер кеше яулык җыючы итеп сайлап куялар. Ул уртага чыгып баса да:

Талым, талым, талчыбык,
Уртасында бал чыбык,
Ал яулык, гөл яулык,
Бир син миңа бер яулык, -

дип, такмаклый-такмаклый, барлык кызлардан да яулык җыеп чыга. Җыеп бетергәч, яулык хуҗаларына берәм-берәм җәза бирелә. Җәзадан соң уен тагын яңадан башлана.

Кәрия-Зәкәрия

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Түгәрәктәгеләр бер якка хәрәркәт итеп җырлыйлар. Җырларда уртадагы баланың укуда, хезмәттә, җыр-биюдә булган сәләте, уңганлыгы мактала:

Бу бик яхшы биюче,
Бу бик яхшы биюче,
Аның биюе матур,
Аннан үрнәк алыгыз.

Җырдан соң түгәрәктәгеләр туктап калалар, кул чабып, такмак әйтәләр:

Кәрия-Зәкәрия, коммая,
Кәрия-Зәкәрия, коммая,
Кәри комма, Зәкәр комма,
Зәкәрия коммая

Бу вакытта уртадагы бала бер иптәшен алып әйләнеп тора. Әйләнеп туктагач, чакырган иптәшен калдырып, түгәрәккә баса. Тагын җыр башлана:

Бу бик яхшы җырлаучы,
Бу бик яхшы җырлаучы.
Аның җырлавы матур,
Аннан үрнәк алыгыз.

Шулай йөзүче, укучы, буяучы һ.б. дип төрлечә әйтеп, җырлап-биеп уенны дәвам итәләр.

Яшерәм яулык

Балалар түгәрәк ясап басалар. Кулларын артка куялар. Санамыш ярдәмендә яулык салучы билгеләнә. Аның кулында кулъяулык. Ул, үгәрәктән чыгып, шушы сүзләрне җырлап йөри:

Кулъяулыгым яшел, яшел,
Яшел чирәм астында.
Сиздермичә ташлап китәм
Бер иптәшем артына.

Сүзләрне әйткәндә, бер баланың уч төбенә кулъяулыкны калдырып китә. Үзе түгәрәк эченә кереп баса. Кулъяулыклы бала, тиз генә артка чыгып, сүзләрне әйтә-әйтә, уенны дәвам итәргә тиеш. Әгәр ул тоткарланып торса яки кулъяулык салганны сизмәсә, аңа җәза бирелә.

Куянкай

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар. Түгәрәк уртасына кереп, бер бала чүгәли Ул — "куян ". Куян, бер кулын иягенә куеп, моңаеп утыра. Түгәрәктәгеләр җырлый-җырлый әйләнәләр:

Ак куянга ни булган,
Әллә инде авырган?
Иптәшен дә табалмый,
Урыныннан да торалмый,
Куян, куян, син сикер,
Иптәшең табып китер!

Куян биленә таянып сикерә башлый. Аннан бер иптәшен уртага алып әйләнәләр дә, чакырылган бала куян булып кала. Уен шулай дәвам итә.

Болында

Балалар кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп баесалар. Бер бала уртада кала. Түгәрәктәгеләр, әйләнә буенча бер якка хәрәкәт итеп, җыр җырлыйлар:

Чәчәкләр үскән болында
Җырлыйбыз әйлән-бәйлән.
Халидә, Халидә,
Әйләнәсең кем белән?

Халидә бер иптәшен уртага ала.

Җыр тагын кабатлана:

Әминә, Әминә, Әйләнәсен кем белән?

Шул рәвешчә уртага 5-6 бала җыелгач, уртадагылар түгәрәкләнеп басалар да, кырыйдагыларга капма-каршы юнәлештә хәрәкәт итеп, барысы бергә җырлыйлар:

Гөлнара, Гөлнара,
Син каласың уртада.

Хәрәкәт туктала. Уртадагылыр күмәк рәвештә бер яраткан җырларын башкаралар. Аннан соң, Гөлнарадан башкалары кырый түгәрәккә басалар, һәм уен яңадан башлана.

Без-без, без идек.
Без-без, без идек,
Без унике кыз идек;
Базга төштек бал каптык,
Келәткә кердек май каптык;
Кап та коп, кара, Якуб,

Тимер туп,

Авызыңны ач та йом! М-м-м

Балалар уен сүзләрен көйләп әйтәләр, аннары, берьюлы авызларын йомып, җиңелчә, күңелле көйгә төрле шаян хәрәкәтләр ясыйлар. Кем көлеп җибәрә, шул уеннан чыга һәм җәза үтәргә тиеш була (җырлый, бии, сорауларга җавап бирә һ.б.).

Башмакчы

Балалар түгәрәк ясап басалар. Өлкәннәрдән берәү уенны оештыручы була. Ул, кулына бер башмак алып (башмак уйнаучы балаларның аяк размерыннан зуррак булырга тиеш), уртага баса. Җырлый:

Төрле һөнәр беләбез,

Матур итеп тегәбез;

Асыл төсле җепләр белән

Башмак башын чигәбез.

Балалар аңа каршы, түгәрәк буйлап йөреп, җыр җырлыйлар:

Әй, башмакчы, башмакчы,

Үзең оста такмакчы.

Син җырлама такмагын,

Бир киргә башмагын.

Балалар җырлап бетергәч, алып баручы башмакны ике бала арасыны куя һәм аларның иңнәренә кагыла. Ике бала ике якка түгәрәк буйлап йөгереп китәләр. Кем беренче килеп җитә, шул башмакны кия. Ул башмакчы була. Уен яңадан башлана.

Урманга бару

Балалар, бер-бер артлы тезелеп басалар. Марш астында атлап баралар. Урманга килеп кергәч, лирик көй тыңлана. Балалар, таралышып, салмак хәрәкәтләр ясап, җиләк җыялар, җырлыйлар:

Тиз-тиз итеп савытыма

Эре җиләкләр җыям.

Аларны йә киптерәм,

Я татлы каклар коям.

Монда җиләк күп икән,

Аю-бүре юк микән?

Соңгы юлны әйтүгә, “аю” белән “бүре” килеп чыга да балаларны куа башлый.

Ачык авыз

Балалар, аллы-артлы парлашып, түгәрәк ясап басалар. Бер бала парсыз кала. Ул уртада басып тора. Бию көе уйнала. Шул вакытта эчке якта торган балалар түгәрәк ясап җитекләшәләр һәм бию көенә әйләнәләр. Шулай бераз әйләнгәннән соң. көй кинәт кенә туктала һәм эчке яктагылар тышкы якта басып калган балалар белән парлашалар. Бер бала тагын парсыз кала. Ул, уртага чыгып: “Мин кем?” — дип кычкыра. Иптәшләре аңа: “Ачык авыз син!” — дип җавап бирәләр. Аннан соң “ачык авыз” ның бер әйбере алына. Уен шулай кабат-кабат уйнала, һәм “ачык авыз” лар биш-алтыга җиткәч, аларга җәза бирелә.

Әйдә, танышабыз

Уйнаучылар, ике түгәрәк булып, кулга-кул тотынышып басалар. Уен башлангач, алар әкрен генә җырлап әйләнә башлыйлар. Эчтәгеләр сәгат теле уңаена, ә тыштагы түгәрәк аңа каршы хәрәкәт итә. Җырның бер куплеты беткәч, барысы да туктап калалар. Ике түгәрәктәге уенчылар да бер-берсенә йөз белән борылып басалар, кулларын кысышалар: бер-берсе белән танышалар. Уйнаучылар танышып беткәнче, уен шулай дәвам итә.

Күрсәт әле, үскәнем

Балалар түгәрәк ясап басалар һәм бер баланы уртага чыгаралар. Күмәк җырлап әйләнеп, уртсдагы балага төрле эшләр кушалар. Уртадагы бала кушылган эшне башкара. Кырыйдагылар да: “Менә шулай, менә шулай”, — дип, ул эшләгән эшне кабатлыйлар. Эш кушу өчен түбәндәге җыр-такмаклар файдаланыла:

— Күрсәт әле, үскәнем,
Ничек кошлар очалар?
— Менә шулай, менә шулай,
Шулай кошлар очалар.
— Күрсәт әле, үскәнем,
Ничек йөри аюлар?
— Менә шулай, менә шулай,
Шулай йөри аюлар.
— Күрсәт әле, үскәнем,
Ничек чаба поездлар?
— Менә шулай, менә шулай,

Шулай чаба поездлар.
— Күрсәт әле, әскәнем,
Ничек сикерә куяннар?
— Менә шулай, менә шулай,
Шулай сикерә куяннар.

Гөлбаһар

Балалар, кулга-кул тотынышып, бер сафка басалар. Берсе "бакча каравылчысы итеп билгеләнә. Ул балалар алдында басып тора. Каршы яктан бер бала “көтүче” булып килә. Җырлый:

— Әй, әбекәй, Гөлбаһар,
Синең артта ниләр бар?
— Шалкан белән торма бар.
— Берсен миңа бирсәнә!
— Көчен җитсә тартып ал!

Көтүче балаларның берсен тотып үз ягына тарта башлый, ә “әби” аның юлына каршы чыгып йолкытмаска тырыша. “Шалкан-тормалар” бер-берсенә нык тотынышканнар, ычкынмаска, иптәшен дә ычкындырмаска тырышалар. Шулай берәм-берәм йолкып алып бетергәнче уен дәвам итә.

Такыя үрәм

Балалар түгәрәк ясап басалар. Тәрбияче алып баручы була. Берничә балага “чәчәк” исеме кушыла, һәм аларга шул чәчәктән ясалган башлык бирелә:

Без йөрибез болында,
Чәчәкләр бик күп монда.
Матур чәчәк җыябыз,
Такыялар үрәбез.
Алып баручы:
Ал кирәк, гөл кирәк,
Безгә нәфис гөл кирәк.
Энҗе чәчәк, кил әле,
Бер елмаеп көл әле.
Энҗе чәчәк:
Энҗедәй чәчәк атам мин
Яз көнендә урманда.
Миңа берни дә кирәкми

Күләгәләк булганда.

Балалар:

Энҗе чәчәк, күр әле!

Такыя итеп үр әле!

Энҗе чәчәк чүгәләп утыра. Уен башка чәчәкләр исемен кушып дәвам ителә. Исеме аталган нәр чәчәк уртага чыгып утыра. Шулай итеп, такыя үрелә.

Күкчәчәк:

Кечкенә көнбагыш кебек
Чәчәк булам мин үзем.
Таҗларымны санап кара,
Әгәр булсаң бик түзем.
Арыш арасында үсәм,
Зәп-зәңгәр чәчәк атам.
Зәңгәр күкле, чат кояшлы
Аяз көнне яратам.

Такыя үрелеп беткәч, такыя бер якка, түгәрәктәге балалар икенче якка әйләнеп җырлыйлар:

Без йөрибез болында,
Чәчәкләр бик күп монда.
Матур чәчәк җыйдык без,
Такыялар үрдек без.

Наза

Балалар парлашып, бер-бер артлы тезеләләр. Бер бала парсыз, ул уенчылыр каршысына чыгып баса. Балалар, җырлый-җырлый, баскан җирдә аякларын-кулларын хәрәкәтләндерәләр:

Наза дигән кыз баланың
Бөрлегәне түгелгән;
“Наза” дигән уенны без
Уйныйбыз чын күңелдән.

Кушымта:

Наза, наза,
Наза матур кыз бала.
Наза тырыш, уңган бала,
Зирәк, акыллы бала.

Кушымтаны җырлаганда, парсыз бала каршыдагы уенчылар арасыннан биеп үтә, үзенә пар сайлый, һәм алар икенче башка барып басалар. Парсыз калган бала уенны дәвам итә.

Нардуган

Бер бала уртага чыга. Башка балалар аның тирәсендә бер түгәрәк ясап, кулга-кул тотынышып, нардуган җырын җырлап әйләнәләр:

Син уртада, без кырыйда,
Әйләнәбез, нардуган,
Син нишләсең, ни кылансаң,
Мин дә шуны булдырам!

Җыр беткәндә, уртадагы бала нинди дә булса бер хәрәкәт ясый, түгәрәктәге балалар шул хәрәкәтне кабатларга тиешләр. Кем шуны булдыра алмый, уртадагы бала үз урынына аны чыгара да, уен баштагыча дәвам итә.

Бу дустың белән күреш

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә басалар һәм, җырның эчтәлегенә әйтелгән хәрәкәтләрне ясап, “Сандугач-күгәрчен” көенә җырлап әйләнәләр:

Аякларың тыпырдат,
Куларыңны чәбәклә,
Бер монда, бер монда,
Кыен эш түгел бер дә.
Башың аска иеп ал,
Кул бармагың янап ал,
Бер монда, бер монда,
Кыен эш түгел бер дә.
Бу дустың белән күреш,
Бу дустың белән күреш,
Йә иптәш, йә, әйлән,
Бик кыен түгел бу эш.

Жырга туры килгән хәрәкәтләр эшлиләр.

Түгәрәк алан

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәктә йөриләр һәм такмак әйтәләр:

Бу аланда чәчәкләр күп,
Кыймыйм ләкин өзәргә.

Әминә, Гөлфия,
Әйдә әле биергә.
Бу аланда чәчәкләр күп,
Без аларга тимибез,
Лилия, Гөлия,
Әйдә бергә биибез.

Исеме әйтелгән балалар, уртага чыгып, бергәләп әйләнәләр һәм икесе дә кырыйдагы балалар арасыннан берәр балалның каршына килеп башларын ияләр. Уен әлеге балалрның исемен әйтеп дәвам итә.

Бүген кемнең туган көне?

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер бала (туган көне булган бала) уртага чыга. Уйнаучылар, җырлый-җырлый, бер якка таба әйләнәләр, ә уртадагы бала түгәрәк эчендә каршы якка йөри. Тәрбияче балалар белән бергә җырлый:

— Бүген кемнең туган көне?
Нигә кояш елмая?
— Белдек, белдек, Гөлсинәгә
Бүген алты (3, 4, 5) яшь тула.
Гөлсинәгә карагыз:
Ничек матур киенгән!
Сәламәтлек, бәхет, шатлык
Телибез чын күңелдән.

Икенче куплетны җырлаганда, балалар туктап, кул чабып торалар, Гөлсинә бии.

Яулык бирәм

Уйнаучылар көй астында — зур түгәрәктә, ә уенны алып баручы түгәрәк уртасында бию хәрәкәтләре ясап әйләнәләр. Көй туктауга, уенны алып баручы бер бала янына килә дә: "Яулыгымны ал, кесәңә сал", — ди. Балалар: "Бер, ике,өч, дүрт, биш, тотарга тырыш!" — диюгә, бала уенны алып баручыны тотарга һәм яулыкны аннан атырга тырыша.

Җиз бүкән

Йөгереклекне, җитезлекне үстерү өчен бу уен күбрәк малайлар арасында җәй көне тышта уйнала.

Балалар бер түгәрәк булып, җирдә «җиз бүкән» булып, чүгеп утыралар. Һәрберсенең артында бер малай басып саклап тора. Арада бер малай бүкәнсез калдырылган була. Ул арттан килә дә «сакчы» белән сүз башлый:

— Җиз бүкән, җиз бүкән сатлык микән?

— Җиз бүкән сатлык икән.

— Күпме хак алыр икән?

— Хак ярым хак, пот ярым борчак икән.

— Әйдә йөгерешеп карыйк, кем килеп алыр икән? — диләр дә түгәрәк тышыннан бер-берсенә каршы йөгереп әйләнәләр. Кем иң элек әйләнеп килеп җитсә, җиз бүкән шуныкы була.

Алдыр чишмә тамчылый

Балалар, икегә бүленеп, бер-берсеннән 20–30 метр ераклыкта тезелеп басалар. Уйнаучылар бер-берсе белән кулга-кул тотынышалар. Беренче яктагылар икенче яктагыларга кычкырып такмаклыйлар:

Алдыр чишмә тамчылый,
Гөлдер чишмә тамчылый,
Ал кирәк, гөл кирәк,
Бездән сезгә кем кирәк?

Каршы яктагылар җавап бирәләр:

Алдыр чишмә тамчылый,
Гөлдер чишмә тамчылый,
Ал да кирәк, гөл дә кирәк,
Роза матур кыз кирәк.

Исеме чыккан уенчы каршы якны ң сафын йөгереп барып өзеп чыгарга тырыша. Өзә алса, бер уенчыны ияртеп, үз ягына алып кайта. Өзә алмаса, шул якта кала. Уен шул тәртиптә бер якта уенчылар беткәнче дәвам итә.

Кошлар һәм читлек

Бу уен балаларны тәвәккәл һәм түземле булырга өйрәтә. Ә уенның кагыйдәсе болай.

Уенда катнашучыларның яртысы (8–12 кеше), кулга-кул тотынышып, «читлек» хасил итәләр. Калганнары «кошлар» була. Алар төрле якта «очып йөриләр». Уенны алып баручы хәбәр биргәч, «читлек» ачыла — балалар кулларын югары күтәрәләр. «Кошлар» читлеккә кереп-чыгып йөриләр.

Алып баручы яңада н хәбәр салгач, «читлек» ябыла — балалар, чүгәли төшеп, кулларын төшерәләр. Түгәрәктән чыга алмый калган «кошлар» тотылган дип исәпләнә. Алар да, кулга-кул тотынышып, «читлек» ясаучылар янына басалар.

«Читлек» иркенәя. «Читлек» 3–4 кат ачылып-ябылгач, уенга йомгак ясала. Иң җитезләр билгеләнә. Соңыннан уенчылар урыннарын алмашалар.

Искәрмә. Әгәр алып баручы хәбәр салганда «кош»ның башы читлек эчендә кала икән, ул тотылган дип исәпләнә. «Читлек»нең эченә кермичә кырыйда гына «очып йөргән» «кош»лар да тотылганга исәпләнә.

Яшелчәләр

Яз көне ишегалдында, болыннарда уйнала торган уен. Балалар арасыннан «бакчачы», «яшелчә алучы» билгеләнеп куела. Балалар бер тирәгә җыелыбрак утыралар, һәм «бакчачы» аларның колагына яшелчә исемнәре әйтеп чыга. Шул вакыт «сатып алучы» килеп ишек кага һәм ике арада шундый сөйләшү була:

— Тук-тук!

— Кем бар?

— Мин.

— Син кем?

— Кеше.

— Нигә килдең?

— Яшелчә алырга.

— Нинди?

— Шалкан (теләгәнен әйтә).

Әгәр яшелчәләр арасында «шалкан» булса, ул торып йөгерә һәм билгеләгән урынны урап килә . Әгәр «сатып алучы» ул арада аны куып тота алмаса, «шалкан» үз урынына килеп утыра, һәм, аңа яңа исем кушылып, уен дәвам итә. Әгәр бала тотылса, ул уеннан чыга. Уен «яшелчәләр» тотылып беткәнче дәвам итә.

Майламыйча купмый

Түгәрәк уртасында берәү тәңкә салып йөри. Бөтен кешеләргә салып бетергәч ул: «Тәңкә батыр, сикереп тор», — ди.

Тәңкәле кеше: «Майламыйча купмый», — ди. Шуннан соң тәңкә салучы йә бер җыр башкара, йә биеп күрсәтә, аннан болар урыннарын алышалар: җырлаган (биегән) кеше утыра, икенчесе тәңкә салучы була.

Мин качам, син тот

Уйнаучылар кулга-кул тотынышып, парлап басалар. Алда, аларга каршы, уенны алып баручы баса. Балалар бергәләп:

«Без, балалар, яратабыз качыш-тотыш уйнарга. Әйдә безне тотып кара, көчең җитсә тотарга», — дип әйтүгә, беренче булып басып торган пар кулларын ычкындыра, һәм икесе ике якка йөгереп китә. Уенны алып баручы аларның берсен тотарга тиеш. Тотылган кеше уенны алып баручы була.

Чыпчык, чык

Балалар түгәрәккә басалар. Уртада бер бала кала. Ул — сыерчык. Сыерчык бер бала янына килә дә: «Чык әле, әй, кошчык , исемең кем?» — ди. Ул бала: «Чыпчык», — дип җавап бирә һәм: «Ә үзең кем соң син? Йөрисең ник борчып?» — дип сорый. Сыерчык: «Кем дисеңме, чыпчык? Мин булам сыерчык. Бу минем йортым, чык моннан, чык, чык, чык», — ди. Алар икесе дә түгәрәк тышына чыгып, икесе ике якка йөгерәләр һәм, йөгереп килеп, буш «ояга» керергә тырышалар. Урынсыз калган бала түгәрәк эченә баса һәм сыерчык итеп билгеләнә. Уен шулай дәвам итә.

Буяу сатыш

Кызлар бер якка, малайлар икенче якка тезеләләр. Уен алып баручы (буяу сатучы) кызларга буяу төсләре атап чыга.

Малайлар берәм-берәм «буяу» сатып алырга киләләр. Алучы сатучыга болай ди:

Буяуларың бар микән,
Зәңгәр микән, ал микән?
«Төсем матур, мине ал», —
Диючесе бар микән?
Буяу сатучы җавап бирә:
Буяуларым күптән күп:
Зәңгәр, кызыл, яшел, күк.
Кайсы һөнәрен күрсәтсә,
Шуңа шөһрәт, даннар күп.

Сатып алучы, үзенең нинди дә булса һөнәрен күрсәткәннән соң, буяу төсе бирелгән кызларның берсен алып, үз сафына китә. Аннан «буяу» сатып алырга икенче малай килә. Уен «буяу»лар алынып беткәнче дәвам итә.

Самовар

Самовар һәм әби сайланып куела. Калганнары читкәрәк тезелешеп утыралар. Әби балаларга ширбәт исемнәре әйтеп чыга, аларны «самовар» ишетмәскә тиеш. Әби, «самовар»ның колагын тотып: «Чәй эчәргә килә-килә... шикәр!» — ди.

«Шикәр», акрын гына килеп, «самовар»ның аркасына төртә дә үз урынына барып утыра. «Самовар» карый, балаларны ң барысы да баш бармакларын өскә каратып утыра.

«Самовар» кем төрткәнен әйтергә тиеш. Әгәр белсә, тоткан бала «самовар» була. Белмәсә, «шикәр»гә икенче исем кушылып, уен дәвам итә. Өч мәртәбә әйтә алмаган «самовар»га җәза бирелә.

Гөрләмеш, яки кача-кача

Гөрләүчене берәр койма, багана як и өй-келәт почмагына, койма артына илтеп, өйдә булса, почмакка илтеп гөрләтәләр.

Бу урын барлык уйнаучыларга да «оя» була. Гөрләүче коймага яки почмакка карап йөзе белән баса һәм йөзен каплап гөр-гөр әйтә:

Гөр-гөр гөрлимен,
Вакыт күбен белмимен,
Вакыт күбен белер идем,
Мин бит сезне күрмимен.
Инде озак гөрләдем,
Моннан ары түзмимен.

Ул әйткәнче, балалар качып бетәргә тиеш. Алардан бер дә тавыш-тын килмәсә, гөрләүче эзли башлый. Ул кемне дә булса, берәр уйнаучыны күрсә, исеме белән кычкыра. Шуннан ул гөрләгән ояга кайсы элек килеп кулы белән кагылса, шунысы тотылмаган була. Әгәр дә гөрләүче ояга качучыдан алдан килеп баскан булса, йә качканда аркасына сугып өлгерсә, ул качучы отылган була да гөрләүче урынына баса.

Гөрләүче барлык качучыларны да табып чыгаргач, уен тагын башлана.

Мәкаль әйтеш

Балалар түгәрәкләнеп утыралар. Берәүнең кулында төйнәлгән кулъяулык була. Ул алар алдына чыгып баса да әйтә:

— Мин мәкаль әйтүче булам. Мәкальнең беренче яртысы минем телемдә, икенче яртысы шушы төендә. Хәзер мин, сезгә бер мәкальнең яртысын әйтеп, бу яулыкны кайсыгызга булса да ыргытырмын да, «бер, ике, өч...» дип, алтыга хәтле санармын. Мин шулай санаганчы, яулык тигән кеше тиз генә шул мәкальнең икенче яртысын әйтеп өлгерергә тиеш. Әйтә алган кеше мәкаль төенен чишкән дип санала, әйтә алмаучыга җәза бирелә.

Шулай ди дә, уен башлана. Әйтик, уртадагы бала: «Ни чәчсәң, ...» — дип, яулыгын берәүгә ыргыта. Яулык тигәне аңа: «Шуны урырсың»-дип җавап бирә. Тагын моңа мисаллар:

Ыргытучы: Кем эшләми, ...

Яулы к тигәне: шул ашамый.

Ыргытучы: Какма кеше капкасын, ...

Яулы к тигәне: ү з капкаңны кагарлар.

Ыргытучы: Ачтан үлсәң дә, ...

Яулы к тигәне: ата-анаңны ташлама.

Ыргытучы: Ачы булсаң, тоздай бул, ...

Яулы к тигәне: татлы булсаң, балдай бул.

Ыргытучы: Бер тиенлек куян, ...

Яулы к тигәне: у н тиенлек зыян.

Ыргытучы: Берәү туеп сикерә, ...

Яулы к тигәне: берәү туңып сикерә.

Ыргытучы: Ашаганда колагың селкенсен, ...

Яулы к тигәне: эшләгәндә йөрәгең җилкенсен h. б.

Ыргытучы алтыга хәтле санаганчы җавап таба алмаган кешегә җәз а бирәләр. Яулыкны алган соңгы кеше, тагын берәр мәкальнең беренче яртысын әйтеп, яулыгын икенче кешегә ыргыта. Уен шулай дәвам итә.

Ашханә

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Уенны алып баручы уртага чыгы п баса һәм түгәрәктәге балаларны ң һәммәсен ризык исемнәре белән атап чыга. Аннан соң ашханәдә булган берәр вакыйга турында ирекле хикәя сөйли башлый. Хикәягә балаларга кушылган ризык исемнәре керү мәҗбүри.

Хикәя барышында исеме чыккан бала әйләнеп алырга тиеш. Әгәр моны эшләмәсә, ул уеннан чыгарыла. «Ашханә» дигән сүз чыкканда барлык балалар да әйләнәләр. Уен түгәрәктә бер генә бала калганчы дәвам итә. Ул җиңүче була.

Ак, димә, кара, димә...

Балалар тезелеп утыралар. Санамы ш ярдәмендә сорау бирүче билгеләнә. Ул балаларга төрле сораулар бирә. Аңа җавап бирүче «ак», «кара», «әйе», «юк» димәскә тиеш. Башны түбән иярге һәм көләргә дә ярамый. Сорау алучы, бер баланың каршына басып, әйтергә ярамаган сүзләрне әйттерү өчен, юри сораулар бирә:

- Синең күлмәгең нинди, акмы?
- Кызыл.
- Синең аягыңда туфлимы?
- Итекләр.
- Сөтнең төсе нинди? һ. б.

Әгәр бала, ялгышып, әйтергә ярамаган сүзләрнең берәрсен әйтсә, йә булмаса башын исә, яки көлеп җибәрсә, ул бала сорау алучы була. Уенның кагыйдәсен шигырь юллары белән әйтеп, уенны дәвам итә:

«Ак», димә, «кара», димә,
Башыңны түбән имә.
«Әйе», димә, «юк», димә,
Көлмә, елмайма.

Чүлмәк сатыш

Балалар җиргә «чүлмәк» булып түгәрәкләнеп утыралар.
Артларына һәрберсенең «хуҗа»сы баса.
Берәү чүлмәк алучы була һәм:
- Чүлмәк сатасыңмы?- дип сорый.
Хуҗа:
- Сатмыйм, каймак саласым бар,- ди. Яки:
- Мин китсәм, каймагымны урлыйлар,- ди.

Шул рәвешле сөйләшкәндә, хуҗалар, «чүлмәк»ләрен җиң чабулары белән каплап торалар. Сүзгә мавыгып торганда, алучы «чүлмәк»нең баш киемен, яулыгын сыдырып ала да:

«Ачык авызларның каймагын шулай итәләр»,- дип, икенче хуҗага килә. Йөгереп-йөгереп берсе дә сатмагач, яңадан баштагы хуҗага дәшә:

- Чүлмәгеңне сатасыңмы инде?

- Сатам.

- Күпмегә сатасың?

- Өчкә,- дисә, өч мәртәбә (күпме әйтсә, шулкадәр) кул сугышалар. Сатучы белән алучы ничәгә килешсәләр, түгәрәк тышынна н кара-каршы шулхәтле чабышалар . Кем алдан килсә, чүлмәк шунықы була, аның артына баса. Артта калучы чүлмәк алучыга әйләнә. Уен шулай дәвам итә.

Почмак алыш

Балалар мәйданчыкның төрле урыннарында басып торалар. Алар - «әбиләр». Бер бала, «әбиләр» янына килеп, мунча сорап йөри:

- Әби, мунча бир әле?

- Мунчам буш түгел әле.

- Әби, мунча бир әле?

- Ташы төшкән.

- Әби, мунча бир әле?

- Мунча салырга агач юк. (Шулай итеп, төрле сәбәпләр әйтелә.)

Аннары тиз генә: «һоп, һоп!» - дип, берничә мәртәбә кычкыралар. Шушы вакытта балалар урыннарын алыштыралар.

Мунча сораучы бала шушы арада берәрсенең урынын алып өлгерергә тиеш. Кем урынсыз кала, шул уенны дәвам итә.

Песи белән тычканнар

Бу да почмак алыш уеннарының бер төре. Уенда биш бала катнаша. Уйнаучыларның берсе «песи» була. Калган дүртесе, «тычкан» булып, почмакта урын алалар. Песи уртада тора.

Тычканнар үз почмакларында торганда, ул аларга тимәскә тиеш. Тычканнар һәрвакыт урыннарын алмашырга йөгереп торалар. Шул чагында песи аларның берсен тотарга тырыша.

Шуңа күрә урыннарын алмашырга теләгән тычканнар элек бер-берсенә күз белән яки кул белән ымлап, йә булмаса йөткереп, «Әйдә урыннарны алмашабыз!» дигән серне белдерәләр.

Шул вакыт песи, башын аска игән, күзен йомган булып, астан гына аларны күзәтеп тора. Тычканнар, аннан көлеп, як-яктан такмаклыйлар:

Мияу-мияу мышнаган,
Мич башында кышлаган,
Бүген тычкан тотмаган,
Тотар иде йоклаган.
Песи-песи поскан,
Ике күзен кыскан,
Кысса безне тоталмый,
Тотар иде, җиталмый...

Шулай дип җырлашка н арада, алдан ымлашкан буенча, берсе икенчесенең почмагына таба чаба башлыйлар. Шул чагында песинең «күзләре ачыла», почмакка җиткәнче бер тычканны тотып ала. Кулына төшкән тычкан песи була да, элгәреге песи, буш почмакны алып, тычкан була. Уен шулай дәвам итә.

Алырмын, кош!

Балалар арасыннан «тилгән» һәм «ана кош» сайлап куела. Калган балалар «бәбкәләр» була. Алар «ана кош» артына бербер артлы булып тезеләләр, бер-берсенә ныклап ябышалар.

«Тилгән» «ана кошка» ташлана: «Алырмын, кош!» «Ана кош», кулларын җәеп, балаларын саклый, «тилгән» кайсы якка ташланса, шунда «тилгән»гә каршы чыга: «Бирмәмен, кош!» «Тилгән» иң арттагы баланы тартып ала алса, үз оясына алып китә һәм уенны дәвам иттерә. Уен вакытында балалар чылбырны ычкындырмаска, «ана кош»тан ераклашмаска тырышалар.

Песием, песием

Бер бала икенче балага кул сыртын сузып тора. Икенчесе, аның кул сыртын сыйпый-сыйпый, түбәндәгечә тиз-тиз такмак әйтә:

Песи, песи, пес итәр,
Ана песи сөт эчәр,
Ана песи сөт эчкәндә,
Ата песи күз кысар.
Ал дигәндә алмасаң,
Лап итәр дә шап итәр!

«Лап итәр» дигәндә, сыйпаганы теге баланың кул сыртына шап иттереп суга. Тегесе кулын тартып алып өлгермәсә, отылган була. Отылмаса, тегесе сыйпаучы, монысы сугучы була.

Буш урынлы

Йөгереклек һәм җитезлекне булдыру өчен булган бу уен җәй көне тышта, кышын киң залларда ир һәм кыз балалар арасында уйнала.

Шобага яки санашу юлы белән берәүне көтүче итәләр дә, калган балалар, бер түгәрәк ясап, бер-берсенең кулларына тотынышып торалар. Көтүче, түгәрәк тышыннан сагалап, түбәндәгечә җырлап йөри:

Саескандай чыйкаклап,
Мин йөримен өй саклап,
Каздай булып кыйгаклап,
Сиңа тиям, син әбәк!

Шулай дип берсенең аркасын а суга да түгәрәк әйләнә йөгерә. Сугылган бала, урыныннан чыгып, аңар каршы яктан йөгерә. Алдан әйләнеп килеп җиткәне шул буш урынны ала. Урынсыз калганы көтүче була да, уен дәвам иттерелә.

— Үскәнем, алга таба сиңа тәкъдим ителгән уен сине йорт хайваннары дөньясына алып кереп китәчәк.

Ак калач

Балалар түгәрәкләнеп тезеләләр. Уртада уенны алып баручы була. Балалар түгәрәк буенча җырлап әйләнәләр:

Әминә апа туган көнне
Пешердем мин ак калач.
Ул калачны, мин сиңа әйтим,
Менә шулай кабарган.
(Балалар кулларын югары күтәрәләр.)
Ул калачны, мин сиңа әйтим,
Менә шулай җәелгән.
(Балалар кулларын як-якка җәяләр.)
Ул калачны, мин сиңа әйтим,
Менә шулай ябышкан.
(Балалар чүгәлиләр)

Ахырда уртага икенче бала чыгып, уен яңадан башлана.

Без дә

Иң беренче уенны алып баручы билгеләп куела. Ул салмак кына берәр вакыйга сөйли. Әгәр аның сөйләмендә балалар башкара ала торган хәрәкәт-шөгыль телгә алынса, уенчылар хор белән «Без дә!» дип кычкыралар. Аларның хәленнән килми торган эшләр турында сөйләнелсә, дәшми калырга тиешләр. Кем дә кем булдыра алмас шөгыль, хәрәкәт турында сүз барганда ялгышып «Без дә!» ди икән, ул кеше уеннан чыгарыла. Мәсәлән, уенны алып баручы шундый хикәя сөйли:

— Мин урманга киттем (уенчылар «без дә!» диләр). Урманда мин җиләк җыя башладым («без дә!»). Менә көчле җил чыкты (дәшмиләр). Яңгыр ява башлады, күк күкрәде (дәшмиләр). Мин печән куышы астына кереп утырдым («без дә!») һ. б.

Уен җавап бирүчеләрнең берсе генә калганчы дәвам итә. Һәм ул җиңүче булып санала. Икенче уенда ул уенны алып баручы була.

Аксак төлке

Балаларның берсе шобага, я санашу юлы белән Аксак төлке, икенчесе өй хуҗасы итеп сайлана. Башка балалар тавыклар булып, зур бер түгәрәк сызыкка кереп тулалар. Аксак төлке, бер аягын күтәреп аксаклап, ерактан килеп чыга һәм өй хуҗасын күреп туктый. Алар үзара шулай әйтешәләр:

— Төлке, Төлке, Түләнтәй, Төнлә кая барасың?

— Мамай улы Бикчәнтәй, Әбиемә барамын.

— Әбиеңдә ниең бар?

— Мич артында туным бар.

— Туның янса нишләрсең?

— Суга илтеп салырмын.

— Туның акса нишләрсең?

— Үкереп елап калырмын.

— Төлке, Төлке, Түләнтәй, Тунсыз ничек йөрерсең?

— Мамай улы Бикчәнтәй, Йөргән чакта күрерсең.

Шулай әйтешкәннән соң, хуҗа тынычланып «йокларга ята». Төлке сыңар аяклап тавыклар оясына төшә дә аларны куа башлый һәм куып җиткәнен кулы белән яки кулындагы салам камчысы белән әбәкләп-тәпәләп калырга тырыша. Кулга төшкән бала Аксак төлке була.

Аксак төлке ялгышып икенче аягы белән дә җиргә басса, хуҗа күреп, аның үзен куа башлый. Әгәр төлке үз оясына җиткәнче тотылса, ул яңадан төлке булып уйнарга тиеш була.

Алырмын кош

Зуррак балалардан берсе «ана» булып сайлангач, «балаларын» үз артына кош итеп тезә һәм алар бер-берсенә тотынышып, җитен карарга баралар. Арадан тагын бер бала, усал «карчык» кыяфәтенә кереп, аларның юл өстенә килеп чыга һәм таяк белән җир казып утыра. Аның турысына җиткәч, «ана» белән «карчык» арасында шушындый әйтешү була:

- Әби, нәрсә казыйсың?

— Бер тиен акча казыйм.

— Ул акча нигә кирәк?

— Энә алырга.

— Ул энә нәрсәгә?

— Капчык ямарга.

— Ул капчык нәрсәгә? Таш тутырырга.

— Ул таш нәрсәгә?

— Синең балаларыңны таш атып куарга.

— Ни өчен балаларымны таш атып куасың?

— Ак сыерымның маен шулкадәр ашаганнар, кара сыерымныкын шулкадәр. (Кулы белән күрсәтә.)

— Ялгыш күргәнсең, әби, без кеше базына төшмибез, үз эшебез артыннан йөрибез.

— Ә сез кая барасыз?

— Җитен карарга барабыз.

Минекен дә карап кайтыгыз, күпме үскәнен әйтерсез. Балалар, тезелешеп, арттан билләреннән тотынышкан хәлдә җитен карап әйләнеп кайталар.

Усал «карчык» башын күтәрмичә генә:

— Минем җитенем күпме үскән? — дип сорый. Балалар:

— Әби, синеке болай гына, безнеке болай үскән, — дип, куллары белән «әбинең» җитенен җирдән генә итеп, үзләренекен күктән итеп күрсәтәләр.

«Әби», аларның куллары бер-берсенең билләреннән ычкынганын күрү белән, урыныннан сикереп торып, аларны йолкып алырга ташлана. Балалар бер-берсенә тотынып өлгермәсәләр, «әби» шунда ук берсен үзенә тартып ала. «Әби» белән «кызлар анасы» бер-берсенә шулай әйтешәләр:

— Алырмын кош!

— Алма кош!

— Алырмын кош!

— Бирмәмен кош!

«Алырмын кош» уңнан да, сулдан да балалар янына үтмәкче була, аны «Бирмәмен кош» үткәрми, аның торган ягына каршы тора, «балалары» «анага» ышыкланып бер яктан икенче якка өерелеп торалар.

«Карчык» тагын хәйләгә ябыша: — Ярар, бирмәсәң бирмә, кодагый, әнә күктән бер кашык май төшә, кара әле.

Явыз «карчык» шулай дип алдап аны күккә карата да шул арада бер баланы йолкып алып китә. Тагын килә:

— Алырмын кош!

— Бирмәмен кош!

— Әнә күктән койрыклы йолдыз төшә...

Яки тагын шундый берәр хәйләле сүз әйтеп күккә каратып, тагын бер «баланы» йолкып алып китә. Балалар, бер-берсенә тотынган булсалар да, «карчык» «Алырмын кош!» дип, аларны берәмләп йолкып алып, качсалар, куып тотып бетерергә тиеш була. Аннан соң яңа «әби» сайлап, уен яңадан дәвам итә.

Ат карагы

Өлкәнрәк яшьтәге малайлардан берсе ат карагы, икенчесе йорт хуҗасы булып уйный. Калган яшьрәк малайлар атлар ролен башкаралар. Ат карагы хуҗаның ишеген шакый:

- Тук-тук-тук!

— Кем бар анда?

— Мин бер юлчы. Ерактан кайта идем. Кундырып чыгармассыңмы?

— Бик кундырыр идем дә, өем тар шул. Йокла шунда атлар янында, салам өстендә.

— Ярар, алайса.

Хуҗа ята да «йокыга китә». Ат карагы да йоклаганга салышып хырлап-хырлап куя. Әледән-әле, хуҗа йоклады микән, дип сыңар күзен ачып карый. Хуҗаның «йоклаганына» тәмам ышангач, «атларның» берсен эләктерә дә (күлмәк итәгеннән тотып) чыгып чаба. «Аты» да кешнәгән була. Хуҗа куа чыга, әмма каракны тота алмый.

Ә бераздан «карак» киемнәрен әйләндереп кия дә янәдән «хуҗа» йорты янына килә. Өстәвенә әле чатанлаган була.

— Әй, абзый, өеңә кертче.

— Бу караңгы төндә ат урларга йөрисеңдер әле.

— Юк, абзый, юк, ерак-ерак җирләрдән кайтып килешем. Бик туңдым, керт инде.

— Кара аны, атларга тиясе булма. Бер көнне дә бер юлчыны керткән идем, иң әйбәт атымны урлап качты.

— Шулаймыни?! Берәү бик шәп атка атланып Иделне чыгып бара иде — шулдыр әле, мөгаен.

Сүз шул характерда дәвам итә. Бераздан «хуҗа» да, «карак» та йокыга талалар. «Карак» янә бер атны урлап кача. Шулай төрле-төрле «хәйләләр» белән килә-килә, «карак» «хуҗа »ның барлык атларын берәм-берәм урлап бетерә. Аннан Ат карагы Хуҗа, Хуҗа Ат карагы роленә кереп, уен яңадан башлана.

Кап та коп

Берничә бала бер түгәрәк булып утыралар, бер-берсенең баш бармакларын учлаган килеш, йодрыкларын йодрык өстенә куеп, кулларын бергәләп күтәреп-төшереп шуны әйтәләр:

Без-без, без идек,
Без унике кыз идек;
Базга төштек бал ашадык,
Келәткә кердек май ашадык;
Өйгә мендек өйрә эчтек,
Коега төштек су эчтек;
Бер тактага тезелдек,
Таң атканчы юк булдык,
Кап та коп,
Авызыңны ач та йом! —

диләр дә барысы да берьюлы авызларын йомалар.

Моннан соң уенчылар берсе дә авызын ачмаска, көлмәскә, сөйләшмәскә тиеш.

Алар бер-берсен көлдерү өчен төрлечә кыланалар, күз-йөз белән төрлечә ымнар ясыйлар. Кем иң элек авызын ачса, йә көлеп җибәрсә, аннан:

— Күктән кемнең өе башына төштең? — дип сорыйлар.

Ул берәр таныш өйне атый. Шуннан соң ул өйдә ире, хатыны, балалары белән ничә кеше булса, көлүченең үзен дә кушып, һәрбер уйнаучы бу көлгән кешенең кулына йә маңгаена шулар санынча чиртеп ала. Уен тагын яңадан башлана.

Әйләп-бәйләп уены

Әтәч коймага менгән дә:

— Кикрикү-үк! — дип кычкыра башлаган.

— Кикрикү-үк, уяныгыз, йорт хайваннары-ы! Әйдәгез, әйләп-бәйләп уйныйбыз!

Маэмай килгән:

— Һay-hay, мин риза! — дигән.

Үрдәк килгән:

— Бак-бак, мин дә риза! — дигән.

Бака килгән:

— Кур-рыйк, кур-рыйк, мин дә уйныйм! — дигән.

Тавык килгән:

— Кыт-кытыйк, мин дә катнашам! — дигән.

Бахбай килгән:

— Иһа-ha-ha, мине дә алыгыз уенга! — дигән.

Каз килгән:

— Кыйгак-кыйгак, мин дә әйләп-бәйләп уйныйм! — дигән.

Песи килгән:

— Мыр-мияу, мин дә, мин дә уйныйм, — дигән. Барысы да әйләп-бәйләп уйный башлаганнар.

Әйләп-бәйләп уйныйбыз,
Матур җырлар җырлыйбыз;
Беребез гармун, беребез курай,
Беребез кубыз уйныйбыз.

— Үскәнем, әйт әле, әтәч ничек кычкыра?

— ... .

— Ә песи?

— ... .

— Ә хәзер бергәләп кабатлыйк: ат әйтә – иһа-ha-ha; каз әйтә – кыйгак-кыйгак; үрдәк әйтә – бак-бак; бака әйтә – кур-рыйк, кур-рыйк.

— Булдырдың. Акыллым, син хәзер рәхәтләнеп, тирә-яктагы кош-кортлар белән сөйләшә аласың. Татар халык авазы үрнәкләрендә кош-кортлар белән сөйләшеп уйный торган уеннар күп. Син халык авыз үрнәге дигән төшенчәне аңлыйсыңмы соң?

— ... .

— Әйе, әкиятләр, табышмаклар, такмаклар, мәзәкләр, мәкальләр халык авыз иҗаты үрнәкләре булып тора. Ә менә кара-каршы әйтешләрне ишеткәнең бармы синең?

— ... (Юк.)

— Юкмыни? Әйдә әле, нәни дустым, кара-каршы әйтешләрне тыңлап китик.

— Монда май бар иде, ул кайда?

— Тычкан ашаган.

— Тычкан кайда?

— Мәче ашаган.

— Мәче кайда?

— Салам астында.

— Салам кайда?

— Үгез ашаган.

— Үгез кайда?

— Тегермән астында.

— Тегермән кайда?

— Утка янган.

— Ут кайда?

— Көл булган.

— Көл кайда?

— Күккә очкан.

—

— Әйтештә кулланылган сүзләрне бергәләп әйтеп карыйк әле, яме, дустым. Кабатлаганда, сүзләр хәтердә җиңелерәк кала: тычкан, мәче, салам, үгез, тегермән, ут, көл. Син бу сүзләрне аңлыйсыңмы соң?

— (Барысын да түгел).

— Барысын да түгелме? Әйдә алай булганда, кайбер сүзләрнең рус теленә тәрҗемәләрен дә әйтеп китик: салам — солома, үгез — бык, тегермән — мельница, ут — костер, көл — зола. Тагын бер кат бергәләп кабатлыйк әле. Син әзерме? Әйдә: салам — солома, үгез — бык, тегермән — мельница, ут — костер, көл — зола. Сиңа әйтешләр ошадымы, акыллым?

— ... .

— Алай булганда, әйдә әле тагын бер әйтеш тыңлап китик, яме?!

— Песи, кая барасың?

— Әбиләргә барамын.

— Анда сиңа ни тия?

— Ике калак май тия.
— Аны кая куярсың?
— Мич астына куярмын.
— Пычранса нишләрсең?
— Суга төшеп юармын.
— Төшеп китсәң нишләрсең?
— Талга ябышып чыгармын.

— Акыллым, әйтеш нәрсә белән алып барыла?
— ... .
— Ә сезнең песиегез бармы соң?
— .... .
— Синең песиең бар икән. Ә менә кемнеңдер юктыр. Булмаса да күңелсезләнмә, үскәнем. Уенчыкларың арасыннан эзләп кара әле, уенчык песиең булмыйча калмас. Таптыңмы? Яхшы. Әйдә хәзер песи белән әйтеш уйнап алыйк. Песи булып әйткәндә тавышыңны үзгәртергә тырыш, минем кебек итеп, яме, үскәнем. Кабатлыйбызмы..., әйдә әле.
— Песи, кая барасың?
— Әбиләргә барамын.
— Анда сиңа ни тия?
— Ике калак май тия.
— Аны кая куярсың?
— Мич астына куярмын.
— Пычранса нишләрсең?
— Суга төшеп юармын.
— Төшеп китсәң нишләрсең?
— Талга ябышып чыгармын.
— Афәрин, булдырдың. Песи булып та сөйләшә аласың икән.

Әйтештә калак, мич асты, тал сүзләренаңладыңмы икән, үскәнем? Аңламасаң да зарар юк, бергәләп карап китик: калак ул икенче төрле кашык дигән сүз, мич асты — под печкой, тал — ива. Исеңдә калдыра алдыңмы? Я кабатлап кара әле, кадерлем.

— Калак // кашык, мич асты, тал. Үскәнем, вакыт табып, үзең әле генә сөйләшкән песинең рәсемен дәфтәреңә ясап куярга онытма, яме? Үзенә исем дә бир, без бит бармакларның да исемнәре булганын белеп киттек, песинең дә исеме булырга тиештер инде , шулай бит.

— Акыллым, сиңа тагын бер әйтеш ишеттерп китергә телим әле. Ул алдагы әйтешләрдә аерылып тора. Нәрсә беләнме? Тыңлыйк әле, минемчә, үзең дә әйтә алырсыңдыр. Син бик зирәк бала бит, шулаймы?

— Дуслар кая барасыз?
— Карурманга барабыз.
— Карурманда нишлисез?
— Кура җиләк җыябыз.
— Җиләк белән нишлисез?
— Җиләктән как коябыз.
— Бүре килсә нишлисез?
— Урман буйлап чабабыз.
(Күмәк җырлыйлар)
— Җиләк җыям, как коям,
Дәү әнигә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк икән

— Дускаем, бу әйтеш алдагылардан нәрсә белән аерыла инде?
— Афәрин, әйе бу әйтешне җырлап әйтәләр. Яле, акыллым, бергәләп җырлап карыйк:
Җиләк җыям, как коям,
Дәү әнигә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк икән.
— Инде үзең генә җырлап кара.
— Булдырдың. Бик матур җырлыйсың икән син. Ә әйтештәге бөтен сүзләрне дә беләсеңме соң? Әйдә тикшереп карыйк әле: карурман — ул... нәрсә була инде?
— ... .
— Афәрин. Әйе, кадерлем, биек агачлар үсә торган бик зур урман. Ул кара урман дигән сүздән ясалган.
— Ә кура җиләк?
— ... .
— Бу сүзне дә дөрес әйттең, үскәнем. Әйе шул – бакчада, куакта үсә, кып-кызыл, бик тәмле җиләк.
— Ә как нәрсә икән соң үскәнем? Синең аны ашаганың бармы?
— ... .

— Юкмыни? Җиләк-җимештән ясыйлар, күпчелек очракта алма, сливадан. Исеңә төшмәдеме?

— Юк.

— Алай булганда ярдәмгә килмичә ярамас: как – пастила була. Инде үскәнем сүзләрне бергәләп кабатлыйк: карурман, кура җиләге, как. Бу сүзләр барысы да бер-берсенә ошаганнар, игътибар иттеңме, акыллым?

— ... .

— Әйе, шул “к”га башланалар. Чү, үскәнем, тыңла әле, ниндидер сәер тавыш килә түгелме? (Тук-тук дигән тавыш ишетелә һәм аннан сң әйтеш башланып китә)

— Тук-тук. Кем анда тукылдый?
— Бу — тукран тукылдый.
— Нишли тукран? Нәрсә ясый ул тук та тук?
— Тукран ясамый, дәвалый.
— Кем авырган, кемне дәвалый ул?
— Тукран агачларны дәвалый, агачлар авырган.
— Тукран тукылдый тук та тук, аның кебек уңган юк!

— Акыллым, әйтештә сүз барган кошны син беләсеңме?

— ...

— Бик дөрес, үскәнем. Тукранны рус телендә дятель дип йөртәләр. Әйтештә тукранны ни өчен уңган дип атыйлар соң, акыллым?

— ....

— Әйе, ул агачларны дәвалый. Агачның кабыгы астына кереп яшеренгән зарарлы бөҗәкләрне чүпли, урманны чистарта. Акыллым, әйт әле тукранны тагын ничек атап йөртәләр.

— Урман докторы.

— Афәрин, кадерлем. Әйе шул аны бик хаклы рәвештә урман докторы дип йөртәләр.

— Ә хәзер, дускаем, игътибар белән әйтешләрне кабат тыңлыйк. Чөнки алдагы биремебезне үтисебез бар бит әле. Син әзерме?

— Монда май бар иде, ул кайда?

— Тычкан ашаган.

— Тычкан кайда?

— Мәче ашаган.

— Мәче кайда?
— Салам астында.
— Салам кайда?
— Үгез ашаган.
— Үгез кайда?
— Тегермән астында.
— Тегермән кайда?
— Утка янган.
— Ут кайда?
— Көл булган.
— Көл кайда?
— Күккә очкан.

— Дуслар кая барасыз?
— Карурманга барабыз.
— Карурманда нишлисез?
— Кура җиләк җыябыз.
— Җиләк белән нишлисез?
— Җиләктән как коябыз.
— Бүре килсә нишлисез?
— Урман буйлап чабабыз.
(Күмәк җырлыйлар)
— Җиләк җыям, как коям,
Дәү әнигә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк икән.

— Тук-тук. Кем анда тукылдый?
— Бу — тукран тукылдый.
— Нишли тукран? Нәрсә ясый ул тук та тук?
— Тукран ясамый, дәвалый.
— Кем авырган, кемне дәвалый ул?
— Тукран агачларны дәвалый, агачлар авырган.
— Тукран тукылдый тук та тук, аның кебек уңган!

— Кызык әйтешләр шулай бит. Кадерлем, ә хәзер бу әйтешләрне әйтүдә үзең дә катнашып ал, ягъни сорауларга җавапларны исеңдә калганча биреп бар, исеңдә калмаган җаваплар урынына үзеңнекен бир, килештекме?

—

— Монда май бар иде, ул кайда?

—

— Тычкан кайда?

—

— Мәче кайда?

—

— Салам кайда?

—

— Үгез кайда?

—

— Тегермән кайда?

—

— Ут кайда?

—

— Көл кайда?

— Песи, кая барасың?

—

— Анда сиңа ни тия?

—

— Аны кая куярсың?

—

— Пычранса нишләрсең?

—

— Төшеп китсәң нишләрсең?

—

— Дуслар кая барасыз?

—

— Карурманда нишлисез?

—

— Җиләк белән нишлисез?

—

— Бүре килсә нишлисез?

—

— Тук-тук. Кем анда тукылдый?

—

— Нишли тукран? Нәрсә ясый ул тук та тук?

—

— Кем авырган, кемне дәвалый ул?

—

— Тукран тукылдый тук та тук, аның кебек уңган юк!

— Афәрин, акыллым, менә бит нинди кызык әйтешләр килеп чыкты. Инде әйтеш уенын онытма, яме? Иптәшләреңә белән җыелганда, бу әйтешләрне исеңә төшереп, уеннар да оештыра аласың, шулай бит?!

Нәни дустым, буш вакытыңда карандашларыңны һәм рәсем ясый торган дәфтәреңне алып, әйтешләрдә очраткан геройларны ясарга онытма. Дәфтәрдәге рәсемнәрне караганда, бу әйтешләрне кабат-кабат исеңә төшерерлек булсын, сөйләштекме?

Ә хәзер бераз укып та ал. Уен уен белән, укуны да онытырга ярамый.

Тау таптым

Кичә мин тау таптым. Бүген дә шул тауга шуарга барам. Берүзем генә барам. Инде мин зур бит.

Әнкәй елмаеп тәрәзәдән карап калды. Ул минем зур икәнне белә.

Күрше Гайнулла бабай да, олы борынын тәрәзәгә үк төртеп, мине карап калды.

Мин ераккa китеп шуам, юлның теге ягына. Ә-әнә теге җиргә хәтле барам. Кичә дә шунда барган идем. Шунда мин үземә яхшы тау таптым. Чаңгым да яхшы.

Кар тирән. Карда бик күп эзләр бар. Төлке, бүре эзләре, диләр. Монда поши эзләре дә була, дип сөйлиләр. Мин үзем куян эзләрен генә таныйм әле, әтием күрсәтте.

Бүген көн салкын. Җил дә юк. Бөтен җир ап-ак! Өченче көн инде шулай. Мондый көннәрне мин санап барам.

Җайлап кына кар да ява башлады. Кар яуса, көн җылыта, дигән иде әти. Җылытыр, ахры.

Монда җәй көне нинди җылы иде! Чәчәкләр бар иде. Ак, зәңгәр, сары, ал чәчәкләр... Күбәләкләр!

Мин ак күбәләкләрне яратам. Кар бөртеге, ак булса да, күбәләк була алмый. Кыш көне күбәләк кар була, боз була...

Ә минем кулым да өшеми. Яңа бияләйләр кигәнгәдер инде. Әллә җылыта да микән?

Кара-кара! Кар бөртекләре ничек күп булып ява башлады!.. Әнә нинди эзләр күмелә! Бүре эзләредер әле, күмелсеннәр тизрәк. Алар мине бераз куркыта. Куян эзләреннән мин курыкмыйм. Тик куян эзләре күмелеп тә бетте шул инде... Кар һаман ява. Моннан безнең өебез күренеп тора. Әткәй эштә инде. Әнкәй әле дә тәрәзәдән карый микән? Гайнулла бабай да карыйдыр. Алар мине күрә микән? Хәзер мин үзем тапкан тауга менәм. Яңа карга яңа эз салам.

— Дускаем, син игътибар иттеңме, әйтешләрдә безнең тирә-яктагы кош-кортлар, табигать күренешләре турында сөйләнде. Ә безнең тирә-ягыбызда кызыклы күренешләр, хайван-җәнлекләр, кош-кортлар бик күп. Шуңа күрә алдагы тукталышыбыз итеп, “Мин табигать яратам” тукталышын сайладык.

МИН ТАБИГАТЬ ЯРАТАМ

Бу тукталышта безгә иң элек тизәйткечләр өйрәнергә кирәк. Син тизәйткечләрнең нәрсә икәнен беләсеңме? Үзең нинди тизәйткечләр беләсең?

Тизәйткечләр — беренче карашка әйтелешләре авыр булган, бер-берсенә охшаш сүзләр җыелмасы. Тизәйткечләрне укымыйлар, ә кеше әйтүе буенча кабатлыйлар. Билгеле бер авазның әйтелешенә шул аваз еш кабатланган сүзләр булган тизәйткечләр кулланыла. Тизәйткечләрне әйтеп, без аерым авазлырны дөрес әйтергә өйрәнәбез.

[а]:

Абагага бага-бага, башым бәрдем баганага.
Андый төймә Ләбибәдә дә бар, Нәфидәдә дә бар.

[ә]:

Әрәмәдәге әрем әче.

[ү]:

Күп күркәгә кирәк күп көрпә.

[ө], [ү]:

Биш үгездә
Биш мөгез.
Әй саташтым,
Ун мөгез.
Ун үгездә
Ничә мөгез,
Мүкләк булса
Өч үгез?
Санагызчы
Үзегез,
Әгәр җитсә
Көчегез.

[ж]:

Җиләк җыя Җәмилә.
Җылы җәйнең көннәрендә
Җәймә тау итәгендә
Җизни кызы Җәүһәрия
Җиләк җыя чиләгенә.

Җиләк, җиләк, җиләкләр,
Бик тиз тулмый чиләкләр.
Тулыр иде чиләге,
Юк бит аның җиләге.

[h]:

Илһам җырлый, илһам килсә,
Илһамның бар аһәңе.
Илһам абый белә микән
Халык биргән бәһане.

[къ]:

Капкага капка каршы, Капкага капка капма-каршы.

[т]:

Талга кунар бер тартар, Ул тартарны тал тартыр,
Тартар басып талны тартыр,
Тал тартыр, тартар калкыр,
Тартар калкыр, тал тартыр.

[с]:

Синең мускул мускулмыни, мускул түгел ул — мыскыл.
Менә Мостафа мускулы мускул дисәң дә мускул.
Сыерчык, сыерчык,
Нинди матур сызгырчык!

[ш]:

Дару белән өч шешә,
Шешә бавын теш чишә, шешә чишсәң теш шешә.

Кулда тукмак,
Алыйк кер тукмап:
Тукта, тукта, тукмама,
Тукма, тукма, туктама!
Туктап тукмап булмый ул,
Тукмап тукмак тынмый ул.

Андый төймә Ләбибәдә дә бар, Нәфидәдә дә бар.

Талга кунар бер тартар,
Ул тартарны тал тартыр,
Тартар басып талны тартыр,
Тал тартыр, тартар калкыр,

Тартар калкыр, тал тартыр.

Без дә таптык шәт кәҗә.
Әби әйтә: шәп кәҗә!
Сөтлесен сөтле түгел,
Ләкин бит ул шәл кәҗә,
Югалтырга жәл кәҗә.

Ра – ра – ра – ра – ракетага
Ра – Ра – Рамил утырган.
Ра – ра – ра – ра – ракетаны
Җир тирәли очырган.

Ла – ла – ла – ла, ла – ла – ла,
Кем матур җырлый ала,
Кем матур бии ала –
Шул булыр үрнәк бала.
Алмалар да
Алланган.
Алланган да
Балланган.
Бал кортлары
Аларны
Чәчәкләр дип
Алданган.

Бүрәнәләр турый-турый,
Барый абый бура бурый.
Бурасының матурлыгын
Карап йөри урый-урый.

Биш үгездә
Биш мөгез.
Әй, саташтым,
Ун мөгез.
Ун үгездә
Ничә мөгез,

Мүкләк булса
Өч үгез?
Санагызчы
Үзегез,
Әгәр җитсә
Көчегез.

Хәзер шагыйрә Марзия апагыз Фәйзуллина язган табышмакларның җавабын табарга кирәк булачак. Син, нәни дустым, үзеңнең зирәклегеңне күрсәтә күрче, яме? Әйдә әле, табышмакны игътибар белән тыңла һәм җавабын уйлап кара?!

Безз-безз, безелди,
Борынымда бар безем, ди,
Үзеннән зурга “энем”, ди.
Бумы, бу — ...
— Яле, зирәккәем, бу нәрсә булыр? Борынында без бар. Ә нәрсә соң ул без, беләсеңме?
— ... .
— Белмисеңдер шул. Без ул энәгә ошаган, ләкин калынрак һәм озынрак инструмент, аның белән калын әйберләрне тегәләр, рус телендә аны шило диләр. Шулай итеп борынында безе бар, үзе безелди, аеруча җәйге кичләрдә һич кенә дә тынычлык бирми. Җавабы булыр...
— ...
— Афәрин, әйе, озынборын.
Җәй буе бал җыя,
Кыш буе хәл җыя.
Торыр өчен бар йорты,
Шунда яши ...

— Үскәнем, тиз генә җавабын тапчы? Ничек?
— ... .
— Һичшиксез, бал корты. Тәмле, файдалы бал белән безне бал кортлары сыйлый. Ә менә алдагы табышмакның җавабын табар өчен челтәр дигән сүзне аңлау кирәк.Синең Кыш бабайның тәрәзәгә ясаган төрле-төрле бизәкләрен күргәнең бардыр, мөгаен, аларны да челтәр диләр.Челтәрне энә

белән нечкә җептән бәйлиләр, рус теледә кружева, диләр. Ә хәзер табышмакның үзен тыңлап карыйк әле:

Күрер-күрмәс күзләре,
Челтәр бәйли үзләре.
Челтәрләре түгәрәк,
Эшли алар үрмәләп.

— Кадерлем, яхшылап уйла әле — нинди бөҗәк неп-нечкә җепләрдән челтәр бәйли ала? Аның исеме үрмәли сүзенә бик охшаш.

— ... (үрмәкүч).

— Зирәклегеңә сокланып бетә алмыйм, бик дөрес — үрмәкүч. Кадерлем, ә синең табышмакларның җавабын дәфтәреңә ясап куясың килмиме? Әйдә әле, дәфтәреңне ал да ясап кара. Рәсем ясаганда җыр да тыңлап ал,ярыймы?

— Булдымы. Бик үк килеп чыкмаса да кәефсезләнмә, үскәнем. Өегездә бу бөҗәкләрне сиңа ясарга булышырга теләүче табылмый калмас. Бары тик матур итеп сорарга гына онытма, ә моның өчен нинди сүзләр кулланырсың икән?

— .... Зинһар өчен,

— Әйе, зинһар, зинһар өчен, ярдәм итә алмыйсыңмы, булышып җибәрче, күрсәтеп бирче? Шулай матур, әдәпле, тәмле итеп ярдәм итүләрен сорасаң, сиңа бик рәхәтләнеп, ярдәм кулы сузылыр.

— Ә менә Гөлнур апагыз Корбанова күбәләкләрне бик ярата икән. Әйдә әле, үскәнем, бергәләп шагыйрә апагызның күбәләк турындагы шигырен тыңлап китик һәм күбәләкләр артыннан аларның хәрәкәтләрен кабатлыйк.

Мин — күбәләк, күбәләк!
Очабызмы бергәләп?
Әйдә, җәйдек кулларны,
Күккә таба, югары,
Аяк очларыбызга
Бастык та барыбыз да
Күзләребезне йомдык
Һәм очарга тотындык.
Канатларны кагабыз,
Минем арттан калмагыз,
Болытларга менәбез,
Без бит оча беләбез!

Шулай очып йөргәндә,
Очрадык без гөлләргә.
Гөлгә кундык чүгәләп,
Чөнки без бит күбәләк!
Әй, иснибез гөлләрне!
Гөлнең исләре тәмле!
Көтә безне әнкәбез,

Гөлнур Корбанова

Бик матур шигырь, шулай бит, акыллым. Ә хәзер, әйдә әле хәрәкәтләрне кабатлап карыйк (монда музыка кирәк!): Кулларны ике якка җәйдек, аяк очларыбызга бастык, күзләребезне йомдык, кулларыбыз-канатларыбызны кагындык, чүгәләдек, күзләребезне ачтык, гөлләрне күреп, сокландык, аларны иснәдек, акрын гына тордык, канатларыбызны кагынып катырга чыктык. Үзегезне беразга гына булса да күбәләк итеп тойдыгызмы?

— … . (әйе).

— Ә шул хәрәкәтләрегезне әйтеп чыгып карагыз әле үзегез. Сез нәрсәләр эшләдегез? Әйдәгез әле бергәләп:

Кулларыбызны җәйдек.
Аяк очына бастык.
Күзләребезне йомдык.
Канатларны кагындык.
Күзләребезне ачтык.
Гөлләр күреп сокландык.
Өйгә кайтырга чыктык.

— Афәрин. Менә бит сез үзегез дә шигырь чыгарып карадыгыз. Гөлнур апагызга рәхмәт инде. Аның ярдәме белән чыгардык шигырьне.

Үскәнем, без синең белән Рафис абыегыз Корбанның шигырьләр язганын беләбез, без аларны рәхәтләнеп тыңладык. Ә Рафис абыегыз әле әкиятче дә икән, ул карга турында бик матур әкият язган. Тыңлап китәбезме?

— Бик рәхәтләнеп, дисеңме. Әйдә алай булгач. Нинди карга икән ул, әкият герое.

Карга

Ай-лю-ли, вай-лю-ли,
Әби әкият сөйли.
Борын-борын заманда,

Әби дә тумаганда,
Туса да тормаганда,
Бабай да булмаганда,
Безнең авыл каршында
Карт карама башында
Яшәгән, ди, бер карга.
Карт карга, ала карга.
Түгел лә бала карга.
Аның булган әбисе,
Әтисе һәм әнисе.
Эшкә киткәч әтисе,
Эшкә киткәч әнисе,
Нәнисенә әбисе
Әкиятләр сөйләгән.
Моңлы көйләр көйләгән:
“Кар, кар, кар, дигән,
Минем кызым бар, дигән,
Минем нәни кызымның
Дәү үсәсе бар, дигән”.

Рафис Корбан

— Менә шундый матур әкият бүләк итте безгә Рафис абыегыз.

— Без аңа нәрсә әйтәбез әле?

— Әйе, рәхмәт, әле тагын рәхмәтләр яусын, дип тә әйтергә була, шулай бит, кадерлем.

Үскәнем, кошларның да әти-әниләре, әби-бабалары бар. Алар да үз балаларын яраталар, кадерлиләр, саклыйлар. Кошлар, бөҗәкләр, хайван-җәнлекләр дә төрле-төрле хәлләргә очырыйлар. Ә язучы абый-апаларыгыз балаларга шулар турында кызыклы, мавыктыргыч әкият-хикәяләр яза. Мөгаен синең дә шуларны ишетәсең киләдер. Рәхим ит. Тыңла һәм уйла әле, ничек эшләргә ярый, ә ничек эшләргә ярамый? Нинди булырга ярый, ә нинди булырга ярамый? Ни өчен?

Баллы кузгалак

Яшәгән ди бер Кузгалак. Бик әче икән бу.

Аны ашаганда балаларның йөзләре чытыла, күзләре кысыла, телләре әчетә икән.

Ә Кузгалак балаларның йәзләре чытылуын, күзләре кысылуын, телләре әчетүен бер дә теләмәгән.

Шуннан соң Кузгалак баллыга әйләнгән. Баллы Кузгалакны балалар бик яраткан. Аны ашаганда аларның йөзләре елмайган, күзләре елтыраган, телләре тәмләнгән.

Хәзер баллы Кузгалакны чәйгә дә салып эчәләр ди, бик яраталар ди.

Тәмле телле, баллы телле, сөйкемле холык-фигыльле булсаң, сине дә шулай яратырлар.

Әхәт Гаффар

Җәрәхәтле агач

Алим бабай белән оныгы Рамил күрше авыл базарыннан кайтып баралар. Алим бабайның аркасында биштәр. Биштәрендә — әбиләренә алган чәй, җимеш, бал, йорт кирәк-яраклары...

Күрше авыл урамыннан узып барганда, бабай зәгыйфь бер яшь агачны күреп алды. Бер ботагы сынган. Әле иртән базарга барганда, ул агач сынмаган иде. Бабай, агач янына килеп җитүгә:

— Улым, бу агачны таптап бетерәләр ич. Әйдә әле, аны бәйләп куйыйк, — дип, шул тирәдә яткан таякны алды. Рамил аңа кирпеч кисәге алып килде. Бабасы таякны, агачның як-ягына бастырып, кирпеч кисәге белән кагып та куйды. Аннан соң:

— Улым, әниеңә алган кер бавын бераз кисеп алыйк әле. Шуның белән бәйләп куйыйк, — диде. Шулай эшләделәр дә.

Агачны бәйләп бетергәч, оныгы бабасыннан:

— Бабай, бу бит безнең авыл түгел. Чит авыл урамында үсеп утырган агачны бәйләп, дәвалап йөрибез. Ник үзләре карамыйлар икән, бабай? -дип сорап куйды.

Бабасы:

— Улым, күңел күзе күрмәсә, маңгай күзе — ботак тишеге, ди безнең халык. Ә агач ул, кайда үссә дә, безнеке. Базардан кайтканда, базарга барганда, гел шуннан йөрибез. Сынган агач аунап ятса, безгә дә күңелсез булыр иде. Бу җирне урап үтәр идек. Ә шаулап үсеп утырган агач яныннан үтеп йөрүе безгә дә, башкаларга да күңелле, -дип елмайды.

Нәкыйп Каштанов

Суалчан кунакка бара

(әкият)

Булган, ди, бер Суалчан.

Яңгыр аны кунакка дәшкән. Бик озаклап җыенгач, киткән бу Яңгыр янына кунакка. Бик, би-и-ик, би-и-и-и-ик озак барган, ди. Барган да барган икән. Бер дә ашыкмаган. Барып җитсә ни күрсен: Яңгыр моны көтә-көтә Карга әйләнгән.

— Кунакка кем янына барсаң да ярый. Кар, син мине кунак ит, — дигән Суалчан.

Ләкин Кар аңа ишеген ачмаган. Суалчан ач килеш үз өенә кайтып киткән.

Әхәт Гаффар

— Акыллым, суалчанны күз алдыңа китерәсеңме? Җирне тишеп озын бөҗәк җир астына төшеп китә. Аларны сакларга кирәк, чөнки алар җирне йомшарталар. Рус телендә аларны червяк диләр. Әкияттәге суалчан ни өчен кунактан ач кайткан? Гаеп кемдә? Аның ялгышы нәрсәдә?

— ... .

— Бик дөрес, кадерлем. Кунаккамы яки башка чакырылган урынгамы вакытында барырга, соңга калмаска кирәк. Һәр эшне үз вакытында эшләсәң генә өлгереп була. Ә менә хәзер тыңлаячак әкиятнең геройлары төлке белән торна. Төлкене әкиятләрдә нинди герой итеп сурәтлиләр әле, нәни дустым?

— ... .

— Әйе, хәйләкәр. Ә торна озын аяклы, озын муенлы зур кош, рус телендәге атамасы — журавль. Төлке белән торна арасында нәрсә булган икән, әйдә тыңлыйк.

Төлке белән торна

(әкият)

Төлке белән Торна дус булганнар. Төлке Торнаны кунакка чакырган. «Кунакка кил миңа, үзеңне бик тәмләп сыйлармын! — дигән.

Торна Төлкегә кунакка килгән. Төлке ботка пешергән дә аны сай гына тәлинкәгә салып куйган.

— Аша, күгәрченем, аша, үзем пешердем! — дигән Төлке.

Торна үзенең озын борыны белән тәлинкәне чукыган-чукыган, әмма авызына ботка эләкмәгән. Ул арада Төлке үзе ботканы ялап та куйган.

— Рәхмәт, сыйладың, — дигән Торна. — Иртәгә миңа кил инде!

Икенче көнне Төлке Торнага кунакка киткән. Торна аш пешергән дә аны тар гына авызлы чүлмәккә салып куйган. Шуннан Төлкене кыстый башлаган:

— Аша, җаным, аша! Башка сыем булмады, әйдә, аша шуннан гына! — дигән.

Төлке, тар авызлы чүлмәккә башын тыга алмыйча, чүлмәк тирәли тик әйләнеп йөри икән.

Ә Торна үзе, озын муенын сузып, чүлмәккә башын тыккан да ашны ашап та куйган.

— Гаеп итмә, кода, булсаң бул тук, башка сыем юк! — дигән Торна.

Шуннан аларның дуслыклары беткән.

Татар халык әкияте

— Кадерлем, ни өчен соң төлке белән торна арасында дуслык беткән? Кем гаепле? Төлке дөрес эшләмәгәнме, әллә торнамы? Кунакка башта кем чакырган?

— ... . (төлке дөрес эшләмәгән, ул торнаны хәйләләмәкче булган)

— Акыллым, мин дә нәкъ шулай уйлыйм. Кунакка чакыргач, кунакны чын күңелдән сыйларга, аңа хөрмәт күрсәтергә кирәк. Үскәнем, әйдә әле бу әкиятне икенче төрле итеп, торна белән төлкене тәрбияле, дөрес эшләгән итеп сөйләп карыйк. Мин җөмләне башлыйм, ә син әйтеп бетер, яме?

— Төлке белән торна .... (Әйе, дус булган)

— Төлке торнаны ..... (Әйе, кунакка чакырган).

— Ул төлке кунакка килә дип, ул .... (ярата торган) ризыкларны әзерләгән. Өстәленә бик матур ... (ашъяулык япкан), өстәленә ... (ризыклар) куйган.

— Менә төлке килгән. Торна аны”Рәхим ит, исән-сау килдеңме, түрдән уз дип каршылаган, өстәл артына утырткан, ... (тәмле-тәмле ризыкларбелән сыйлаган). Алар бик матур итеп үзара ... (сөйләшеп утырганнар).

— Аннан соң төлке кайтырга җыенган. Ул торнага .... (бик зур рәхмәт, ризыклар бик тәмле булды,бик рәхәтләнеп утырдым) дигән. Төлке дә торнаны үзенә кунакка чакырган. Төлке торнаны ничек кунак итте икән? Шул турыда әкиятне әниеңә яки әтиеңә сөйләп күрсәтерсең әле, яме?. Онытмассыңмы? Аннан соң бергәләп торна белән төлкене рәсем дәфтәреңә ясап та куегыз, ярыймы?

— Ә менә алдагы әкиятне Идрис абыегыз язган. Әкият мактанчык бака турында. Бака нинди сыйфатка ия һәм ни өчен ул харап була икән, тыңлый – тыңлый шул сорауларга җавап эзлик әле, кадерлем.

Мактанчык бака

(әкият)

Түгәрәк күл буенда камышлыклар төбендә яшәгән, ди, бер бакылдык бака. Үзе кечкенә булса да, тавышы бик ераклерга ишетелгән, ди. Көн димәгән, төн димәгән, һаман мактанган. “Бакка-как-как. Мине эзләп тап! Миннән оста җырчы юк. Исемем — Бакылдык, үзем бер батам, бер калкам”, — ди икән.

Шулай беркөнне бу бака су астыннан өскә күтәрелгән һәм тирә-якны яңгыратып бакылдарга керешкән: “Бакка-как-как” — ди икән бу. Шулвакыт камышлар арасында йөзеп йөргән үрдәк, баканың тавышын ишетеп, аның янына ашыккан.

Үрдәк баканың бакылдавын мактарга тотынган. Бака бик шатланган. Тагын да күбрәк бакылдаган.

— Кил әле, борыным өстенә мен әле. Колакларым катырак, җырыңны бик тансыкладым, — дигән үрдәк.

Бака бик шатланган. Үрдәкнең борынына менеп атланган. Җырларга дип авызын ачуы булган — үрдәк баканы капкан да йоткан.

Идрис Шәймөхәммәтов

— Җавап таптыңмы? Бераз күңелсезрәк әкият, шулай бит. Мактанчык булса да бака бик жәл. Сиңа да жәлме?

— ... .

Татар халык әкиятендә дә үрдәк хәйлә уйлап табырга мәҗбүр. Ни өчен икән? Нинди булырга, нишләргә ярамый? Шул сорауларга җавап табырга тырыш, яме?

Тавык нигә суда йөзә алмый?

(әкият)

Имештер, кайчандыр элек тавыкның тәпие дә, каз-үрдәк тәпие кебек бармак аралары ярылы булган да шуңа күрә күлдә бик шәп йөзгән, ди бу. Үзе һаман мактана:

— Мин шәп йөзәм дә мин шәп йөзәм! Кыт-кыт-кыт, миннән оста беркем юк! — ди икән.

Үрдәкнең моңа бик ачуы килгән:

— Әйдә, алай булса ярышабыз, — дигән.

Тавык әйткән:

— Әйдә!

Үрдәк шуннан бер хәйлә уйлаган. Күлдәге бер кысланы тоткан да әйткән:

— Син су астыннан бар да шул тавыкның бармак араларының ярысын үзеңнең кыскычың белән ерткала, шулай итмәсәң, мин синең үзеңне чукып йотам!

Кысла шулай итеп тавыкның бармак араларын ерткан да, суда йөзүдә үрдәк беренче урынны алган, ди.

Шуннан мактанчык тавык суда йөзә алмыйча, коры җирдә тырманып тамак туйдырырга калган, ди. Алай да мактануның һаман да кимен куймый, бер күкәй салса да:

— Кыт-кытак, йомырка салдым, эзләп тап! — дип, йорт күтәреп җырлый икән.

— Я, үскәнем, әкияттәге тавык нинди?

—...

— Әйе, мактанчык. Ә мактанчык булырга ярыймы соң?

—... .

— Бик дөрес, кирәксә-кирәкмәсә кычкырып, мактанып йөрү яхшы эш түгел. Син эшләгән яхшы эшләрне күреп сине башкалар мактансыннар. Миңа калса, үрдәк тә бик үк дөрес эшләмәгән, чөнки ул кысланы куркытып, кирәкмәгән эш эшләткән. Ә син кысланың нәрсә икәнен беләсеңме соң?

— ... .

— Белсәң, бик әйбәт. Әйе рус телендә аны рак дип йөртәләр. Ә менә казны үлемнән аның нинди сыйфаты коткарып калды икән. Без тыңлаячак әкият шул турыда.

Төлке белән Каз

(әкият)

Бервакыт Төлке Казны тотып алган да:

— Каз, мин сине ашыйм, — дигән. Каз боегып калган.

— Мин риза, Төлке. Тик син миңа бер биеп калырга рөхсәт ит, — дигән Каз.

— Әйдә, бие, — дигән Төлке. — Ашарга өлгерермен әле.

Каз, канатларын җилпеп, бер урында тыпырдый башлаган.

Төлке:

— Әй оста биисең, Каз, — дип көлә икән.

Ә Каз, канатларын җилпеп, бер урында торган-торган да очкан да киткән. Төлке авызын ачып калган.

— Афәрин каз, дип әйтеп мактыйсы килә казны, шулай бит, акыллым. Ә нинди сыйфаты өчен соң?

— ... (тапкырлыгы, зирәклеге өчен)

— Бик дөрес, кадерлем. Тапкыр булу бик яхшы сыйфат. Алдагы әкият герое керпе дә тапкырлыгы аркасында төлкедән котылган.

Керпе ничек энәле булган?

(әкият)

Элек Керпенең бер генә энәсе дә булмаган. Аннан хәтта тычканнар да курыкмаган. Ә хәйләкәр Төлке өчен энәсез Керпе иң тәмле азык булган, шуңа күрә керпеләр Төлке булган җирләрне урап үтәргә тырышканнар.

Керпе өстенә юка гына күлмәк киеп йөргән. Ул кием җилне дә, салкынны да үткәргән, шуңа күрә көзнең яңгырлы көннәрендә Керпе бик туңган, өшегән.

Беркөнне Керпе, ризык эзләп урманда йөргәндә, җирдә бер бик очлы энә күреп алган. Дошман очраса, коралым булыр, очрамаса, күлмәгемне ямарга булса да ярап куяр әле дип, ул энәне түшенә кадаган. Тик түшендәге энә аңа йөгерергә комачаулаган, вакыт-вакыт чәнчеп тә ала икән. Шуңа күрә Керпе аны аркасына кадап куйган һәм юлын дәвам иткән. Бара торгач, сукмакта яткан тагын бик күп энәләргә юлыккан ул.

— Бигрәк әйбәт булды әле бу! Бер энәне югалтсам, икенчесе булыр, — дип, аларны да алып аркасына кадаган, ди.

Урманның эченә үк кереп җиткәч, Керпегә кулына кәрзин тоткан Төлке очраган. Күрше авылга тавык кетәклегенә барышы булган аның. Керпене күргәч, Төлке бик куанган, хәтта иреннәрен дә ялаштырып куйган. Тик энәләрен күргәч, шаккаткан: бу көнгә кадәр энәле Керпе күргәне булмаган аның.

— Керпе, сеңелкәй! Бер энәңне миңа да биреп тор әле! Затлы тунымның иң матур җирен көя кимергән, ямар идем, — дип алдашкан хәйләкәр Төлке.

— Ярар, ярар! Хәзер иң очлысын сайлап бирермен! — дигән Керпе. Ул энәләрен бер-бер артлы чыгарган һәм күлмәгенең төрле-төрле җирләренә

кадый барган. Ә үзе бертуктаусыз: — Тукта әле, бу энә бик очлы булмады, бусы да очлы түгел! — дип сөйләнә икән.

Төлкенең түзеп торыр чамасы калмаган, һәм ул сикергәләп китеп барган. Үзе эченнән генә: «Нигә мин кадерле вакытымны энәле бер Керпегә әрәм итеп торам соң әле? Энәсезләре дә очрамый калмас. Йотып җибәргәндә, энәләре тамагыма кадалса, нишләрмен?» — дип уйлый икән.

Шулай итеп, хәйләкәр Төлке Керпене алдый алмаган. Ә берничә көннән урмандагы бөтен керпеләр энәле тун киеп йөри башлаганнар. Хәзер аларга Төлке дә, салкын җилләр дә куркыныч түгел, ди.

Флера Мәрданова

- Акыллым, керпе сиңа ошадымы? Ни өчен?

— ... .

— Әйе, шул. Ул акыллы, тапкыр, зирәк. Шундый керпене дәфтәреңә ясап куясың килә торгандыр, мөгаен. Керпене ясау бик җайлы. Моның өчен ярым түгәрәк ясарга һәм аңа энәләр утыртып чыгарга кирәк. Яле ясап кара, үскәнем. (музыка) Килеп чыктымы, афәрин, кадерлем.

— Үскәнем, алга таба тагын берничә әкият укырбыз. Бу әкиятләрне ттатар язучысы Абдулла Алиш язган. Бу әкиятләрне син өйдә әти-әниең белән дә укый аласың.

Куян кызы

Бер соры куянның үзе төсле зур колаклы, бик иркә, бик кадерле бер кызы булган. Ул аны бик-бик ярата икән. Көннәрдән бер көнне куян иркә кызына өр-яңа киез итекләр алып кайтып биргән.

— Мә, бәбкәм, аякларың туңмасын, сызламасын, — дигән.

Кызы бу буләкне бик шатланып алган. Әнисенә рәхмәтләр укыган. Хәзер инде ул яңа киез итекләрне киеп, рәхәтләнеп йөри икән. Ләкин куян кызы җылы итекләргә өйрәнмәгән булган, ул алардан бик тиз туйган, салып ташлаган. Әнием тапмасын дип, аларны яшереп куйган. Әнисе аларны эзләп табып баласына кигезә, ә ул салып ташлый икән. Әнисе кигезсә — ул салган, әнисе тагын кигезгән, ә ул тагын салып ташлаган. Кар өстеннән дә, боз өстеннән дә яланаяк йөгерә икән. Бер көн буе шулай йөгергән, икенче көнне дә шулай яланаяк йөргән, өченче көнне инде аксый-аксый әнисе янына килгән.

— Әни, әни, минем аягым бик авырта! — дигән. Әнисе аның аякларына караган да аптырап калган.

— Кызым, кызым, якты йолдызым, синең аягың шешкән ич, — дигән.

"Инде ни эшләргә?" — дип уйга баткан куян. "Бу бал аны кая алып барырга, ничек дәваларга?" — дип кайгырган.

Шул вакыт нәрсәдер кычкырган. Куян агач башына күтәрелеп караган икән — тиенне кургән. Ул куянга болай дигән:

— Кайгырма, туганкай, йомшак куянкай, кызыңның аягын бик тиз төзәтеп була. Моның өчен "доктор Айболит"ка барырга, аңардан киңәш сораргa кирәк, — дигән.

Куянга чын-чынлап булышырга тотынган, "доктор Айболит"ның өенә узе илтергә булган. Куян кызын күтәргән дә "Айболит доктор "га киткән, тиен, агачтан агачка сикереп, аңа юл өйрәткән. Барып җитсәләр, "доктор Айболит "ның эше бик күп икән, аңа урманның төрле ерткычлары дәваланырга килгәннәр икән. "Балаларны чиратсыз карыйм мин", — дигән "доктор Айболит". Куян кызын доктор алып кергәннәр, нәрсә белән авыруын сөйләп биргәннәр. "Доктор Айболит" куян кызының аягына дарулар сөрткән һәм шул вакытта куян кызына әйткән:

— Аягың төзәлгәч, киез итекләрне инде салкын көннәрдә бер дә салма, сүзне тыңла, тагын начар хәлгә калма,— дигән.

"Доктор Айболит"ка алар бик зур рәхмәтләр әйткәннәр, саубуллашып өйләренә кайтып киткәннәр. Өч көн дигәндә, куян баласының аягы төзәлгән. Ул инде хәзер киез итеген бер дә салмый киеп йөри икән.

Сөйкемсез песи

Безгә аклы-сарылы песи баласы ияләште. Үзебезнең бер песиебез бар иде инде. Ул үзе ап-ак, маңгаенда кара тап бар. Без аны акыллы булганы өчен яратабыз. Ул үзе бик шаян булса да, ашамлыкка тими. Күршеләргә дә кереп йөрми. Песиебезне мактаганда мине дә мактыйлар. Аны Гөлкәй шулай өйрәткән инде диләр.

Ә күршедән кергән песи бик тәртипсез булып чыкты. Бертуктаусыз «мияу-мияу» ди. Ашарына бирсәң, төрле җиргә өстерәп алып китә дә идәнне буяп бетерә. Өстәлгә менеп икмәк сыныкларын тартып төшерә.

Беркөнне минем белән уйнарга иптәш кызым Мәйсәрә керде. Ул, безгә ияләшкән песи баласын күргәч, исе китеп:

— Абау, бу юньсез песине нигә керттегез! Ул инде бик күп кешегә йөрде. Бездә дә булды. Аны Рәисәләр дә, Әнисәләр дә куалап чыгардылар, ул акылсыз, сөйкемсез песи, — ди.

— Ә мин аны куалап чыгармыйм, тәртипкә өйрәтәм, — дидем.

Абыем Шамил дә:

— Сынап карыйк, өйрәнмәсә үзенә үпкәләр, — диде. Без, Шамил абыем белән икәүләп, песине өйрәтә башладык. Аңар ашарга да, йокларга да урыннар әзерләдек. Бер ай дигәндә, ул бөтенләй үзгәрде: матурланды, түгәрәкләнде, акыллыланды.

Хәзер Мәйсәрә безгә уйнарга кергәч, аны күреп исе китә, матурлыгына, тәртипле булуына кызыга.

— Сезнең үз песиегез бар бит, бусын миңа бир әле? — дип сорый ул миннән. Шамил дә, мин дә көләбез.

— Син аны куалап чыгарган идең бит, хәзер без аны берәүгә дә бирмибез, — дибез.

Песи, безнең сүзне аңлаган кебек, минем алдыма кереп утыра да, сырпаланып, койрыгын болгый.

Әминә Бикчәнтәева

Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар

Күз күреме җитмәслек, очына-кырыена чыгып бетмәслек бик зур бер болында күкрәп үләннәр үскәннәр. Чалгы белән чабарлык булып өлгергәннәр. Төрле төстәге матур чәчәкләр анда хуш исләр таратканнар. Кош-кортлар үзләренең матур сайраулары белән болынны яңгыратканнар.

Менә шундый матур болында ат көтүе йөргән. Дугадай муенлы, стакан тояклы аргамаклар болын үләнен ашаганнар. Туйганчы салкын чишмә суын эчкәннәр.

Бу атларның көтүчеләре булмаган. Бары тик үз араларыннан иң сылу, йөгерек, иң җитез Җирән Кашка гына көтүче хезмәтен үти икән. Ул, муенындагы кыңгыравын шалтыратып, башкаларны үз артыннан ияртә, барысын бергә туплап йөртә икән.

Җирән Кашка беркөнне бик арыган, кичен аның йокысы калган булган. Ул ятып бераз хәл җыйнарга, йоклап алырга уйлаган. Иптәшләренең барысын бергә җыйнаган да әйткән:

— Аерылсагыз, айга җитмәссез, бүленсәгез, бүген бетәрсез, бергә йөрсәгез, рәхәт көн итәрсез,- дигән.

Атлар башта гел бергә йөргәннәр. Кичкә таба берничәсе бик начар иткән, көтүдән аерылып киткән. Алар Җирән Кашканың сүзләрен онытканнар. Аның файдалы киңәшен тотмаганнар.

Аерылып киткәннәре килбәтсез зур бер Аюга очраганнар, куркуларыннан һушсыз була язганнар, бик тиз кайту юлына борылганнар. Ләкин Аю алар артыннан калмаган. Әй куган, әй куган, хәер, тота алмаган. Әй йөгергәннәр, әй йөгергәннәр атлар, юлларында тау очраган — йөгереп менгәннәр, урман очраган — ерып чыкканнар, чокырдан сикерергә уйлаганнар — булдыра алмаганнар. Тирән чокыр эченә егылганнар, аякларын сындырганнар.

Тагын өчесе көтүдән бүленеп киткән булган. Күп үтмәгән, алар да Җирән Кашканың туры сүзләрен исләренә төшергәннәр, үзләренең бүленеп китүләренә үкенгәннәр, ләкин инде соң булган. Каршыларына тешләрен шакырдатып, күзләрен акайтып бер Соры бүре килеп чыккан. Алар, бу явыз дошманны күргәч, каушап калганнар, үзләрен-үзләре белештерми, ярсып, кайсы кая таралганнар. Бүре шунда ук бер Атның бугазына ябышкан, буып алган, егып та салган. Калганнары качып котылганнар. Җирән Кашка муенындагы кыңгыравының матур шалтыравын ишеткәннәр һәм туп-туры шунда карап киткәннәр.

Барысы да Җирән Кашкага үз башларыннан үткән хәлләрне сөйләп биргәннәр, аның туры сүзен тотмауларына бик үкенгәннәр. Ә Җирән Кашка башын чайкаган, көчле итеп бер шалтыраткан — көтү бергә җыелган, тагын бер шалтыраткан да сөйләргә тотынган:

— Күрдегезме сүземнең дөреслеген: аерылганнар Аюдан өркеп һәлак булдылар, бүленгәннәр Бүрегә очрадылар, — дигән дә кыңгыравын өченче мәртәбә шалтыраткан һәм барлык аргамакларын болынга җыйган.

Бал корты һәм Шөпшә

Чәчәкләр башлыгы бик зур ярыш үткәрергә булган. Шул турыда ул төрле якка хәбәр салган:

— Кем дә кем бал салырга яхшы савыт әзерли, ул савытта бал бер дә бозылмый, әчеми, барлык чәчәктәге балны шуңа бирәм! — дигән.

Бөҗәкләр көнне-төнне белмәгәннәр. Бар да тырышып савыт эшләгәннәр, бар да үзләре эшләгән савытларны чәчәкләр башлыгына китергәннәр.

— Менә әйбәт савыт, балны кара салып! — дигәннәр. Чәчәкләр башлыгы аларның барысын да борып җибәргән.

— Ашыккансыз, ашыккансыз, бик начар ясагансыз. Мондый савытлар миңа кирәкми. Шуңа күрә бал да сезгә эләкми! — дигән.

Шөпшә һәм Бал корты иң соңгылар булып эшкә керешкәннәр. Беренчелекне алырга өмет иткәннәр.

Бал корты көне буе бертуктамый эшли дә эшли икән. Ерак-ерак җирләргә очып бара, аллы-гөлле чәчәкләрдән бал суырып ала. Аны алып кайтып, үзе әзерләгән матур күзәнәкләргә сала икән.

Шөпшә дә чәчәкләрдән бал җыйган. Ләкин ул бик-бик ялкау булган. Иртән әзрәк кенә эшли дә, кояш кыздыра башлау белән, оясына кереп йоклый икән.

...Ярыш көне килеп җиткән.

Бал корты балавыздан эшләгән матур күзәнәкле бал савытын күтәреп очып киткән. Шөпшә үзенең аннан-моннан эшләгән кәрәзен алып килгән.

Чәчәкләр башлыгы кәрәзләргә бал салып караган. Шөпшә кәрәзендә бал тормаган. Ә Бал кортының кәрәзе акмаган, әйбәт булган.

— Тырышканнар, күп көч куйганнар, менә дигән кәрәз эшләп чыгарганнар. Шуңа күрә теләсә нинди чәчәктән теләсә никадәр бал җыярга бал кортларына рөхсәт бирәм! — дигән Чәчәкләр башлыгы.

Шул көннән башлап бал кортлары чәчәкләрдән бал ташый башлаганнар. Ә шөпшәләр, ялкаулыклары аркасында, хурлыкка калганнар.

Кемгә кирәк, кемгә кирәкми

Әтисе белән бергәләп Тажи балык тотарга барды.

Көн әле бик иртә. Кояш та юк, ә шулай да якты. Су өсте тып-тын. Өф иткән җил дә юк.

Билгеле, мондый вакытта балыклар яхшы чиртәләр, кармакны бер дә тик тотмыйлар. Калкавычны томрып, су төбенә алып төшеп китәләр. Тажиның әтисе балыкларны тарта да чыгара, сөйри дә чыгара, ялтырап торган ап-ак чабакларны, көмеш тәңкәле кызылканатларны, әрсез алабугаларны. Тажи аларның барысын да чиләккә җыя бара. Менә инде аларның балык сала торган чиләкләре дә тулып килә. Балык бик шәп эләгә. Шуңа күрә вакытның үтүе дә тоелмый. Әнә инде кояш та күптән күтәрелеп килә. Тажи аны сизмәде дә. Төшлеккә җитә башлагач, кояш бик нык кыздырырга тотынды, монысын Тажи да тойды. Әтисе дә. Әтисе, кесәсендәге кулъяулыгын алып, маңгаендагы тирләрен сөртте. Ә Тажи:

— Фу... Нәрсәгә кирәк булды инде бу кояш?! — дип, зәңгәр күктән елмаючыны тиргәргә тотынды.

— Кемгә кирәк, кемгә кирәкми, — диде әтисе, шуннан тагын ялгады, — кояш бер дә булмаса, һаман төн генә булыр иде, ә төнлә балыклар эләкми.

Кояш булмаса, җир өстендә үсемлекләр үсмәс, син дә, мин дә булмас идек, — диде.

Кояш кыздыргач, балык та эләкми башлады. Тажи кояшны ачуланып торганда, кинәт җил күтәрелде. Көзге кебек тигез елга өсте шадраланды. Дулкын кузгалды, калкавычлар бер күтәрелделәр, бер төштеләр. Дулкын кузгалды, балык чиртүе дә беленми башлады. Тажи:

— Фу, нигә кирәк булды инде бу җил?! — диде.

— Кемгә кирәк, кемгә кирәкми! — диде әтисе.

Елга өстендә җилкәнен киергән көймә йөзде. Тау башындагы тегермәннәр, берсеннән-берсе узышып, әйләнә башладылар.

Әтисе Тажига:

— Әнә күрәсеңме, җилкән белән җилне ничек җиккәннәр. Җил көймәне этеп бара. Җил әнә тегермәннәрне дә әйләндерә. Ул тегермәндә орлыклар онга әйләнәләр. Ә ул оннан әниең күмәч пешерә, — диде.

Шул арада җил күк читеннән болытларны куып китерде дә, кара-кучкыллы болытлардан яңгыр төшкәли башлады.

— Фу, яңгыр нигә кирәк булды инде, елгада болай да су күп ич! — диде Тажи.

— Кемгә кирәк, кемгә кирәкми! — диде әтисе. Ашлык сукканда, печән җыйганда, безнең кебек балык тотканда яңгыр кирәкми. Ә менә бу болыннардагы үләннәр, урманнардагы агачлар, кырлардагы игеннәр үссен өчен яңгыр бик кирәк, — диде.

Яңгыр астында алар аталы-уллы икәүләп кармакларын чорнадылар.

Шулчак яшен яшьнәде, күк күкрәде. Коеп яңгыр яварга тотынды. Тажи әтисенең көчле сүзләре астында тәмам җиңелгән иде инде.

Ул:

— Яңгыр, яу, яу, чиләкләп-чиләкләп! — дип кычкыра-кычкыра, агач ышыгына йөгерде.

Бераздан әтисе дә килеп җитте. Ул:

— Табигатьтә барысы да кирәкле, улым, — диде, ачылып килә торган офык читенә күз төшереп. — Эх, яңгыр артыннан балык шәп эләгәчәк соң! — дип куйды.

Дуслар

Кич якынлашып килә иде. Алан әйләнәсендәге агачларның күләгәләре озыная барды. Менә алан өстендәге кояш, агачлар артына тәгәрәгәндәй

булып, күздән югалды. Күләгәләр барысы да бергә тоташып җәелделәр, урман эче караңгылана башлады.

Көне буе, кич җиткәнне көтеп, куак астында яткан ана куян урманда йөреп кайтмакчы булды. Киткән чакта, ул үзенең балалары Шалпан колак белән Кечкенәгә әйтте:

— Сез шунда гына уйнагыз. Ерак китмәгез! Чирәм үсеп куелана төшкәч, мин сезне үзем урман белән таныштырырга алып чыгармын. Аңарчы сез тиз йөгерергә дә өйрәнерсез.

Урынныннан кузгалып, бер-ике сикергәч, ул тагы артына әйләнеп:

— Шалпан колак, син Кечкенәне кыерсытма, — дип кычкырды. Аннан агач арасына кереп югалды.

Бу куян балалары яз көне икесе бер вакытта туган булсалар да, берсе никтер нәни иде. Шуңа күрә аңа әнисе Кечкенә дип исем кушты.

Әниләре киткәч, Шалпан колак белән Кечкенә ду килеп куышып йөрергә тотындылар. Түгәрәк алан әйләнәсендә йөгереп аргач, алар кайчандыр яшен сугып аударган имән агачы төбе янына барып ял иттеләр. Ауган агачның үзен инде күптән кешеләр ягарга алып киткән. Ә төбе алан уртасында кара утыргыч төсле булып торып калган иде.

— Әйдә, шул төп аша сикереп уйныйбыз! — диде Шалпан колак, бераз ял иткәннән соң.

— Әйдә-ә! - диде Кечкенә.

Алар сикереп уйнарга керештеләр. Йөгереп-йөгереп киләләр дә шул агач төбе аша — һоп!

Шуннан ерак түгел ямь-яшел яфраклы каен агачы үсеп утыра. Анда бер ана песнәк, оя ясап, йомырка салган да шул йомыркалардан нәни песнәкләр борынлап чыкканны көтеп утыра иде.

Песнәк, куян балаларының йөгереп, сикереп уйнаганнарын оясыннан күреп, сокланып утырды.

— Менә озакламый минем дә нәни кошчыкларым булыр. Канат чыккач, алар очарга өйрәнерләр,- дип уйлап куйды.

Шул вакыт Шалпан колак ерактан йөгереп килеп сикерим дигәндә генә, агач төбе өстендә кәкре коры чыбык, кинәт кузгалып, яртылаш үрә торды. Шалпан колак, куркып, колакларын торгызып кырыйга сикерде.

Башта әле ул бернәрсә дә аңлый алмый аптырап торган иде. Аның коры чыбык дип уйлаган әйбере, ысылдап, чирәмгә төшкәч, аңлады. Ул — чыбык түгел, агулы кара елан икән.

Ул арада кара елан, чирәм өстеннән шуышып, туп-туры әлеге песнәк оялаган каенга табан китте.

Өстән аны күреп торган бичара песнәкнең йөрәге ярылырга җитеште. Ул, акыллы кош, еланнарның гадәтен белә иде. Менә хәзер елан аның оясына үрмәләп менәр дә йомыркаларын ватып эчәр!

Песнәк бик борчылып чыелдап кычкырды:

— Коткарыгыз!

Шалпан колак белән Кечкенә эшнең нәрсәдә икәнен аңлап җиткермәделәр җиткерүен. Шулай да ысылдаган кара еланның берәүгә дә зарары тимәгән кошка явызлык эшләргә җыенуын сизенделәр.

— Ничек коткарырга соң ул кошчыкны? — диде Шалпан колак.

Кечкенә:

— Тукта! Әни кайтып килмиме икән? Мин барып карыйм әле. Ул кайтса, берәр нәрсә уйлап табар,- дип, әнисе киткән якка чапты.

— Ярый, син ул якка бар. Мин бу яктан карап килим! — дип, аланның икенче ягына йөгерде.

Кечкенә сикерә-сикерә йөгереп агачлар арасына барып керүгә, тәпиенә нәрсәдер кадалып, кычкырып җибәрде:

— Ой, ой, ой!

Караса, анда керпе йомарланып яткан икән.

— Нәрсә шулчаклы, күзеңә ак-кара күренми, мәтәлә-кадала чабасың? — диде керпе, Кечкенәгә ачуланып.

Йөгереп килеп сулышы беткән Кечкенә аңа:

— Елан! Елан! — дип кенә әйтә алды. Керпе:

— Фу-фу! Төлке куа икән, дип торам тагын! Кая ул елан, күрсәт, — дигәч, Кечкенә, шатланып, аны ияртеп китте.

Алар бик вакытлы барып өлгерделәр.

Керпе аланда каен агачына үрмәләп менәргә җыенган еланны күрүгә йөгерүен кызулатты һәм, вак-вак атлап, тиз генә барды да, елан өстенә ташланып, аның башының арт ягына тешләрен батырды. Арттарак калып бу хәлне карап торган Кечкенә, керпе өчен куркып, күзләрен йомды хәтта. Ул күзен ачканда, керпе еланны буып салган иде инде.

Ул арада Шалпан колак та, әнисен эзләп таба алмыйча, әлсерәп кайткан иде. Еланның кузгалмый сузылып яткынын күргәч, ул да иреннәрен кыймыл-кыймыл иттереп, шаккатып торды.

— Фу! Шулмы курыккан еланыгыз? Фу! — диде Керпе эре генә.

Оясында тынын алырга да куркып утырган песнәк, шатлыгыннан ни эшләргә белми, чутылдады:

— Рәхмәт сиңа, Керпе. Бу яхшылыгыңны гомердә онытмам. Бәлки, кайчан да булса, минем дә сиңа файдам тияр.

Керпе аңа бернинди дә җавап бирмәде.

— И, мескен кошчык! Син кемгә ярдәм итә аласың соң? — дип, авыз эченнән генә пырхылдап көлеп, үз юлына китте.

Озакламый песнәкнең нәни кошчыклары булды. Алар әле бернәрсә дә эшли белмиләр. Әниләре азык алып кайтканны көтеп, авызларын ачып, тик чыелдашып яталар иде.

Беркөнне песнәк, гадәтенчә азык эзләргә чыгарга җыенгач, аланда уйнап йөргән Шалпан колак белән Кечкенәгә әйтте:

— Куянкайлар! Мин юкта сез минем кошчыкларга күз-колак булсагыз иде. Алар бик тынгысызлар. Егылып төшеп имгәнмәгәйләре дип куркам. Сез аларга кычкыргалап торыгыз, оядан башларын чыгарып сузылмасыннар, — диде.

Шалпан колак белән Кечкенә:

— Ярый, ярый. Без шунда каен төбендә генә уйнарбыз. Кошчыкларың егылып төшә башласа, йомшак тәпиләребез белән тотып алырбыз. Җиргә төшеп имгәнергә ирек бирмәбез! — диделәр.

Песнәк тынычланып очып китте. Бераз очып азык алып кайтып килешли, ул бер төлкенең шыпырт кына куак артына яшеренгәнен күреп алды.

— Кемне сагалап посты икән бу явыз? — дип борчылып, як-якка каранса, текер-текер атлап килеп яткан таныш Керпене күрде.

Керпе сусаган булган, күрәсең, яңгырдан соң тирән чокырга җыелган суга таба бара иде. Төлке шуны сагалап поскан икән. Коры җирдә керпе, йомарланып ятып, төлкегә бирешмә-сә дә, су аның өчен куркыныч. Төлке аны суга тәгәрәтеп төшерә дә керпе җәелеп йөзә башлау белән аны буып ашый ала.

Песнәкнең шундый хәлне күргәне бар иде. Ул шунда ук түбән төшеп, акрын гына:

— Төлкедән саклан! Төлке сагалый! — дип чыелдап, Керпенең өстеннән очып үтте.

Керпе, кире борылып, бөтен көче белән йөгерергә тотынды. Төлке эшне аңлаганчы, ул әллә кая, чытырман арасына качып өлгергән иде инде. Бераз бөгәрләнеп ятканнан соң, ул чирәм арасыннан башын чыгарып карады һәм

Төлкенең бик кәефсезләнеп, борынын салындырып икенче якка ауга киткәнен күреп тынычланды.

— Фу! Менә сиңа кечкенә кошчык! Тукта, барып хәлләрен белим әле үзләренең, — дип, аланга таба тәпиләп китте.

Көннәр үтте. Песнәкнең балалары да үстеләр. Канат чыгарып очарга өйрәнделәр. Үз-үзләренә көн күрә башладылар. Шалпан колак белән Кечкенә дә зур куян булдылар. Тик аларның берсенең дә шул аланнан китәселәре килмәде. Керпе дә башка җирдә ямь тапмады, һаман кыштыр-кыштыр шул тирәдә йөрде.

Кышын песнәкләргә урманда туенып тору читен булачак иде. Шуңа күрә көз җитү белән алар, кая булса да, кешеләр тора торган җиргә китәргә җыендылар.

Керпе, Шалпан колак һәм Кечкенә шул алан тирәсендә кышларга булдылар. Алар песнәкләрне:

— Яз җиткәч, тагын шунда килегез! Без сезне көтәрбез! - дип озатып калдылар.

Сәрвәр Әдһәмова

Акыллым, без синең белән бик күп хайваннар, җәнлекләр, кош-кортлар турында язылган вакыйгаларны тыңлап киттек, алар турында шактый күп белдек. Шуңа күрә Мәхмүт абыегыз Хөсәен язган табышмак-җырга җавапларны җиңел табарсың дип уйлыйм. Син тыңларга һәм җаваплар эзләргә әзерме?

—... .

— Тыңлыйбыз, акыллым.

Безнең дусларыбыз

— Яле, безгә әйтеп карагыз,
Кем икәнен хәзер табабыз.
— Зур мыеклы үзе,
Аннан курка күсе!
— Акыллым, җавабын таптыңмы?
— ... .
— Әйе шул песи.
— Яле, тагын әйтеп карыгыз,
Кем икәнен хәзер табабыз.
— Койрык болгый үзе,

Ялт-йолт итә күзе.
— Ул нәрсә?
— ... .
— Бик дөрес эт.
Тагын, тагын әйтеп карагыз,
Кем икәнен хәзер табабыз.
— Башындагы бүрек
Кып-кызыл ут кебек.
— Ул нәрсә булыр икән?
— ... .
— Әйе, әтәч. Ә хәзер әлеге сүзләргә язылган җырны тыңлап карыйк.
Сүзләрен дә көен дә истә калдырыга тырыш, яме?
Безнең дусларыбыз
— Яле, безгә әйтеп карагыз,
Кем икәнен хәзер табабыз.
— Зур мыеклы үзе,
Аннан курка күсе!
— Ул бит песи, ул бит песи:
— Мияу! — ди,
— Курыкмагыз, мин һәрвакыт уяу! — ди.
— Яле, тагын әйтеп карыгыз,
Кем икәнен хәзер табабыз.
— Койрык болгый үзе,
Ялт-йолт итә күзе.
Ул бит маэмай, ул бит маэмай:
— Һау! Һау! — ди,
— Минем эшем — сезнең өйне саклау! — ди.
Тагын, тагын әйтеп карагыз,
Кем икәнен хәзер табабыз.
— Башындагы бүрек
Кып-кызыл ут кебек.
— Ул бит әтәч, ул бит әтәч:
— Кик-ри-күк!
Безне йокыдан уята бик иртүк,
Безнең әле дусларыбыз бик-бик күп!

М. Хөсәен

— Үскәнем, ә хәзер шигырьне куплетлап кабатлыйк һәм җырлап карыйк.

Кабатлыйбыз:

— Яле, безгә әйтеп карагыз,

Кем икәнен хәзер табабыз.

— Зур мыеклы үзе,

Аннан курка күсе!

— Ул бит песи, ул бит песи:

— Мияу! — ди,

— Курыкмагыз, мин һәрвакыт уяу! — ди.

Җырлыйбыз:

— Яле, безгә әйтеп карагыз,

Кем икәнен хәзер табабыз.

— Зур мыеклы үзе,

Аннан курка күсе!

— Ул бит песи, ул бит песи:

— Мияу! — ди,

— Курыкмагыз, мин һәрвакыт уяу! — ди.

Кабатлыйбыз:

— Яле, тагын әйтеп карыгыз,

Кем икәнен хәзер табабыз.

— Койрык болгый үзе,

Ялт-йолт итә күзе.

Ул бит маэмай, ул бит маэмай:

— Һау! Һау! — ди,

— Минем эшем — сезнең өйне саклау! — ди.

Җырлыйбыз:

— Яле, тагын әйтеп карыгыз,

Кем икәнен хәзер табабыз.

— Койрык болгый үзе,

Ялт-йолт итә күзе.

Ул бит маэмай, ул бит маэмай:

— Һау! Һау! — ди,

— Минем эшем — сезнең өйне саклау! — ди.

Кабатлыйбыз:

— Тагын, тагын әйтеп карагыз,

— Кем икәнен хәзер табабыз.
— Башындагы бүрек
— Кып-кызыл ут кебек.
— Ул бит әтәч, ул бит әтәч:
— Кик-ри-күк!
Безне йокыдан уята бик иртүк,
Безнең әле дусларыбыз бик-бик күп!
Җырлыйбыз:
Тагын, тагын әйтеп карагыз,
Кем икәнен хәзер табабыз.
— Башындагы бүрек
Кып-кызыл ут кебек.
— Ул бит әтәч, ул бит әтәч:
— Кик-ри-күк!
Безне йокыдан уята бик иртүк,
Безнең әле дусларыбыз бик-бик күп!

— Афәрин, акыллым, син инде хәзер бәйрәмнәрдә бу җырны җырлап та күрсәтә аласың, шулай бит.

— Бу тукталышта без табигатьне саклау турында күп сөйләштек. Алга таба татар шагыйрьләренең табигать турында искиткеч шигырьләрен укырбыз. Бик ошаганын өйдә әтиең яки әниең белән бергә өйрәнерсең.

Гөл янында

Чыккан иде Вил
Күңел ачарга,
Ал чәчәкле гөл
Күрде бакчада.
Әй, чәчәкләре
Матур бу гөлнең!..
Кулы берсенә
Сузылды Вилнең.
Яратканын ул
Алды да өзеп,
Тагын үрелде:
Булмый бит түзеп.
Ләкин әйтте гөл:
«Кадерлем, җитәр,

Алай күп өзсәң,
Бар ямем бетәр.
Иртәгә бире
Чыксаң тагын да,
Бер матур чәчәк
Бирермен шунда».
Гөлнең сүзенә
Вил карышмады,
Һәм шуңа гөл дә
Яратты аны.

Әнәс Кари

Урманда

Биредә кошлар, җәнлекләр
Читлеккә ябылмаган.
Урманы да койма белән
Уратып алынмаган.
Ул куяннар, ул пошилар,
Ул керпеләр, тилгәннәр
Казандагы зоопарктан,
Ахры, качып килгәннәр.
Алар безне күргәчтен,
Без урманга кергәчтен,
Тизрәк качып китәләр,
Тизрәк очып китәләр.
Юкса без ул җәнлекләргә,
Кошларга тиябезме?
Алар бит матурлый гына
Әйләнә-тирәбезне.
Без бит яратабыз гына
Аларны — белдегезме?!
«Курыкмагыз!» — дияр идем,
Белсәләр телебезне.
Белмиләр шул. Алар шулай
Гел качарга торалар.
Зоопаркка ябарлар, дип
Куркып качадыр алар.

Роберт Миңнуллин

Зоопаркта

Бервакытны әтием
Алып барды шәһәргә,
Зоопаркта күрдек без
Бүреләр, төлкеләр дә.
Читлектәге арслан
Йөрми җәнлек ауларга.
Китә алмый моннан ул
Туган иле — тауларга.
Лачын салган канатын, —
Сусаган ул иреккә,
Моңсу күзен төбәгән
Биеккә, зәңгәр күккә.
Маймылга конфет биреп,
Өйгә кайтып киттек тә...
Кызганып йөрим хәзер:
Яшәү читен читлектә.

Разил Вәлиев

— Акыллым, табигать турында сөйләшкәндә, ел фасылларын да искә төшеререгә кирәк. Син нинди ел фасылларын беләсең?

— Яз, җәй, көз, кыш.

— Афәрин! Кайсы ел вакыты сиңа күбрәк ошый?

— Мин җәйне яратам.

— Әйе, җәй көне табигать искиткеч матур. Ә җәйне син ни өчен яратасың?

— Җәй көне җылы. Күбәләкләр оча. Су коенырга була.

— Әйе, дөрес. Табигать елның нинди булуына карамастан гүзәл. Хәзер без ел фасыллыры турында хикәяләр, шигырьләр укырбыз. Син, өйгә кайткач, ел фасыллырын рәсемдә сурәтләрсең, килештекме?

— Әйе.

Яз килә

Көннәр аяз, күктә алсу
Нур сибеп, кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы -
Сагынып көткән яз килә.

Әйтегезче: кайсы вакыт
Яздагыдан ямьлерәк?
Кыш айларын да яратам,
Әмма яз күңеллерәк.
Көннәр җылы, күктә алсу
Нур сибеп, кояш көлә, —
Җәйге шатлык, көзге бәхет
Яз белән бергә килә.
Мөнир Мазунов

Дачада

Айнур белән Алсу шәһәр уртасында яши. Биек йортның сигезенче катында. Балконга чыгасың да, туйганчы, урам күзәтәсең. Анда тыз-быз машиналар чаба. Трамвайлар йөгерә. Абыйлар, апалар, әбиләр, бабайлар каядыр ашыга. Алар йортлар артына китеп югалалар. Айнур белән Алсуның да шунда барасы килә.

Ә быелгы яз аларга шатлык алып килде. Әтиләре шәһәр кырыенда дача алды.

Дачалары каенлык уртасында аланда икән. Өй зәңгәр, яшел, ак буяуларга буялган. Идәне сап-сары.

— Йә, ничек, ошыймы сезгә дача? — дип сорады әтиләре.

— Әй-йе. Без монда хәзер җәй буе торабызмы?

— Теләсәгез, җәй буе да мөмкин.

Әниләре аш-су әзерли башлады. Әбиләре яшелчәләргә су сибәргә чыгып китте. Әтиләре баскычка юнәлде. Ул ике кулы белән баш очындагы тоткаларны эткән иде, түшәм ишек кебек өскә ачылды да китте. Ур-ра! Монда берсендә — диван, икенчесендә карават торган бүлмәләр бар икән ич. Айнур мәтәлчек атып алды. Тиздән аш өлгерде, чәй кайнады. Яңа дачада беренче мәртәбә табын янына җыелдылар. Шатлыкны кайбер күршеләр дә уртаклашты. Алар Айнур белән Алсуга үзләре үстергән чәчәкләр бүләк иттеләр.

Әй кызык икән дачада!

Тәүфикъ Әйди

Көз

Күрәмсез, дусларым, көз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.

Китә башлады бездән инде кошлар;
Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.

Габдулла Тукай

Бу кайчак була?

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява;
Җирләр дымлана, —
Бу кайчак була?

Габдулла Тукай

Көз

Үтте-китте матур җәйләр,
Көзләр килеп җиттеләр.
Ак каенның яфраклары
Саргаешып киптеләр.

Кави Нәҗми

Яфрак бәйрәме

Яңгыр түгел, кар да түгел,
Яфраклар ява җиргә.
Көз турында җырлыймын мин —
Кушыл син яңа җырга.
Сары, сары, сап-сары
Агачның яфраклары.
Җил исә, ява яфрак —
Көзнең матур чаклары.
Оча яфрак, уйный яфрак,
Һаваларда әйләнеп.
Бүген, бүген, бүген, бүген
Яфракларның бәйрәме!

Ләбиб Лерон

Көзге яңгыр

— Апа, безгә артыбыздан
Шыбыр-шыбыр кем дәшә?
— Кем дә дәшми, көзге яңгыр
Зонтик белән сөйләшә.

Мәрзия Фәйзуллина

Көз

Көз килде. Үләннәр
Саргайды, шиңде.
Сап-сары яфраклар
Җиргә сибелде.

Әхмәт Ерикәй

Кошлар киткәндә

— Сыерчыгым, нигә китәсең?
Сагынырмын сине, киткәчтен.
— Көз җитте бит инде, мин туңам,
Килгән идем җәйге костюмнан.

Бари Рәхмәт

Салкын саф һава,
Йомшак кар ява.
Урамга чыксаң,
Битләр кызара.
Кар бөртекләре
Өстеңә куна,
Үзләре матур
Һәм салкын була.

Әминә Бикчәнтәева

Кышкы иртә

Кышкы иртә. Авыл. Тынлык.
Җил әле уянмаган.
Иртә шул: бала-чага да
Чыкмаган урамнарга.
Кошлар күптән хәрәкәттә —
Очып йөриләр иде.
Агайлар да, сукмак ясап,
Карлар көриләр инде.
Тиздән, тиздән җил уяныр —
Сукмакларны себерер.
Балаларның шат авазы
Урамнарга сибелер.

Кыш — буяучы

Бөтерчектәй бөтерелә,
Әй тирбәлә ак карлар...
Кыш — буяучы, табигатьне
Буяп чыккан, акшарлап!
Куе зәңгәр томан булып,
Урманга эңгер төшә.
«Җиһан тыныч йокласын», — дип,
Җил йөри, мендәр түшәп...
Чиксезлектә, җем-җем балкып,
Йолдызлар нидер көтә.
Шунда очып китәр сыман
Чыршы — яшел ракета!
Ылыс-канатларда — бәсләр,
Яна, әнә, елкылдап...
Вакыт безгә алып килә
Яңа ел — яңа китап!

Кыш бабай җыры

Бигрәкләр дә матур дөнья! —
Җиргә аклык бөркелә...
Гүзәллекккә таңнар калып,
Бер елмаям, бер көләм.
Кешеләрнең, бик сагынып,
Мине көткәнен беләм.
Шуңа күрә сөенечләр,
Шатлыклар алып киләм.
Өләшермен мин аларны,
Тынычлык, бәхет теләп.
Яңа яуган кардай ап-ак
Биштәрем үзем белән...

Кар бабайлар

Нәсим дә кар тәгәрәтә,
Вәсим дә кар тәгәрәтә...
Нәни генә булса да, күр,
Рәсим дә кар тәгәрәтә!

Тәгәрәтәм мин дә карны —
Тәгәрәтәм ап-ак шарны...
Кар шар миңа өчәү кирәк —
Тәгәрәтәм тагын карны!..
Эшебезгә карап тордык —
Иллә дә шәп булды, малай:
Кар бабайлар белән безнең
Бөтен урам тулды, малай!

Күңелле!

Буранлап-буранлап,
Кар яуды:
Урамнар, сукмаклар
Тарайды.
Чыктылар балалар
Урамга.
Урамны киңәйтеп
Уйнарга!
Уйныйлар, көләләр
Үзләре.
Суыктан алланган
Йөзләре.
Кыш көне, әйе шул,
Күңелле!
Сиңа да бу шулай
Түгелме?

Кызык кыш

Кыш беткәндә... кыш килде —
Быел кыш кызык итте...
Кар яудыра-яудыра,
Кыш тәмам кызып китте!
Башта билдән булган көрт
Мине дә узып китте;
Койманы һәм мунчаны...
Өйне дә узып китте!
...Ярый әле кышның, дим,

Үзен яз кызык итте:
Кояш булып чыкты да
Бөтен карны эретте.
Радиога салкын тигән
Энемнең тавышы беткән
Көч-хәл белән сөйләшә.
Салкын тигән. Шуңа күрә
Мәтрүшкәле чәй эчә.
... Беркөн безнең радиога
Нидер булды — сөйләми.
Чыжылдый шунда... Йөткерә –
Берничек тә көйләнми.
Нишләтергә инде моны
Әйбәт сөйләсен өчен?
Энем әйтә:
«Салкын тигән.
Мәтрүшкәле чәй эчсен!»

Ләбиб Лерон

Бүләк кемгә?

(Татар халык әкияте)

Бервакыт Кояш елның дүрт фасылын — Көзне, Кышны, Язны һәм Җәйне үзенә чакырып алган.

— Сезнең кайсыгыз матуррак, кайсыгыз эштә батыррак? Шуңа бүләк бирәм,-дигән.

Ә бүләк бик затлы икән -уч тутырып йолдыз бирергә уйлаган Кояш.

Сүзне башлый Көз:

— Үзегез яхшы беләсез, мин бөтен басуларның уңышын җыйдым, бар дөньяны алтынга күмдем. Кошларны җылы якка озаттым, балаларны мәктәпкә җыйдым. Бүләк миңа тиеш!

— Әллә мин эшләдемме аз? — дип сикереп тора Яз. — Мин барлык карларны эреттем, басуларга иген чәчтем, кошларны чакырып кайтардым, агачларны яфрак ярдырдым, болыннарны чәчәккә күмдем. Арада иң матуры да, иң булдыклысы да мин! -дигән ул.

— Ай-яй, — дигән Җәй, — мине тыңлагыз әле, мин дөньяны яшеллеккә күмәм, чәчәкләр үстерәм, игеннәрне өлгертәм, җимешләрне пешерәм. Әллә мин иң матурыгыз түгелме?

— Артык күп түгел минем эш,-ди тыйнак кына Кыш.-Мин җирне ял иттерәм, киләсе уңыш өчен карлар ташыйм, дөньяны ап-акка буйыйм, балаларны чана, чаңгы шуарга чакырам. Мин дә ямьсез түгел. Минем чыршыларымны, кар бөртекләремне, мамык бәсләремне яраталар.

Тыңлап-тыңлап торган да Кояш, бүләкне бу дүртәүнең берсенә дә бирә алмаган. Йолдызларны ул күккә сипкән. «Әнә барыгызга да!» — дигән.

Йолдызларны елның бер фасылы да үзенә ала алмаган. Алар һәрвакыт — яз да, җәй дә, көз дә, кыш та балкып яналар.

— Дустым, без тагын бер тукталышка килеп җиттек. Ул — йорт хайваннары һәм йорт кошлары тукталышы. Шулай ук, бик кызыклы һәм бик күңелле тукталыш булачак. Син әзерме? Алайса, алга!

ЙОРТ ХАЙВАННАРЫ, КОШ-КОРТЛАРЫ

— Нәни дустым, сиңа табышмакларның җавабын табу бик ошый, шулай бит?! Шуңа күрә тукталыш балән танышуны табышмаклардан башлап китик әле, син каршы түгелдер бит?

— ...

— Юкмы? Бик яхшы. Әйдә әле игътибар белән тыңлыйк һәм җаваплар эзлик.

Бака ашый, балык ашый,
Ашаса, ашый күпләп.
Су буеннан кайтып керми,
Нәрсә ул? Әлбәттә,...
— Үрдәк.

Гөлнур Корбанова

Күлгә таба йөгерә,
Җиргә басып лап та лоп.
Күпләп су эчә, ашый,
“Бак-бак” диеп мактанып.
— Бусы...
— Үрдәк.
— Афәрин.

Ленар Шәех

Башында кызыл тарак,
Ә койрыгы нәкъ урак.
Таңнан уята җырлап,
Исеме аның ...
— Нәрсә икән?
— ... .
— Әтәч, билгеле.

Марзия Фәйзуллина

Күзләре — кара,
Күзләре — төймә.
Яши ул кырда,
Яши ул өйдә.
Мәчеләр — аңа

Һәрвакыт дошман,
Ярыкка әллә
Койрыгын кыскан,
Идән астында:
“Чи-чи”, — ди ... Ул нәрсә икән?
... .
Бик дөрес — тычкан

Гөлнур Корбанова

Үләнашый, майташый.
(Сыер)
Кешенең дусты, йортның сакчысы.
(Эт)
Мыеклы да койрыклы,
Мендәр өстендә йоклый.
(Песи)
Йомры, йомшак соры йомгак
Йөгереп йөри чирәмдә.
(Чеби)
Су төбенә төшә,
Чыланмыйча чыга.
(Үрдәк)
Канаты бар — оча алмый,
Аягы бар — йөзә алмый.
(Тавык)

Сакаллы килеш туа, берәү дә гаҗәпләнми.
(Кәҗә)

Кабара, кабара, кабара күк,
Кабарып пешкән икмәк күк;
Шыгай улы кунак күк,
Киенеп чыккан кияү күк.
(Күркә)

Тимерче дә түгел,
Балта остасы да түгел,

Үзе авылда беренче эшче.
(Ат)

Безнең өч дусыбыз бар:
Берсе ашата,
Икенчесе эчертә,
Өченчесе йорт саклый.
(Ат, сыер, эт)

Койрыгыннан мөгезе озын.
(Кәҗә)

Бәләкәй генә буйлы,
Әйләндереп кигән тунлы.
(Сарык)

Кечкенә генә татар,
Язын тунын сатар.
(Сарык)

Ак песи

Идел-елга буенда, ямьле яр тугаенда зәңгәр тәрәзәле, зәңгәр болдырлы, зәңгәр капкалы бик матур бер йорт утырган. Шушы йортта бик тә матур, кеп-кечкенә ике песи баласы торган. Аларның берсе ап-ак мамыктай күперенке тунлы, үзе күк күзле, үзе бик тә үзсүзле булган. Икенчесе аклы-сорылы, күзе дә соры, әмма үзе бик тә акыллы, тыйнак һәм тыңлаучан икән.

Шушы ике песи баласыннан кала, бу матур йортта тагын апак чәчле, йомшак сүзле, ягымлы йөзле Әби дә яшәгән. Янында бик җитез, бик шаян бер оныгы да бар икән.

Бу Кызчык үзе дә тузгып торган сап-сары чәченә күбәләк кебек итеп зәңгәр тасма тагып йөри, Ак песинең муенына да зәңгәр тасма бәйләп куя икән. Барыннан да бигрәк, Кызчык Ак песине ярата, аны кочаклап кына йоклата, үзе ашаганны гына ашата, кәгазь күбәләкләр ясап уйната икән. Аның каравы, Әби үзе Соры песине артыграк күрә, аны һаман «акыллым» — дип кенә йөртә икән.

Шуңа да бу ике песи, тормышларыннан бик канәгать булып, тыныч кына, рәхәт кенә яшәп яталар, тәмле-татлы ризыклар ашыйлар, йомшак урыннарда гына йоклыйлар, матур яшел бакчада йөреп-уйнап кайталар икән.

Бервакытны бу песиләр икесе бергә зәңгәр болдырның зәңгәр баскычында зәңгәр чынаяктан сөт эчеп торганда, баскыч төбендә кечкенә генә кап-кара бер Көчекне күреп алганнар. Бу Көчек, бик тә нәүмизләнеп, боегып кына, песи балаларының сөтләренә карап тора, ә үзе, сөт эчәсе килүен белгертергә теләгәндәй, еш-еш койрыгын болгый икән.

Ак песи баласы, Көчекне күрүгә, ап-ак сыртын кабартып җибәргән, тешләрен ыржайткан да, күк күзләрендә зәңгәр очкыннар уйнатып:

— Кит моннан! — дип ысылдаган. Соры песи, аптырап, Ак песигә караган.

— Бу нишләвең, Аппагым?! Күрмисеңмени, безнең кунагыбызның да сөт эчәсе килгән бит! — дигән ул, иреннәрен ялап торган кара Көчеккә күрсәтеп.

— Килсә соң! Минем анда ни эшем бар? Безнең зәңгәр баскычтан хәзер үк китсен! Югыйсә менә шушы тырнакларым белән күзләрен тырнап бетерәм мин аның! — дигән Ак песи һәм, кечкенә генә йомшак тәпиен күтәреп, үзенең бик тә очлы, бик тә үткен тырнакларын күрсәткән.

— Алай ярамый, сеңлем! Бәлки, аның сыеныр урыны юктыр, хәлен белергә, ярдәм итәргә кирәк үзенә! — дигән Соры песи.

— Сыеныр урыны, имеш! Шул гына җитмәгән иде, Сыеныр урынсыз Көчек була димени? Минем андыйларны күргәнем дә юк, күрәсем дә килми, — дигән Ак песи бик эре генә.

Соры песи туганының бу сүзләре өчен бик оялган һәм зәңгәр баскычтан сикереп төшкән дә кара Көчекне, әйдәп, үзе белән сөтле чынаяк янына алып килгән.

— Курыкма син аннан, курыкма, эч сөтне, эч! Үсмәгән әле ул, дуслыкның да, ачлыкның да нәрсә икәнен белми, — дигән Соры песи һәм, тынычландырырга тырышып, кара Көчекнең борын очын ялап алган. Шуннан кара Көчек, курка-курка гына булса да, сөтне эчә башлаган.

Резеда Вәлиева

— Үскәнем, синең иң яраткан йорт хайваның нинди?

— Эт, песи...

— Алга таба этләр турында бик матур шигырьләр укырбыз.

Маэмай

Минем бар бер маэмаем,
Кара борын Акбаем.
Күп йөгерә, күп өрә,
Күп ишетә, күп күрә…

Муса Җәлил

Маэмай

Тешләмәсен Акбаем,
Сезгә өрә маэмаем:
“Ташлар ыргытмагыз, — ди, —
Мине котыртмагыз”,, — ди.

Ж.Тәрҗеманов

Көчек

Шаярырга бик ярата
Безнең нәни көчек.
Һич туктамый сикерә ул,
Алга-артка төшеп.

Юри генә тешли кулны,
Ялый борын очын.
Күнегүләр ясый шулай,
Тизрәк үсәр өчен.

Г.Әхтәмова

Көчегем

Бар минем бер көчегем,
Көчегем – бөтерчегем.
Әйткән сүземне аңлый,
Дусларымны да таный.

Кая гына барсам да,
Артымнан бер дә калмый.
Шундый өлгер көчегем,
Көчегем – бөтерчегем.

Л.Әмирханова

Кызыклы шәкерт

— Әйдәле, Акбай, өйрән син,
арт аягың белән тор;
Аума, аума, туп-туры тор,
төз утыр, яхшы утыр!

— Ник газаплыйсың болай син,
мин әле бик кечкенә;
Мин туганга ике айлап булыр, я өч кенә.

Юк, кирәкми, мин өйрәнмим,
минем уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым,
шунда ауныйсым килә.

— Ах, юләр маэмай! Тырыш яшьләй,
зурайгач җайсыз ул,
Картаеп каткач буыннар,
эш белү уңайсыз ул!

Габдулла Тукай

Акбай

Арт аягына баскан,
Биш-алты медаль аскан.
Сикереп бии Акбай.
Акбай — акыллы маэмай.

Койрыгын селкетә —
Ул тәмле азык көтә.
Конфет ашамый Акбай.
Акбай — акыллы маэмай.

Биеде дә тирәмдә
Барып ятты чирәмгә.
Тузанга ятмый Акбай.
Акбай — акыллы маэмай.

Ренат Харис

Акбайга

Йөрмә, Акбай, безнең янда,
Я тешләрсең, кит әле.
Песиебезгә дә өрмә –
Ул бәләкәй бит әле.

Юлбарыска охшаган ул
Безнең песи баласы.
Чынлап юлбарыс булган, ди,
Аның ерак бабасы.

Ул да, үскәчтен, юлбарыс
Булыр әле — күрерсең.
Алай бик батыр икәнсең –
Менә шунда өрерсең!
Роберт Миңнуллин

Рәхәт безнең Акбайга

Рәхәт безнең Акбайга,
Менә ул бәхет кайда!
Күлмәген юасы юк,
Чалбарын юасы юк,

Үтүкләп куясы юк.
Пычракка керсә дә,
Баткак ерып йөрсә дә —
Ачуланмый берсе дә.
— Чык хәзер үк! — димиләр,
Кагылмыйлар-тимиләр.
Бәйләнми һичберкем дә,
Яши ул үз иркендә.
Рәхәт безнең Акбайга,
Менә ул бәхет кайда!

Резеда Вәлиева

Ялкау маэмай

Безнең маэмай рәхәт тора, сафа сөрә,
Җитезләнә, уйный һаман йөгрә-өрә;
Карый миңа мәхәббәтле күзе белән,
Гүя «уйныйк» дигән була, гүя көлә.
Кайвакыт ул ята тәмле ашап туеп,
Ал аяклары өстенә башын куеп.
Аны шунда чебен халкы тынычсызлый;
Ялкау маэмай! Ул аларны тормый куып.
Чебеннәрне астан гына карап ята,
Ярты йомык күзен генә ялтырата;
Бервакыт ул колак артын торып кашый,
Чебен халкы шунда тиз-тиз кача башлый.

Габдулла Тукай

Кәҗә

Кәҗә безгә йон бирә,
Кәҗә безгә сөт бирә.
Тик шунысын яратмыйм:
Җәен бакчага керә.

Мөнир Мазунов

— Акыллым, йорт хайваннары турында сөйләшүне дәвам итик.

Бәтиләр

Үсә безнең фермада
Бик күп нәни бәтиләр.
— Бә! — диләр. — Бә! — диләр,
Башка бер сүз әйтмиләр.
— Ничек исемнәрегез? —
Дип сорагач, бәтиләр:
— Бә! — диләр. — Бә! — диләр,
Башка бер сүз әйтмиләр.
—Сезгә ничә яшь? — дигәч
Аңламыйлар бәтиләр:
— Бә! — диләр. — Бә! — диләр,
Башка бер сүз әйтмиләр.

— Шәл бәйләргә йон безгә
Бирегезче, бәтиләр!
— Мә! — диләр. — Мә! — диләр,
Бөдрә тунлы бәтиләр.

Әминә Бикчәнтәева

Безнең сыер

— Әби, әби, әйт әле,
Сыер нигә мөгери?
— Карыны ачкан, улым,
Печән китер, йөгер, — ди.
— Ашап туйгач, ник сыер,
Сузып-сузып, “му-у” ди ул?
— Эчәсе килгән, улым,
Китер миңа су-у! – ди ул.

Нәкыйп Каштанов

Мияу!

Песи, песи, пескәем,
Соры синең төскәең.
Йомшак синең йоннарың,
Җылы синең туннарың.

Роберт Миңнуллин

Бәти

Бар белгәне “Бә”.
— Б-ә дә б-ә, — ди ул.
— Бу ни, — дисәгез, —
Безнең бәти ул.

Рафис Корбан

Маэмай

Минем бар бер маэмаем,
Кара борын Акбаем.
Күп йөгерә, күп өрә,
Күп ишетә, күп күрә...

Муса Җәлил

Мыраубикә

Мыраубикә кызык та соң,
Мыр-мыр-мыр итә-итә,
Әбиемнең итәгендә
Гыр-гыр-гыр йоклап китә.

Дамир Гарифуллин

Безнең сыер

Безнең сыер өебезне яхшы белә,
Көтүдән ул мөгри-мөгри кайтып керә,
Әйтерсең лә: “Мине каршы алыгыз! – ди,
Мул итеп сөт алып кайттым, савыгыз!” – ди.

Әнәс Кари

Чебиләр

Акыллы кыз Гөлфия
Чебиләрне бик сөя:
Әнисе эштә чагында
Ул аларга җим сибә.
Их чебиләр, чебиләр!
Һич тынычлык бирмиләр:
Гөлфиянең кул астында
Черелдәшеп йөриләр.

Әнәс Кари

— Шагыйрь абый-апаларыгыз да безнең тирәдә яшәгән кош — кортларны, хайваннарны яраталар, үз итәләр икән. Шулай булмаса, матур-матур шигырьләр язмаслар иде. Әйдә, акыллым, шул шигырьләрне без дә тыңлап китик, әле.

Тавык

Кытаклап чыкты тавык,
Кытаклый ул мактанып.
Нәрсәгә бик шатланган?
Чөнки ул күкәй салган.
“Әби күреп алсын, — ди, —
Балалар куансын”, — ди.

Әнәс Кари

— Үскәнем, исеңә төшер әле, нинди әкияттә тавык алтын йомырка сала?

— ... . (курочка ряба)

— Әйе, бик дөрес, акыллым, “Курочка Ряба” әкиятендә. Ә татарча бу әкиятне “Чуар тавык” әкияте дип атыйлар. Тавыклар безне тәмле йомырка белән сыйлыйлар, ә менә йокыдан иртүк безне нәрсә уята, беләсеңме, үскәнем?

— ... .

— Шулай, кадерлем, әтәчләр иртүк торалар һәм безгә дә иртә торырга кушалар. Бари абыегыз Рәхмәт үзенең шигырыендә иртүк тора торган әтәч турында язган. Әйдә әле тыңлап китик.

Бала белән Әтәч

— Әтәчем! Әтәчем!
Ник иртә ятасың?
Йокыдан син безне
Иртүк уятасың.

— Мин ятмыйм — кунаклыйм,
Йокыга бик сак мин.
Хәйләкәр төлкедән
Тавыкларны саклыйм.

— Торасың да иртүк
Кычкырасың бик күп,
Кикри-күк, кикри-күк,
Кикри-күк, кикри-күк!
— Мин сиңа кычкырмыйм,
Әнием торсын дим.
Кабартма пешерсен,
Самовар куйсын дим.
Бари Рәхмәт

— Ә менә Хәкимҗан абыегыз Халиков бөтенләй башка холыклы әтәч турында язган, үскәнем игътибар белән тыңлыйк әле.

Тәкәббер әтәч

Бу әтәчме?! Авылда
Иң матур әтәч булган,
Ә башында, таҗ сыман,
Кып-кызыл кәпәч булган.

Койрыклары тиң булган
Салават күперенә...
“Сугышма”, — дип, хуҗасы
Әйтмәгән күпме генә?!

Тыңламаган. Ә хәзер
Калган бер күзе генә.
Башындагы таҗның да
Калган тик эзе генә.

Колак каккан хәтта ул
Үзенең бар йоныннан.
“Ник сугыштым икән?” — дип,
И үкенгән соңыннан.
Әмма инде соң булган.

Хәкимҗан Халиков

— Я, акыллым, бу әтәч турында нәрсә әйтерсең икән?

— ... . (Сугыш чукмары әтәч)

— Менә шундый сугыш чукмары әтәч тә була икән. Ә сезнең арада бу әтәчкә ошаган малайлар очрамыймы, акыллым.

— ... . (юк)

— Юкмы? Мин бик шат. Чынлап та аңлашу, аралашу өчен тәмле телебез булганда нигә әле сугышып аңлашырга, шулай бит үскәнем.

— Акыллым, ә менә Дамир абыегыз Гарифуллин шигырь—табышмак язган. Яле, үзеңне сынап кара, җавапларың дөрес булырмы икән?

Дамир Гарифуллин

Нурбәк әкияте

Ике яшьлек Нурбәк әтисенә әйтә:

— Әти! Бака күрәсем килә, ди. Бака кайда тора ул?

Әтисе Нурбәккә әйтә:

— Бака су буенда була ул,— ди.

— Су буена барыйк, — ди Нурбәк.

Әтисе белән Нурбәк су буена төшеп барганда, аларга тыкрык башында бер оя Каз очрады.

— Ка-как-ка-ка-ка-как, — ди Казлар.

— Әти, Казлар ни әйтә ул? — ди Нурбәк.

— «Нурбәк, кая барасың?» — дип сорыйлар Казлар, — ди әтисе. — Бака карарга барам,— ди Нурбәк.

— Ка-ка-ка-как, Бакага бездән сәлам әйт! — диләр Казлар.

Тыкрык уртасына җиткәч, Нурбәк белән әтисенә Бозау очрады.

— Му-у-у! — ди Бозау.

— Әти, Бозау ни әйтә ул? — ди Нурбәк.

— «Ну-ур-бә-әк, кая барасы-ың?» — дип сорый Бозау.

— Су буена, Бака карарга-а! — ди Нурбәк.

— Бакага миннән сәлам ә-әйт! — ди Бозау. Нурбәк белән әтисе су буена төшеп җитте. Су буенда, сөзәк ярда бик матур, ямь-яшел бер Бака утыра. Үзенчә сайрап утыра.

— Курыйк-курыйк, бака-ка, курыйк-курыйк, бака-ка!

— Әти, Бака нәрсә әйтә ул? — ди Нурбәк.

— «Исән-саумы, Нурбәк!» — дип сорый Бака,— ди әтисе.

— Исәнме, Бака! — ди Нурбәк.— Бака-бака, Бакакай, Казлар сиңа сәлам әйтте.

— Бик рәхмәт, Нурбәк, — ди Бака.— Үзең дә Казларга миннән сәлам әйт.

— Бозау да сиңа сәлам әйтте, — ди Нурбәк.

— Бик рәхмәт, бик рәхмәт, — ди Бака.

— Миннән дә Бозауга сәлам әйт. Нурбәк белән әтисе Бака белән саубуллашып кайтып китә. Кайта торгач, алар Бозау янына җитә.

— Бозау, яшел Бака сиңа сәлам әйтте! — ди Нурбәк.

— Рәхмә-әт, — ди Бозау. Казлар янына җиткәч, Нурбәк:

— Казлар, яшел Бака сезгә сәлам әйтте, — ди.

— Ка-как-ка-как, рәхмәт, — диләр Казлар.

Рабит Батулла

Сертотмас үрдәк

Борын заманда башы бүрекле, аягы төкле бер үрдәк булган. Ул үзе, сайрый белмәсә дә, күргән бер кошына, хайванына, ерткычына озак-озак итеп яңа хәбәрләр сөйләргә ярата икән. Тегеләр аның сүзләрен тыңлый-тыңлый арып бетәләр, я бөтенләй тыңламый ташлап китәләр икән. «Ишеттеңме бер яңа хәбәр? Сиңа гына сер итеп сөйлим», — дип башлап китә торган булган ул сүзен.

Бердәнбер көнне йорт хуҗасы үзенең этен иярткән, корыч балтасын биленә кыстырган да урманга киткән. Йортындагы һәрбер кош-кортына: «Өйдә юклыгымны берәүгә дә белдермәс булыгыз!» — дигән.

«Нигә белдермәскә кушты икән?» — дип, үрдәк йөдәп чыккан, ләкин ни өчен икәнен һич төшенә алмаган.

Кош-кортлар хуҗаларыннан башка бер кич кунганнар, берни булмаган. «Икенче көнне дә кайтмас бу», — дип, алар хуҗаны чакырып кайтырга берәрсен җибәрергә булганнар. «Син очасың да, син йөзәсең дә, син йөгерәсең дә, син бар!» — дигәннәр алар үрдәккә. «Ләкин берүк нишләп йөрүеңне берәүгә дә белгертәсе булма!» — дигәннәр. Үрдәк күнгән: «Ярар, сезнең хакыгыз өчен генә барсам барырмын инде», — дигән.

Иртә торгач та үрдәк, уйлап-нитеп тормаган, тамагын туйдырган да, юлга чыккан. Башта ул канатларын кагып очкан, оча-оча бер елгага барып төшкән. Ишкәкләре — тәпиләр — үзендә булганга аптырамаган, йөзеп тә киткән. Елга буйлап озак йөзгәч, корыга чыгып, тәпи-тәпи дә йөгергән…

Бара-бара куе бер урманга барып җиткән. Төрле тәмле җиләкләр, симез бөҗәкләр ашый-ашый, урманга кереп тә киткән.

Үрдәк күбәләк куып йөргәндә, аның каршысына бер керпе килеп чыккан һәм аңа сүз дә кушкан: — Кая барасың болай? — дигән.

Үрдәккә инде шул гына кирәк тә. Юл буе берәү дә очрамаганга, берәү белән дә җәелеп сөйләшергә туры килмәгәнгә, аның бик эче пошкан булган, иптәшләренең әйткәннәрен дә оныткан, сүз артыннан сүзне тезәргә тотынган: — Урманда утын кисүче хуҗабызны эзлим. Җитмәсә, этебез дә аңа ияреп киткән иде. Хәзер йорт-җирне саклаучы берәү дә юк. Аларны чакырып кайтырга иптәшләрем мине җибәрделәр, — дигән.

— Синең өең ераКмы соң? — дигән керпе.

— Анда симез тычканнар, усал еланнар юкмы? — дип сораган. Аның үз хәле хәл, бик ныК ашыйсы килә икән. — Менә шушы сукмак безнең өйгә туптуры алып бара, бер кешегә дә әйтмә, кара! — дигән үрдәк. Өйләрендә еланнарның бөтенләй юклыгын, тычканнарга көн бирмәүче мәченең

шуклыгын да сөйләп биргән. — Мин инде андый усалларның берсе дә түгел, синең серләреңне белсәм дә, каян килүеңне күрсәм дә, сиңа зарарлы эш эшләмәм. Шулай да син саграк бул. Очраган берәүгә серләреңне сөйләмә. Серең эчендә торса, йортың тыныч булыр, җимерелмәслек нык булыр, — дигән. Керпенең бу акыллы киңәшенә үрдәк һич колак салмаган, ашыга-ашыга урман эченәрәк атлаган.Бара-бара үрдәккә озын колаклы бер куян очраган, һәм ул да аңардан сораган:

— Әй, бүрекле үрдәк, көзге төсле матур, кыр төсле зур күл булганда, ни эшләп урманда буталып йөрисең?

— Хуҗабыз белән этебез урманга утын кисәргә киткәннәр иде, өебез ялгыз калды, — дигән үрдәк, керпегә сөйләгәнне моңа да сөйләп биргән. — Куян эченнән генә: «Алай булгач, хуҗаның алмагачларын кимерергә барырга бик җайлы вакыт икән», — дигән. Үрдәктән өйләренең кайдалыгын сорашкан, теге юләр моңа да серен ачкан.

— Хуҗаңны күргәнем юк, — дигән дә куян, куаклык эченә кереп югалган.

Үрдәк тагын алга киткән. Бара-бара бер аланлыкка барып җиткән. Анда бер зур соры аю мышный-мышный йоклап ята икән. Үрдәк аны да уяткан.

Керпе белән куянга сөйләгән сүзне аңа да сөйләп биргән. Сүз ахырында аюдан сораган:

— Эт иярткән, кулына балта тоткан кешене күрмәдеңме? Аю:

— Күрмәдем, — дип җавап биргән. Үрдәкнең кайгысын уртаклашкандай булып кыланган. — Урман эченәрәк керсәң, һичшиксез табарсың, — дип, юл өйрәтеп җибәргән. Ә үзе эченнән генә: «Хуҗаның умартасын ватып, бал ашап кайтырга бик җайлы вакыт икән», — дип, ашыга-ашыга китеп тә барган.

Үрдәк һаман хуҗаны эзләвен дәвам иттергән. Аның саен урманның эченәрәк керә барган. Бара торгач, аның каршына бүре килеп чыккан һәм аңа сүз кушкан:

— Әй, бүрекле баш, шушындый куе урманда япа-ялгызың гына курыкмыйча батырланып ничек йөрисең? — дигән. Теге дә үзенең ник йөрүен сөйләп биргән. Хуҗаның өйдә юклыгын, этнең дә аның белән бергә ияреп китүен бүрегә дә әйткән. Усал бүре тешләрен шыгырдаткан, үз-үзенә: «Боларның сарыкларын барып ашап кайтырга бик җайлы чак икән», — дигән, ә үрдәккә: «Андый кешене күргәнем юк!» — дигән дә үзе куаклар арасына кереп югалган.

Үрдәк һаман туктамаган. Хуҗасын эзләүне һаман дәвам иткән. Күргән бер коштан, төрле ерткычтан, хәтта нәни бөҗәкләрдән дә бу турыда сорашып бара икән.

Бара-бара аның каршысына көлтәдәй койрыклы бер төлке килеп чыккан.

Теге дә ахмак бит, моңа да сүз кушкан: — Багалмакай, матур апакай, минем хуҗамны күрмә¬деңме? — дигән. — Янында эте, кулында балтасы бар иде, — дип өстәгән. Хуҗасыз һәм этсез өйдәге хайваннарның тынычсызлануларын, алардан башка куркуларын да сөйләп биргән. — Чибәрләрнең чибәре, гәүһәрләрнең гәүһәре, күрдем мин аны! — дигән төлке. — Янында кәкре койрыклы эте дә, билендә корыч балтасы да бар иде, — дип өстәгән. Үрдәкне үзе белән ияртеп киткән. Алар бик озак барганнар һәм куак белән капланган елга буена килеп туктаганнар. Шунда төлкенең оясы буенда балалары уйнап йөриләр икән.

Алар:

— Әни, безгә азык алып кайттыңмы? — дип, аның тирә-юнен сырып алганнар, ә ул, авызын ерган килеш, үрдәккә күрсәткән…

— Менә, бәбкәләрем, сезгә тәмле үрдәк ите,— дигән һәм шул минут, үрдәкне буып, балаларына бүлеп тә биргән. «Үрдәк ите бигрәк тәмле була икән!» — дип, алар, авызларын ялый-ялый, аны ашап та ташлаганнар, ләкин туймаганнар, аналарыннан тагын да сораганнар.

— Хәзер, бәбкәләрем, авылга барам, берьюлы берничә үрдәк алып кайтам, — дигән төлке. Балаларын калдырып, авылга киткән.

Бер Сертотмас үрдәк аркасында бу хуҗалык тәмам туздырылган булыр иде, ләкин хуҗа уяу кеше булган, дошманнарына каршы һәр җирдә киртә куйган. Куян рәшәткә арасыннан үтә алмаган, кире борылган. Аю бәрәңге базына төшкән. Бүрегә дә сарыклар эләкмәгән, хуҗалык абзарына ул бөтенләй керә алмаган. Төлке хәйләкәр булса да, сыза алмый калган, үрдәк ите ашыйм дигәндә генә, капкынга эләккән, ә хуҗа кайткач инде, аның кирәген биргән… «Тагын берничәне тоткач, толып тектерермен», — дигән һәм тиресен киптерергә амбарга элгән.

Хайваннар эшнең нидәлеген хуҗага сөйләп биргәннәр, Сертотмасны шундый зур эшкә кушуларына алар да бик нык үкенгәннәр.

Абдулла Алиш

Чукмар белән Тукмар

Бер әбинең ике әтәче булган. Бу әтәчләрнең берсе ак, берсе кара икән. Ул аларның икесен дә бер-тигез ярата икән. Әтәчләр күп вакытларын

сугышып уткәрәләр, сугы-шырга тотынсалар, канга батып бетәләр икән. Ак әтәчне әби Чукмар дип кушкан, карасын Тукмар дип атаган. Чукмар чукырга бик оста, ә Тукмар бик оста тукый икән. Әби ашатырга тотынса, “Җимне миңа әзрәк бирдең”, “Ник минем өлешемә кердең?” — дип кычкырыша башлыйлар икән әтәчләр. Әйтешеп-әйтешеп кенә калмыйлар икән, шунда ук сугыша да башлыйлар. Чукмары канга батырганчы чукырга, Тукмары күгәрткәнче тукмарга тотына икән.

Бер дә бер көнне бу әтәчләр шулай бик каты кычкырышканнар һәм канга батканчы сугышканнар. Әбинең моны күреп бик ачуы килгән. “Боларны ни эшләтим икән?” — дигән. Тегеләрне бик каты орышкан, сугышмаска кушкан. Тегеләр әби алдында бераз тынычланып торганнар, әби аларның күзләреннән югалгач, тагын сугышырга тотынганнар.

Әби килеп житсә, Чукмар исемле ак әтәч йөгереп килеп:

— Әби, әби, кара әле, Тукмарың тукмый-тукмый башымны күгәртеп бетерде, — дип әләкли икән.

Тукмар исемле кара әтәч тә энесеннән калышмый:

— Башымны кара әле, әби, Чукмарың чукый-чукый канатып бетерде, — ди икән.

Әби аларның әләкләүләреннән дә туйган. Ул бер сүз дә әйтмәгән, Тукмарны култыгына кыстырган да каядыр күтәреп киткән. “Суярга алып китә, ахры, мине”, — дип курыккан Тукмар. Ләкин әби аны күршеләргә генә кертеп торган. Ул әтәч шунда өч кич кунган. Ялгыз калгач, Чукмарга бик күңелсез булган, аның күңеле тулган. Юньләп ашый да, эчә дә алмаган. Әбигә ул: “Тукмарны алып кайтсана, инде бер дә сугышмас идек”, — ди икән. “Ярый, — дигән әби, — алып кайтсам кайтыйм, әгәр тагын сугыша торган булсагыз, ул вакыт тотам да берегезне бөтенләй юк итәм”,— дип куркытып куйган һәм күршедәге Тукмарны алып кайткан.

Тукмар да Чукмарны бик сагынган булган, ал ар, күптәннән бирле күрешмәгән туганнар төсле, кочаклашып исәнләшкәннәр һәм киләчәктә бер дә сугышмаска сүз бирешкәннәр. Хәзер инде алар бик тату яшиләр икән, тик аларга кушылган исемнәр генә аларның электәге шуклыкларын күрсәтеп, исләренә төшереп тора икән.

Абдулла Алиш

Бикбатыр белән Биккуркак

Бер баланың ап-ак куяны белән бик матур песие булган. Алар үзара бик тату яшәгәннәр. Куян, кетер-кетер итеп, агач кайрысы кимергән, ә песи, чепер-чепер итеп, сөт эчкән.

Песи бернәрсәдән дә курыкмый икән, аңа теге бала “Бикбатыр” дип исем кушкан. Куян, дер-дер килеп, бар әйбердән дә шүрли, аны ул “Биккуркак” дип атаган.

Биккуркак беркөнне стенада коточкыч әйбер күргән: колаклары бик озын, мыеклары селкенеп тора, ә үзе бик килбәтсез икән. Куркуыннан Куян нишләргә дә белмәгән, баскан урыныннан кузгала да алмаган. Ярый әле Бикбатыр килеп җиткән һәм Биккуркакка бераз көч кергән: “Әй юләр, юләр, — дигән Бикбатыр, — үз шәүләңнән үзең куркып торасың ич”, — дигән. Биккуркактан көлгән. “Ярый әле син килдең, Бикбатыр, куркуымнан үлгән булыр идем”, — дигән Куян.

Икенче бервакытны Куян тагын куркуга төшкән, йөрәге аның дөп-дөп типкән, нәрсәдер бик нык итеп кыштырдый икән. “Хәзер идән астыннан чыга да, кыштырдаучы нәрсә мине кабып йота”, — дип уйлый икән Куян.

Песи дә колакларын торгызган, ул да курка, ахры, дип уйлаган Куян. Шулчак нидер шап итеп дөбердәп киткән. Куян һушсыз була язган. Ә Песи, авызына нәрсәдер кабып, Куян янына килгән. Килгән дә: “Менә сине куркытучы нәрсә шушы инде”, — дигән, бер кечкенә генә кара әйберне Куянга күрсәткән. “Шушы кечкенә генә фетнә шулкадәр тавыш чыгара аламы?” — дип, Куян гаҗәпләнеп караган.

Өченче бер тапкыр ачык ишектән бер эт килеп кергән һәм каты итеп өрергә керешкән. Куян карават астына кереп качкан. Ә Бикбатыр идән уртасына чыгып баскан, зур күренергә тырышып, сыртын кабарткан, эт һөҗүм итсә, аның битләрен тырнарга җыенган. Билгеле, эт аңар кагылмаган, ишектән әкрен генә чыгып сызган.

Ә Бикбатыр үзенең батырлыгы аркасында бу бәладән дә бик оста котылган.

Абдулла Алиш

Батыр әтәч

(Татар халык әкияте)

Борын-борын заманнарда бер авылда яшәгән икән, ди, бер Бабай. Бу Бабайның бер Кызы һәм бер Кәҗәсеннән башка бернәрсәсе дә булмаган, ди. Бик ярлы булган бу.

Көннәрдән беркөнне Бабай үзенең Кызын болынга Кәҗәсен көтәргә җибәргән. Кыз Кәҗәне көн буена болында көтеп йөргән дә, кичкырын гына алып кайтып, ишегалдына кертеп япкан, ди.

Бабай, Кәҗә янына чыгып:

— Йә, Кәҗәкәем, көне буена болында булып, ни ашадың, ни эчтең? — дип сорый икән.

Кәҗә моңа:

Бер яфрак ашадым да бер кашык чамасы су эчтем, — дип җавап биргән, ди.

Картның моңа ачуы килеп:

— Бер Кәҗәне дә туйганчы ашатып кайта алмагансың,— дип, Кызын бик каты ачуланган, ди.

Икенче көнне Карт болынга Кәҗәне үзе алып киткән. Кәҗә көне буена болында йөреп туйганчы ашаган, ял иткәләп алган да, ди, тагын торып ашарга тотынган. Бабай моны күреп бик шатланган. «Ярый, үзем алып килгәч, бик рәхәтләнеп, туйганчы ашады әле бу», — дип уйлый икән Бабай. Шулай дип уйлаган да теге бабай, кич булганны да көтеп тормаган, Кәҗәсен калдырып өенә кайтып киткән, ди.

Кич булып караңгы төшүгә, Кәҗә дә болыннан кайтып кергән, ди. Бабай сорый инде бу Кәҗәдән:

— Нихәл, Кәҗәкәем, көне буена болында йөрдең, ни ашадың, ни эчтең? — ди.

Кәҗә аңа:

Бер яфрак ашадым да бер кашык чамасы су эчтем, — дип җавап биргән, ди.

Картның моңа бик ачуы килә. «Гаеп Кызда түгел, бу Кәҗә үзе бик ялганчы хайван икән», — ди. Шуннан соң Бабай: «Бу ялганчы Кәҗәдән барыбер бер рәхәт тә күрмәссең», — дип уйлый да Кәҗәсен суеп ашарга була. Икенче көнне Бабай Кәҗәне ике мөгезеннән тотып алып, аякларын бәйләп сала. Бабай пычак алырга дип өенә кереп киткән арада Кәҗә аякларын ычкындыра да чыгып сыза.

Китә бу. Бара-бара барып җитә бу кечкенә генә бер өйгә. Бу — Куян йорты икән. Барып керә. Өй эчендә беркем дә юк. Бу барып кергәндә, Куянның чыгып киткән вакыты булган икән, ди.

Кояш баеп караңгы төшә башлауга, Куян үзенең өенә кайтып керә. Керсә, ни күзе белән күрсен, теге Кәҗә түр башына менеп, мөгезләрен

тырпайтып, сакалын селкетеп утыра икән, ди. Куян, моны күреп, бик каты курыккан да алдына-артына карамастан, урманга таба торып чапкан, ди.

Урманга барып керүгә, бу Куянга очраган, ди, бер Бүре. Бүрене күрү белән Куян акырып елый башлаган. Моны күреп, Бүре:

— Нигә елыйсың, сиңа ни булды? — дип сорый икән.

Куян моңа:

— Нигә еламаска, көне буена урманда йөреп, өемә әйләнеп кайтсам, түр башында бик куркыныч бернәрсә утыра, күрү белән йөрәгем ярыла язды, — ди.

Моны ишетү белән Бүре батырланып:

— Әйдә киттек, без аны хәзер куып чыгарабыз, — ди.

Китәләр. Куян өенә барып җитү белән, Бүре үзе дә курка-курка гына ишекне ача. Караңгы өйдә зур мөгезле, озын сакаллы Кәҗә башын күрү белән Бүренең дә коты оча. Бүре тиз генә өй ишеген яба да урманга карап сыза.

Куян аның артыннан китә. Куянның урманга барып керүе була, моның каршысына лап-лап басып килә икән, ди, бер Аю. Аюны күрүгә, Куян тагын кычкырып елап җибәрә:

— Коткарыгыз, харап булдым, өемә куркыныч бернәрсә кергән, — ди.

Аю бик батырланып:

— Ташла әле, юкка-барга елап күз яшеңне әрәм итмә, без аны хәзер куып чыгарырбыз,— ди икән.

Китәләр. Караңгы төшүгә Куян өенә барып җитәләр. Аю, бик батырланып өй ишеген ачып җибәрүгә, сәке өстенә менеп утырган зур мөгезле, озын сакаллы Кәҗәне күрү белән, бик каты куркуга төшә. Аю да куркуыннан алдына-артына карамый урманга чаба. Куян — аның артыннан.

Куянның урманга барып керүе була, очрый инде моңа бер Төлке. Төлке дә бик батырланып бара. Караңгы бүлмәдә кукраеп утырган Кәҗәне күрү белән, Төлкенең дә коты оча: кача бу.

Куян нишләсен, йорт-җирен калдырып чыгып китә урманга.

Таң атып яктыра башлауга, барып җитә бу бер урман каравылчысының йортына. Бу йортның койма башында утыра икән, ди, бер Әтәч. Әтәчне күрү белән, Куян, гадәтенчә, тагын да кычкырып елап җибәрә, ди.

Нигә елыйсың соң син, Куянкай? — ди Әтәч, моннан сорый инде.

— Нигә еламаска,— ди Куян,— менә минем өемә бер куркыныч нәрсә кереп утырды, аны үзем дә, Бүре белән Аю да, хәтта Төлке дә куып чыгара алмады, — ди.

— Юкка елама, Куянкай, әйдә киттек, менә мин үзем сиңа ярдәм итәрмен, — ди Әтәч.

Китәләр. Куян өенә барып җитүгә, Әтәч әйтә инде Куянга:

— Миңа өй ишеген ачу гына кыен булыр, син, ишекне ачып, мине кертеп җибәрерсең, калганын үзем белермен, — ди.

Өй янына барып җитү белән, Куянның ишекне ачып җибәрүе була, Әтәч, өй эченә кереп, Кәҗә мөгезләре арасына барып кунуы була. Кәҗә башына куна да бу, чукый башлый Кәҗәнең күзләрен. Кәҗә бернәрсә эшли алмый. Чыгып кача Куян өеннән. Әтәч аны бик ераккa хәтле куып бара. Шулай итеп, батыр Әтәч Куянны ялганчы Кәҗәдән коткарган, ди.

Кәҗә бәтиләре һәм бүре

(Татар халык әкияте)

Борын-борын заманда булган, ди, дәү сакаллы, бик акыллы бер Кәҗә. Аның булган, ди, өч бәтие. Тагын булган, ди, бу Кәҗәнең бер куышы. Кәҗә өч бәтие белән шул куышта рәхәт рәхәт тора икән, ди. Көндезләрен Кәҗә яшел болыннарда, киң тугайларда ашап-эчеп йөри икән дә, кич булгач, җырлый җырлый балалары янына кайта икән:

Таудан тауга йөримен -
Тау җимеше җыямын.
Кырдан кырга йөримен -
Кыр җимеше җыямын.
Бер имиемә сөт җыям,
Бер имиемә май җыям.

— Ачыгыз, балакайларым! — дип, ишек төбенә килә икән, ди.

Кәҗә бәтиләре өйнең ишеген ачып җибәрәләр икән, ди. Кәҗә өенә керә дә, бәтиләрен имезеп, тамакларын туйдыра икән, ди.

Шулай итеп көн артыннан көн үтә, таң ата да кич була, кич артыннан төн җитә. Иртә торгач, Кәҗә тагын яшел болыннарга, киң тугайларга чыгып китә, ди, кичен тагын шулай җырлый-җырлый кайта, ди. Боларга яңгыр үтми, җил тими, тамаклары тук, өсләре бөтен, ди.

Бервакытны соры Бүре боларны сагалап йөри башлаган. Кәҗәнең кичен шулай җырлап кайтканын ишеткән дә аның җырларын отып калган, ди.

Менә беркөнне, Кәҗә өеннән чыгып киткәч, Бүре, Кәҗә булып җырлый-җырлый, ишек төбенә килгән:

Таудан тауга йөримен —
Тау җимеше җыямын.

Кырдан кырга йөримен -
Кыр җимеше җыямын.
Бер имиемә сөт җыям,
Бер имиемә май җыям.

— Ачыгыз, балакайларым! — дип кычкырган, ди.

Кәҗә бәтиләре ишекне ачмаганнар, ди.

— Син безнең әни түгел, синең тавышың бик ямьсез, — дип әйткәннәр, ди. — Аннары безнең әни бу вакытта кайтмый. Ул кич булгач кына кайта, — дип әйткәннәр, ди.

Бүренең бик ачуы килгән, ди, ул, телен таптатып, тавышын нечкәртер өчен, туп-туры тимерчегә киткән, ди.

Су буенда алачыкта Аю тимер суга икән.

— Исәнмесез, Аю дус! — дип әйткән, ди, Бүре.

— Бик һәйбәт әле, Бүре дус! — дип әйткән, ди, Аю.

Бүре, исәнлек-саулык сорашканнан соң, Аюга әйткән, ди:

— Аю дус, минем телемне юкартып бирсәнә, — дип әйткән, ди.

Аю Бүренең телен юкартырга риза булган, ди.

— Без барыбер шул эш белән кәсепләнәбез, — дип әйткән, ди, — эш хакы бер сарык булыр, ул булмаса ике бәрән китерсәң дә ярар, — дип әйткән, ди.

Бүре сарык китермәкче булган. Шуннан соң болар эшкә тотынганнар. Бүре телен чыгарган да сандалга китереп салган, ди; Аю, җиң сызганып, аны чүкергә тотынган, ди. Бүре башта чинап җибәргән, аннары, чыдый алмыйча, улап җибәргән. Шулай да түзгән, ди. Шуннан соң аның теле юп-юка булып калган, ди.

Хәзер Бүре, нәкъ Кәҗә шикелле, нечкә тавыш белән җырлый-җырлый, ишек төбенә киткән, ди.

Таудан тауга йөримен —
Тау җимеше җыямын.
Кырдан кырга йөримен —
Кыр җимеше җыямын.
Бер имиемә сөт җыям,
Бер имиемә май җыям.

Кәҗә бәтиләре, Бүрене әниләре дип белеп, ишекне ачып җибәргәннәр иде, ди, ач Бүре аларны берәм-берәм йоткан да урманга кереп киткән, ди.

Кич булгач, Кәҗә әүвәлгечә җырлый-җырлый өенә кайтса, өйнең ишеге төбенә чаклы ачык калган, бәтиләре юк булган, ди.

— Мики-ки-ки, мики-ки-ки, балакайларым, сез кайда? — дип кычкырган, ди. Аңа җавап бирүче булмаган, ди.

Шуннан соң Кәҗә, бик кайгырып, Бүре эзеннән туп-туры урманга чапкан. Бүре урман буенда, кояшта корсагын җылытып ята, имеш. Кәҗәнең чабып килүе булган, Бүренең корсагын мөгезе белән актарып ташлавы булган, Кәҗә бәтиләре өчесе дә Бүре корсагыннан чабышып килеп чыкканнар, ди. Кәҗә, өч бәтиен ияртеп, сөенә-сөенә өенә кайтып киткән, ди.

Алар тагын элеккечә рәхәт тормыш итә башлаганнар. Шулай да, Бүре тагын килер дип, бәтиләремне тагын ашап китәр дип, Кәҗә гел кайгырып йөри икән, ди.

Беркөнне Кәҗә, өч бәтие белән, бер тар гына тирән чокыр казыганнар, ди, чокырның өстенә ялганчы гына итеп чыбык чабык түшәгәннәр дә чокыр кырыена күп итеп салам өйгәннәр, ди.

Йөри торгач Бүре бик ачыккан да, ди, Кәҗә бәтиләрен ашап булмасмы икән дип, тагын юлга чыккан, ди. Ярты юлда Кәҗәне очраткан да, ди, алдашырга тотынган, ди.

— Мин сине кунакка дәшергә дип киләдер идем, Кәҗә дус, — дип әйткән, ди.

Кәҗә аңа әйткән:

— Әйдә, алайса, Бүре дус, элек миңа кереп чәй эчеп чыгыйк, аннары сиңа да җитешербез, — дип әйткән, ди.

Киләләр-киләләр, ди, болар. Кәҗә Бүрене туп-туры әлеге хәйләле чокырга таба алып килгән, ди. Кәҗә үзе чокырны сиздермичә генә сикереп чыккан, ди, Бүре чокыр төбенә мәтәлеп барып төшкән, ди.

Кәҗә балаларына дәшкән, ди:

— Мики-ки-ки, мики-ки-ки, балакайларым, шырпы кая? Ут төртегез, янсын Бүре, йөзе кара! — дип кычкырган икән, ди.

Кәҗә бәтиләре салам өстенә ут төртеп, аны чокырга ишеп төшергәннәр, ди.

Чокыр төбендә чатыр-чотыр яна башлагач, Бүре ялынырга тотынган, ди:

— Кәҗәкәем, колагым пешә, тартып ал!

Кәҗә аңа өстән кычкырган, ди:

— Балаларымны ашаганда бик шәп иде, кычкыра-кычкыра ян!

Бераздан Бүре тагын кычкырып җибәргән, ди:

— Кәҗәкәем, башым пешә, тартып ал!

Кәҗә аңа өстән тагын кычкырган, ди:

— Балаларымны ашаганда бик шәп иде, кычкыра-кычкыра ян!

Бүре шунда янып үлгән, ди. Кәҗә өч бәтие белән, җырлый-җырлый, Бүрене шул чокырга күмеп куйганнар, ди. Аннан соң тагын элеккечә рәхәт-рәхәт гомер итә башлаганнар, ди.

Хәйләкәр төлке
(инглиз халык әкияте)

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер әби. Аның тавыклары, чебиләре, сыерлары, чучкалары бик күп булган. Көннәрдән беркөнне, бу әби картайгач, кош-кортларын, хайваннарын кararга кеше эзләп урман читенә чыгып баскан. Менә аю килә, лап-лап. Аю әбигә әйтә икән:

— Нишләп торасың, әби, — дигән.

Әби әйтә икән:

— Әй, аюкай, кош-кортларымны, хайваннарны кararга кеше кирәк иде, — дигән.

Аю әйтә икән:

— Мин ярыйммы соң, — дигән.

Әби әйткән:

— Я, әле, син ничек итеп куачаксың аларны? Күрсәт әле.

— Уууууууу!!!

Әби әйтә:

— Юк, юк аюкай, кирәк түгел, син бит аларны куркытып бетерәсең.

Аю, шулай дигәч, китеп барган.

Менә бүре килә икән.

— Нишләп торасың, әбикәй?

Әби әйтә икән:

— И, менә кош-кортларымны, хайваннарны кararга кеше кирәк иде, — дигән.

Бүре әйткән:

— Мин ярыйммы соң? — дигән.

Әби әйткән:

— Я, әле, син ничек итеп куар идең аларны? Күрсәт әле.

— Уууууу!!!

Әби әйткән:

— Юк, юк, бүре, кирәк түгел, син бит аларны куркытып бетерәчәксең, — дигән.

Менә бераз вакыт үткәннән соң төлке килеп чыккан. Төлке белән дә нәкъ шулай сөйләшкәннәр. Әби төлкедән ничек итеп хайваннарны куарсың,

дигәч, төлке бик матур итеп җырлый-җырлый, бии-бии күрсәтеп биргән. Әбигә төлке бик ошаган, һәм ул аны ярдәмгә алган. Шулай итеп, берничә көн үткәннән соң, әби кош-кортларын санаса, тавыкларының саны җитмәгән. Әби аларны эзләп тә караган, ләкин таба алмаган. Ул төлкедән шикләнгән һәм аны куарга булган. Ләкин хәйләкәр төлке бер дә үзен гаеплисе килмәгән.

Шулай көннәрдән бер көнне әби үзенең иң яраткан тавыгының юкка чыкканын белгәч, төлкене куа башлаган. Төлке әбидән качканда ишегалдындагы сөт салынган ләгәнгә килеп төшкән. Ләгәннән чыккач, төлке койрыгының очы ак калган. Шуннан бирле барлык төлкеләрнең койрык очы ак, ди.

Ни өчен Эт белән песи бер-берсенә дошман булганнар?
(Легенда)

Элекке заманда бер Этне хуҗасы бик начар карый башлаган. Эт, бичара, бик ябыгып, арыкланып, эченнән кылыч күренерлек булып калган, ди.

Менә бервакыт аны шул авылның Старостасы күргән дә бик кызганган, аны үз янына чакырып алып әйткән, ди:

— Син, төннәр йокламыйча, хуҗаның йортын саклыйсың, көндез аның терлекләрен көтәсең, быелгы ачлыкта, улап-улап, яңгыр китердең. Бар, әйт хуҗаңа, сине, карамыйча, болай ач йөртмәсен; инде ул ашлыгым уңмаган дисә, менә мин синең кулыңа шушы кәгазьне бирәм, яңа ашлык өлгергәч тә, сине ул яхшылап ашатып симертсен, анда да начар ашатса, аңа шушы фәрманны күрсәтерсең! — дип, Староста аңа печать суккан кәгазь тоттырып җибәргән, ди.

Эт шул кәгазьне алып киткән, авызында тотып та караган, кулында тотып та караган, кая куярга да белмәгән.

— Авызымда йөртсәм чылана, өрсәм, авызымнан төшә, кулымда йөртсәм ертыла, тукта, мин моны Мәчегә биреп саклатыйм, — дигән дә аны чакырып чыгарган. Чыгарган да кәгазен күрсәтеп әйткән, ди:

— Мәче дус, менә бу миңа югарыдан төшкән зур кәгазь, минем аны саклар урыным юк, син өйдә торасың, шуңа күрә мин аны сиңа әманәт итеп куеп торам, көз хуҗабыз әвен суккач, мин аны үзем синнән сорап алырмын, син яхшы сакла, — дигән. Мәче кәгазьне «ярый» дип алган да өйгә шома гына кереп киткән. Ләкин Мәчедә Эт кайгысы бармыни? Шул төнне салкын булгач, ул җылынырга дип, мичкә кереп яткан икән, Этнең боерыгын шунда онытып та калдырган. Иртән торуга мич яксалар, Этнең кәгазе дә шунда янып көл булган, ди. Менә җәй үткән. Яңгырлар явып, игеннәр уңып киткән. Өйдә

икмәк тә, аш-су да пешеп тора, ди. Адәмнәр дә тук, Мәче дә тук. Тик хуҗасы бу карт Этне һаман да карамый, ул һаман да ач кала икән. Ник дисәң, аның хуҗасыннан икмәк дәгъва итәргә кулында кәгазе юк. Хыянәтче Мәчедән сора-сорама, хәзер юньләп җавап та бирми, тыр-мыр итә дә, үтә дә китә. Шуннан бирле хәзер Эт, Мәчене күрсә, бердән аңа ташланып: — Ыр-р, ыр-р! Безне ач калдыручылар! — ди икән. Мәче: — Пырых, пырых!.. Без бит тук!.. — дип, йоннарын торгызып, өйгә таба чаба бирә, ди. Һәм шуннан бирле араларында дуслык та беткән, әле дә булса гомер буе ырлы-мырлы, этле-мәчеле булып яшәргә калганнар, ди.

Мыекбай

Бар, имеш, бер әбинең
Бик кадерле песие.
Озын булгач мыегы,
Мыекбай, ди, исеме.
Ашаган, ди, Мыекбай
Ашта пешкән ит кенә,
Ә сусаган чагында
Эчкән җылы сөт кенә.
Йоклаган, ди, һәрвакыт
Мамык мендәрдә генә.
Тигәндер бу рәхәтлек,
Белмим, кемнәргә генә?!
Тик кызганыч шунысы:
Бер дусты да булмаган.
Ниһаять, ул үзенә
Дус эзләргә уйлаган.
Аны, өйдән чыгуга,
Каршылаган Актырнак:
— Әй, син, — дигән аңарга, —
Ник торасың аптырап?
һаман этле-мәчеле
Яшәп булмый дөньяда.
Дуслар кирәк сиңа да,
Дуслар кирәк миңа да.
Дуслар кирәк һәркемгә.
Әйдә без дә дуслашыйк.

Тату гына очрашыйк,
Тату гына хушлашыйк.
Елмайган да Мыекбай,
Бөтереп ак мыегын:
— Миңа, — дигән, — ошамый
Синең кәкре койрыгың.
Ала-кола туның да,
Колакларың салынган.
Кемгә кирәк мондый дус!
Тизрәк китим яныңнан.
Чыккан икән урамга,
Чабып килгән бер Мәче.
Кара тунлы, ут күзле,
Ак тәпиле көр Мәче.
Әйдә, — дигән бу Мәче, —
Уйныйбызмы куышлы?
Кара пәри белән мин
Уйныйм фәкать сугышлы.
һәм, «мыр-рауу!» дип,
Мыекбай Атланган да сыртына,
Ул песине, елатып,
Куып керткән йортына.
Моны күреп, бер Көчек:
— Эх син! — дигән. — Нишлисең?!
Ул бит песи — туганың,
Нигә аны тешлисең?
Мыекбайның мыегы
Кабарган, ди, тагын да:
Ләң-ләң килеп, чәңгелдәп
Торма әле янымда!
Ычкын тизрәк, югыйсә
Биетәм бит мин сине!
Гади песи түгел мин,
Мин бит — фарсы песие!
Болай булсаң, Мыекбай,
Тапмыйсың син бер дус та.
Әни әйтә: «Ялгыз, — ди, —

Яшәп булмый тормышта».
Ничек ышанмыйсың ди
Әниләрнең сүзенә.
Шуңа күрә һәр көн мин
Дуслар эзлим үземә.
Көчек киткән уң якка,
Ә Мыекбай — сул якка.
Әрәмәдә йөргәндә,
Күзе төшкән куакка.
Тиеннәрнең уйнавын
Күргәч, хәйран калган ул.
«Нинди тату болар!» дип
Көнләшеп тә алган ул.
Шул вакытта бер Керпе
Килеп чыккан иснәнеп.
Аны күргәч, Мыекбай
Киткән, имеш, сискәнеп.
— Әйдә, — дигән Керпекәй, —
Сөйләшик бер, кил әле!
Без соң ничек дуслашыйк,
Син бит, Керпе, энәле.
— Энәләрем кадала
Бары явыз дошманга.
Якынрак кил, курыкма,
Тими алар дусларга.
Әгәр китсәк дуслашып,
Бергә тычкан ауларбыз.
Шунда бер-беребезне
Без яхшырак аңларбыз…
— Ә син, — дигән Мыекбай, —
Мине кем дип беләсең?!
Гади авыл песие
Дип уйлыйсың, күрәсең.
Тәкәббер дә соң үзе,
Бер тәпие бөердә:
Мин бит — фарсы песие,
Тычкан аулап йөрергә!

— Алайса хуш, — дигән дә
Керпе китеп барган, ди.
Ә Мыекбай, уйланып,
Берьялгызы калган, ди.
Өенә дә шуннан соң
Бик борчылып кайткан ул.
Менеп яткач мендәргә,
Уйга ныграк баткан ул:
«Дуслар таба алмадым
Нигә соң мин үземә?!»
Яшь тулган, ди, шулвакыт
Мыекбайның күзенә.
Аптыраган хуҗасы:
«Нәрсә булды? Нишләдең?!
Әллә авырыйсыңмы,
Ник сөтеңне эчмәдең?
Әллә яңа туп тегеп
Биримме соң уйнарга?..»
Песи исә торган да
Чыгып чапкан урамга.
Аны күргәч, песиләр
Тотынган, ди, үртәргә…
Мәҗбүр булган Мыекбай
Кире кереп китәргә.
Тагын менеп яткан ул
Мамык мендәр өстенә.
Ә уйлары тынгылык
Бирми икән һич кенә…
Бер дусты да булмагач,
Ничек эче пошмасын?!
Эзләмәсәң дус-ишләр,
Үз-үзеңә дошман син.
Җиңел түгел, әлбәттә,
Яхшы дуслар табуы.
Тик үзеңне ярату -
Дуслык өчен агу ул.
Хәкимҗан Халиков

Тавыклар көлә...
Үрдәк йөзә белә,
Казлар йөзә белә.
Сыер йөзә генә!
Сарык йөзә генә...
Ат та йөзә белә,
Эт тә йөзә белә!
Мәче йөзә белә!
Ничек шулай булган,
Ничек бар да белгән,
Ничек белеп туган?
Белмим икән бер мин,
Тик мин генә белмим,
Ярда гына йөрим...
Минем арттан кыр-р-кыр-р
Тавык җырлап килә.
Үзе йөзә белми,
Үзе миннән көлә!...

Шәүкәт Галиев

Балыкларны куркыткан

Бер малай кармак алып күл буена балык тотарга килгән, ди. Күлнең өсте тып-тыныч икән. Малай күл буена әкрен генә килеп утырган да кармак салган. Шул арада су өстендә «чулт» иткән тавыш ишетелеп киткән. Караса, басма өстендә бер бака утыра икән. Бака зур авызын шапылдатып:

— Әй юньсез малай! Кичә синең дәрестә шаулаганыңны ишетеп, судагы балыклар барысы да качып беттеләр, хәзер инде тота алмассың, — дигән.

Әминә Бикчәнтәева

Елак Әтәч

Бер Әтәч очрады миңа бүген. Акырыплар елап утырган көне.

— Нигә елыйсың, Әтәчкәй? — дип сорадым. Әтәч томшыгын ачып күрсәтте. Тешләре коелып беткән икән мескеннең.

Әтәч һаман елый:

— И-и-и, томшыгым авырта-та. Йоклый алмыйм. Ашый алмыйм. Чукый алмыйм.

— Кем койды соң синең тешләреңне, Әтәчкәй? — дим.

— Конфет күп ашадым. Шоколад яратам мин. Менә хәзер ашый алмыйм, йоклый алмыйм, томшыгым сызлы-ы-ыый, — дип елый Әтәч.

— Син бит Әтәч түгел, улым, елама. Алайса, тавыклар көлер үзеңнән. Әнә Әтәчкәйдән бөтен тавыклар көлә икән хәзер.

Елак-елак, елтын колак,
Карама таяк, карт әтәч.
Гарьлек, хурлык,
Бер түбәтәй орлык, —
дип, җыр чыгарганнар тавыклар Әтәч турында.

Син бит Әтәч түгел, конфет күп ашама, шоколад сорама. Йә елак Әтәч сыман тешсез калырсың, аннары йоклый алмассың.

Рабит Батулла

Татлы җәй

— Улым, Җәйгә дә рәхмәт әйт. Бу — Җәй нигъмәтләре, — диде әнисе, Шаянның башыннан сыйпап.

— Әнием, ә Җәйне кайдан табармын соң мин? — дип сорады Шаян.

— Җәй җиләкле урман аланында яши. Әмма ул акыллы балаларга гына күренә.

— Ә акыллы бала нинди була соң, әнием?

— Акыллы бала агач һәм куак ботакларын сындырмый, чәчәкләрне өзми, суны пычратмый, улым. Гомумән, башкаларга гел игелек кенә кыла.

Шаян, Җәйне күрү өчен, урман аланына юнәлде. Барганда, урман сукмагында бер Кырмыскага чак кына басмый калды.

— Гафу ит, зинһар, Кырмыска дус, — диде Шаян һәм әдәп белән аның яныннан сак кына үтеп китте. Ул ерак китәргә өлгермәде, куаклар арасында чырылдашкан тавышлар ишетте. Шәүлегән баласы оядан егылып төшкән икән. Әнисе, ни эшләргә белми, аның янында бөтерелә, елый.

Шулчак кинәт каяндыр Карга атылып чыкты. Шаян, сикереп, Шәүлегән баласын гәүдәсе белән каплады. Төлке баласына бәрелгәч, Карга усал каркылдап очып китте. Шаян бәләкәчне оясына салды.

— Рәхмәт сиңа, акыллы малай, — диде Шәүлегән. — Син минем баламны үлемнән йолып калдың. Мин, батырлыгыңны җырга салып, башкаларга да сөйләрмен.

Һәм Шәүлегән, биеккә күтәрелеп, өздереп сайрый башлады.Шаян алга атлады. Кинәт урман ачыклыгындагы агач ботаклары шартлап сына башлады. Якынрак килеп караса, Аю балалары икән.

— Нигә ботакларны сындырасыз?! — диде Шаян, аларны шелтәләп.

— Без бит көй чыгарабыз, — дип аклана башладылар нәни йөнтәскәйләр, уңайсызланып.

— Сез шулай көй чыгарсагыз, кичкә урманда бер исән агач та калмас, — диде Шаян һәм аларга корыган агач чырасыннан кубыз ясап бирде. Шулай урман аланына җитүен сизми дә калды Шаян. «Инде ничек Җәйне табармын», — дип, күл буендагы агач төбенә утырып кайгыга чумды.

Шулчак гаҗәеп ягымлы тавыш ишетелде.

— Кайгырма, Шаян, мин монда. Күрәсеңме, кызарып җиләкләр пешә. Кылган игелекләрең өчен алар сиңа бүләгем булсын. Кояш җылы нурын сипкәндә, кошлар сайраганда, чәчәкләр хуш ис таратып, өсләрендә күбәләкләр очканда, мин һәрчак яныңда булырмын. Шаян җиләк өзеп алды да, күзләрен йомып, авызына капты. Кара син аны, Җәй нинди татлы икән, ә?

Фирдәвес Зариф

Тычкан баласының арыслан буласы килә

Шулай ул берваkыт яңа гына канатын чыгарган яшь чикерткә болында очып арыгач, бер чәчәккә кунып, җырлый башлаган. Ә ул чәчәк тычкан оясы янында гына үсә икән. Шунда үзе кебек яшь тычкан баласы аның җырлаганын тыңлар өчен оясыннан башын чыгарган.

— Бигрәкләр дә матур җырлыйсың инде, җырчы кош, — дигән.

Чикерткәнең үзен җырчы кош диюенә күңеле булган.

— Әйдә, икәү бергәләп җырлыйк! — дигән ул.

Тычкан баласы, билгеле, үзенең җырлый белмәгәнен әйтеп тормаган.

— Бүген күбрәк җырлап ташладым шул, тавышым карлыкты, — дигән.

— Тавыш та карлыгамыни, арыслан абзый?

Чикерткә бала гына булган шул әле, ул арыслан турында ишетеп кенә белгән, үзе бәләкәй булгач, әлеге тычкан баласы да аңа чынлап та арыслан кебек зур булып тоелган.

Тычкан баласы: «Мин арыслан түгел шул», дип әйтеп тормаган. Кайсы тычканның арыслан буласы килмәсен? «Чынлап та әллә арыслан булып үсә башладым микән?» — дип тә уйлаган. Тиккә генә әнисе үзен: «Арыслан йөрәкле кызым», — димәгәндер бит!

Бу турыда әнисеннән сорар иде, ул ерак басуга ризык алып кайтырга киткән шул. Аның кайтканын көтеп торырга түземе җитмәгән, чынлап та кемлеген тизрәк беләсе килгән .

Шуннан ул якында гына җир йомшартып яткан яңгыр селәүчененнән:

— Мин арысланга ошамаганмы? — дип сораган.

— Тозсыз сораулар биреп аяк астында уралма әле! Алай йөргәнче уңыш күбрәк булсын өчен җирне йомшартыр идең! — дигән селәүчен.

Ул бу турыда кондыздан сораган, кырмыскадан да сораган, күбәләкләрдән дә сораган, тик берсе дә җавап биреп тормаган, һәркайсы каядыр ашыккан, нидер эшләгән.

Шулай йөри торгач, бака-бакылдык утырган сазлыкка килеп җиткән.

— Бака дус, минем кем икәнен әйтмәссеңме? — дигән.

— Бак-бак-бак1 Үзенең кем булуын белмәүчеләр дә бармыни әле? Бүтән кайгың булмаса, суга төртеп төшерәм! Миңа кем булсаң да барыбер, сазлыгым гына яшәсен! — дигән дә бака —бакылдык суга чумган.

Ә күл буенда үгез йоклап ята икән.

— Бу абзый белмичә калмас, — дип, тычкан баласы аның янына килеп сәлам биргән. Тик үгез колагын да селкетмәгән,чөнки ул аны бөтенләй дә ишетмәгән.

«Якынрак килеп сорасам, ишетмичә калмас!» — дип уйлаган тычкан һәм аның колак эченә үк кереп китәрдәй булып:

— Мин кем? Тычканмы, арысланмы? — дип чәрелдәгән.

Үгез барыбер аны ишетмәгән, колагы гына кытыкланган. Ул колагын кашыйм дип койрыгын селтәп җибәргән икән, тычкан баласы үзенең оясы янына ук чикерткәдән дә тизрәк очып төшкән.

Бераз аңына килгәч:

— Тычкан гына икәнмен шул, югыйсә колак селкенгәнгә дә чикерткә кебек очып йөрмәс идем, — дигән.

Сәмига Сәүбанова

Кем нәрсә ярата?

(Татар халык әкияте)

Бер йортта Песи белән Эт, Әтәч һәм Кәҗә яшәгәннәр. Кич белән алар ишек төбенә җыелалар да үзләренең эшләре турында сөйләшәләр икән. Сөйләшәләр дә бәхәсләшеп китәләр икән. «Кем нәрсә ярата? Нинди азык тәмлерәк?» -дип бәхәсләшәләр икән.

— Иң тәмле сый — сөт, — ди Песи.— Сөттән соң бер Тычкан да тотып кабып җибәрсәң, бигрәк тә шәп була инде! Тик Тычканны тотуы кыен.

— Сөт нәрсә? Ул бит сыек, тамак туйдырмый. Ә менә ярма бөртекләрен, солы орлыгын тук-тук итеп чүпләсәң — менә шунда тамак тук-тук-тук була! — ди Әтәч.

— Юк-юк! — дип сүзгә кушыла Акбай. — Бөртек чүпләп кенә туеп бул-бул-булмый. Менә сөяк кимерсәң, чынлап та әйбәт була, шунда ук тук буласың. Нинди азык тәмле, нинди азык файдалы икәнен миннән дә әйбәт белгән хайван юк.

— Нәрсә-ә-ә сөйлисең син? — дип каршы килә Кәҗә.— Менә кәбестә-ә-ә булса икән. Иң тәмле азык — кәбестә-ә-ә! — ди ул. Алар бәхәсләшәләр икән — әле һаман килешә алганнары юк, ди.

Хайваннарны чакыру

Чакырабыз кәҗәне:
— Кәҗ-кәҗ-кәҗ!
Кәҗ-кәҗ-кәҗ!
Чакырабыз маэмайны:
— Мah-мah-мah!
Мah-мah-мah!
Чакырабыз аткайны:
— Бах-бах-бах!
— Бах-бах-бах!

Йә, алар кемнәр икән?
Тезелешеп кайталар,
“Бак-бак-бак” дип әйтәләр.
— Йә, алар кемнәр икән?
.....
— Алар үрдәкләр икән.

Сикерешеп уйныйлар,
Мәэлдәшеп туймыйлар.
— Йә, алар кемнәр икән?
.....
— Алар бәрәннәр икән.

Юлны күктән сузалар,
Каркылдашып узалар.
— Йә, алар кемнәр икән?
.....
— Алар каргалар икән.

— Афәрин, бөтен җавапларың да дөп-дөрес. Ә хәзер җыр тыңлый-тыңлый, кушылып җырлый-җырлый шигырьләрдәге кош-кортларның берәрсен рәсем дәфтәреңә ясап куй әле үскәнем. (Бу урында бала алда өйрәнгән җырларның берәрсен кабат тыңлатырга мөмкин. Җыр аның исендә калсын.)

— Булдымы, үскәнем. Мөгаен, бик матур рәсем килеп чыккандыр. Үзеңә ошадымы?

— ... (ошады).

— Афәрин, син барсын да булдырасың, шулай бит.

— Кош-кортлар турында шигырьләр укыдык, ә йорт хайваннары турында юк. Шагыйрь абыйларың алар турында да матур-матур шигырьләр язган, шуларны тыңлыйк әле.

Куянкай

Әй, куян, куян,
Кечкенә генә,
Бик йомшак кына.
Ике колагы
Озынкай гына.
Аягы җиңел —
Мамыктай гына.

Нәкый Исәнбәт

Безнең сыер

— Әби, әби, әйт әле,
Сыер нигә мөгери?
— Карыны ачкан, улым,
Печән китер, йөгер, — ди.

— Ашап туйгач, ник сыер
Сузып-сузып “Му-у” ди ул?

— Эчәсе килгән, улым,
Китер миңа су-у! — ди ул.

Нәкыйп Каштан

— Акыллым, ә менә хәзер укыячак шигырьне татар халкының танылган шагыйре Габдулла Тукай язган. Шагыйрь үзенең укучыларына кыйммәтле киңәшен җиткерергә тели. Нинди киңәш икән, яхшылап тыңла әле.

Рәхәт безнең Акбайга

Рәхәт безнең Акбайга,
Менә ул бәхет кайда!
Күлмәген юасы юк,
Чалбарын юасы юк,
Үтүкләп куясы юк.

Пычракка керсә дә,
Баткак ерып йөрсә дә —
Ачуланмый берсе дә.

— Чык хәзер үк! — димиләр,
Кагылмыйлар-тимиләр.
Бәйләнми һичберкем дә,
Яши ул үз иркендә.
Рәхәт безнең Акбайга,
Менә ул бәхет кайда!

Резедә Вәлиева

Кызыклы Шәкерт

— Әйдәле, Акбай! Өйрән син, арт аягың белән тор;
Аума, аума! туп-туры тор, төз утыр, яхшы утыр!

— Ник газаплыйсың болай син, мин әле бик кечкенә;
Мин туганга тик ике айлап булыр йә өч кенә.

Юк, кирәкми, мин өйрәнмим, минем уйныйсым килә;
Шул болыннарда ятасым, шунда ауныйсым килә .

— Ах, юләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул:
Картаеп каткач буыннар — эш белү уңайсыз ул!

Габдулла Тукай

— Кадерлем, шагыйрь нинди киңәш бирә? Маэмайга ул нәрсә ди?

— ... .

— Афәрин. Әйе, тырыш яшьләй, дигән киңәш бирә. Син дә шул киңәшне онытма, ярыймы?

Акыллым, син кош-кортлар, хайваннар турында бик күп кызыклы шигырьләр тыңладың, алар турында бик күп мәгълүмат белдең. Әйдә әле, хәзер син минем сорауларыма җавап биреп кара:

— Иртүк тора, ул — ... (әтәч)

— Йомырка сала, ул — ... (тавык).

— Озын колаклы, ул — ... (куян).

— “Бак-бак”, ди, ул — ... (үрдәк)

— “Му-у”, ди, ул — ... (сыер).

Булдырдың, кадерлем. Барысын да исеңдә калдырып баргансың. Инде әти-әниеңнең, туганнарыңның буш вакытында син аларга кош-кортлар, хайваннар турында үз әкиятеңне дә сөйли адласың, шулай бит. Тик, сөйләргә оныта күрмә, яме!

Дустым, Хуҗа Насретдин мәзәкләре белән дә танышып үтик әле. Алар нәрсәгә өйрәтә икән?

Хуҗа хайваннарны, кошларны бик ярата икән. Беркөнне аның киез катасына песи баласы кереп йоклаган. Нәкъ шул вакытта Хуҗаны кунакка чакыра килгәннәр. Хуҗа, песи баласын уятырга кызганган да, бер катасын аягына киеп, икенчесен кулына тотып кунакка киткән.

Хуҗаның Акбай исемле эте бар икән. Бу этне ул арт аякларына басып торырга, ал тәпиен биреп исәнләшергә өйрәткән. Урамдагы балалар көн буена Акбайны аптырата башлаганнар. Берсе килә дә: — Яле, Акбай, —дип, арт тәпиенә бастыра. Икенчесе килә дә арт тәпиенә бастыра. Өйрәтелгән Акбай балаларның сүзен тыңлап арып бетә. Хуҗа беркөнне балаларны җыеп ала да:

— Хәзер, балакайлар, мин сезгә бер һөнәр өйрәтәм. Сез менә шулай кулларыгыз белән җиргә басып, аякларыгызны күтәреп тора аласызмы? — ди.

— Була ул, Хуҗа абый, — диләр балалар, — безгә берни түгел ул.

Алар аякларын җитез генә югары күтәреп, кулларына басып торалар.

— Ярый, бик әйбәт, — ди Хуҗа.

Шуннан ул балаларны кая күрсә шунда туктата да һөнәрләрен күрсәттерә башлый.

— Хуҗа абый, без арыдык инде, — диләр балалар. Шуннан соң балалар Акбайның да хәлен аңлыйлар, аны бүтән йөдәтми башлыйлар.

Хуҗаның бер тавыгы үзе кая барса артыннан калмыйча ияреп йөри икән. Беркөнне Хуҗаны кунакка чакыра килгәннәр.

— Хуҗа абый, зинһар, тавыгыгызны урам буенча ияртеп килмәгез. Бездә бик зур кешеләр була, көләрләр үзегездән,— дигәннәр аңа.

— Ярар, — дип калган Хуҗа. — Сез дигәнчә булыр.

Кунакка барыр вакыт җиткәч, Хуҗа тавыгын иярткән дә күрше авылга киткән.

Күрше авыл янында инеш аша чыгасы бар икән. Хуҗа инешне ерып чыккан, ә тавыгы яр буенда аптырап калган да әкрен генә өенә кайтып киткән. Шуннан Хуҗа теге кешеләргә кунакка килгән.

Акыллым, ошадымы мәзәкләр? Димәк, хайваннарга, кошларага карата нинди булырга кирәк?

Күгәрчен һәм малай

Кешеләрдән куркып өйрәнгән кош малайның үзенә ярдәм итәргә теләвен белми иде, билгеле.

Урам чатындагы чүп савытыннан асылынып торган чуалчык капрон җепкә күгәрчен тәпиләре эләккән. Бичара кошның ычкыныр җае да, савыт өстенә менеп кунар әмәле дә юк: капрон җеп кыска. Ярсып бәргәләнгән саен, капрон җеп аның аякларын ныграк авырттыра. Күгәрченгә таба ашыгам. Тик гарип аякларым тыңламый. Бер-ике атлауга гаҗизләнеп туктап калам.

Чаттан узып йөргән кешеләрнең бу чүп савытларында да, анда бәргәләнеп җан тартышкан күгәрчендә дә гамьнәре юк. Һәркемнең үз мәшәкате, үз шатлыгы, үз кайгысы. Хәер, барысы да тирә-юньгә алай ук битараф түгел икән әле. Әнә, кулына футбол тубы тотып стадионга таба йөгерүче малай бәлагә тарган күгәрченне күрүгә үк аңа ярдәмгә ашыкты. Савыт янына килеп, тубын бер читкә куйды да күгәрченне тотмакчы булды. Тегесе исә, аннан куркып тагын да ныграк талпына, үрсәләнә башлады. Канаты белән малайның битенә, кулларына бәргәләде... Кешеләрдән куркып өйрәнгән кош малайның үзенә ярдәм итәргә теләвен белми иде, билгеле.

Тырыша торгач, күгәрченне эләктереп, малай аны бер кулы белән күкрәгенә кысты, икенче кулы белән җайлап кына аның тәпиләрен җептән ычкындырды. Тәмам коты алынган кошчык тынып калды. Малай, кошны ике куллап тотып, аның күгелҗем төймәне хәтерләткән кызыл каймалы күзләренә карады, аннары өскә күтәрде. Шәһәр өстендә зәп-зәңгәр күк йөзе елмая иде. Ул әйтерсең, күгәрченне генә түгел, малайның үзен дә иксез-чиксез киңлеккә очарга чакыра.

Малай сәбәбен үзе дә аңламаган эчке бер дулкынлану белән күгәрчен тоткан кулларын кисәк өскә күтәреп, кошчыкны зәңгәр күк диңгезенә, иреккә ыргытты. Тоткында талпынып хәле беткән идеме, әллә үз бәхетенә үзе ышанырга теләмәдеме, кошчык башта һавада мәтәлеп китте, аннары иреккә чыгуын сизеп, кинәт уктай өскә атылды. Аның канатыннан каерылган ялгыз каурый һавада тирбәлә-тирбәлә җиргә төште.

Малай зәңгәр киңлектә томырылып очкан күгәрченне күздән югалганчы артыннан карап калды. Аннары, иелеп, каурыйны сак кына кулына алды, сыйпап карады.

Аксыл-көрән каурыйдан әле күгәрчен җылысы суынырга да өлгермәгән иде. Малай аны әйләндереп-әйләндереп карады, үзалдына елмайды һәм, түш кесәсенә салып, йөгерә-атлый стадионга таба китеп барды. Куанычымнан күзләрем яшьләнде…

Роза Хафизова

— Нәни дустым, син өстәл янында үзеңне тоту кагыйдәләренә төшенгәнсеңдер. Алга таба Әминә Бикчәнтәева язган бер матур хикәяне укыйк әле.

Өстәл янында

Өстәл янында Без энем Равил белән бик тату уйныйбыз. Ат-ат уйнаганда энем ат була, мин дилбегә тотам. Энем чапканда егылмасын дип, дилбегәне каты тартмыйм. Равил бик каты йөгерергә ярата. Ул башын артка чайкалдырып чаба, гел яхшы ат кебек. Без чирәмле җирдә генә уйныйбыз, юл уртасында бер дә уйнамыйбыз. Әнием анда уйнарга кушмый. Анда машиналар йөри, ди.

Йөгереп уйнап арыгач, өйгә ашарга керәбез. Бик әйбәтләп кулны юабыз. Кул сөртергә икебезнең дә кечкенә сөлгебез бар. Равил сөлгесендә чия, минекендә алма рәсеме чигелгән. Кечкенә апам чигеп бирде. Без урамнан пычранып кайтсак, түргә дә уздырмый ул. Юынып керегез, ди. Безнең зур

апабыз да бар әле. Ул инде сигезенчедә укый. Кечкенә апабыз Сәлимә исемле. Дәү апабыз — Хәлимә. Дәү апа һәрвакыт аш өстәлен әзерли. Кечкенә апа безнең өстәл янында ничек утыруыбызны тикшереп кенә тора. Әнием белән әтием өйдә булганда, безнең барыбызны да күзәтеп торалар.

— Өстәл янында тыныч кына утырып ашагыз, дәү үсәрсез, — ди әтием. Әнием дә шулай ди. Дәү апа белән кечкенә апа да шулай әйтергә өйрәнеп беткәннәр. Равил дә, мин дә аларның сүзен бик тыңлыйсыбыз килә. Тик кайчагында тик кенә утырып булмый. Шул чагында дәү апа кара чия төсле күзләре белән безгә туп-туры карый. Кечкенә апабыз тиз генә җиңебездән тартып куя.

— Тик кенә утырыгыз инде, — ди. Үзе әле әтигә, әле әнигә карый. Апаларым бөтенләй тәртипкә өйрәнеп беткәннәр. Әти дә, әни дә аларны ачуланмый. Без дә кечкенә түгел бит инде. Равил дүрттә, мин алтыда. Ә безнең шаярасы гына килеп тора. Мин Равилнең кашыгын алам да әкрен генә аның башына сугам. Дәү апам урыныннан тора да минем кашыкны алып куя.

— Авырттырмадым ич, уйнап кына, әкертен генә, — дим. Равил дә үпкәләми, елмая. Ә шулай да мине шелтәлиләр.

— Кашык ашар өчен куелган, аның белән чәч тарамыйлар, — ди әнием. Кайвакыт Равил өстәл астыннан минем аякка төртә. Мин дә аңар тибеп куям. Шаяра торгач, өстәлдә тәлинкәләр селкенә башлый.

— Болай шаярсагыз, мин сезне циркка алып бармам, — ди әтием. Без бер вакытта туктап калабыз, шаярмаска сүз бирәбез. Менә аш артыннан әнием өстәлгә карбыз китерә. Карбыз утлы күмер кебек кып-кызыл. Үзе бер дә эссе түгел, сап-салкын, үзе шикәрле. Безнең алдыбызга әнием карбыз телемнәре куя. Мин Равилнең карбызына карыйм да:

— Минем кечкенә, Равилнеке зур, — дим. Равил кулындагы карбыз телемен миңа бирә.

— Мә, апам, дәүрәге сиңа булсын. Минем карбызым кечкенә булса да, үзем зур буласым килә. Ә сиңа зур карбыз булсын. Үзең кечкенә булып калырсың, — ди Равил. Миңа бик-бик оят була. Әтием дә, әнием дә, апаларым да Равилне мактап башыннан сөяләр.

Әминә Бикчәнтәева

— Акыллым, сәяхәтебезне дәвам итәбезме?

— ... .

— Ярый. Менә без бик кызыклы тукталышка килеп җиттек. Ул — милли бәйрәмнәр тукталышы.

МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘР

— Акыллым, ә син бәйрәмнәр яратасыңмы? Нинди бәйрәмнәр беләсең? Нинди бәйрәмнәрдә булганың бар?

— ..., ... (туган көн, Яңа ел).

— Афәрин, бик матур бәйрәмнәрне атадың. Ә сабантуй бәйрәме турында ишеткәнең, ул бәйрәмдә булганың бармы соң синең?

— ..... . Бармы?

— Бик яхшы. Сабантуйны татар халкының бәйрәме дип саныйлар. Бу бәйрәм турында шагыйрьләр дә бик күп шигырьләр язганнар. Әйдәгез әле кайберләрен тыңлап китик.

Сабантуй бүген бездә!
Шатлыклар – күңелебездә,
Ал кояш – күгебездә!
Килегез, дуслар, кунакка –
Сабантуй бүген бездә!
Җилферди чиккән сөлгеләр!
Бүләкләр – күбебезгә!
Көрәшик тә, узышыйк та –
Сабантуй бүген бездә!

Роберт Миңнуллин

Сабантуй
Чәчәккә күмелгәч тугайлар,
Июньнең иң матур көнендә
Болынның иң матур җиренә
Килегез Сабантуй күргә!

Энҗе Мөэминова

Сабантуй
Ник безгә дә көрәшмәскә,
Мәйдан тотмаска әле.
Көрәшик, әйдә, бергәләп,
Бүген бит яз бәйрәме.

Сабан туенда көрәшеп,
Бил бирмәскә өйрәник.
«Без һәрвакыт әзер!» — дигәч,
Җиңелмәскә өйрәник.

Куәтебез ташып тора,
Һәркемдә — ярсу йөрәк.
...Без беләбез: әтиләргә
Лаеклы алмаш кирәк!

Газинур Морат

Акыллым, сабантуйга кемнәр җыела икән?

— ..., ... (Туганнар, дуслар, кунаклар)

— Әйе, сабантуй дуслар, туганнар җыела торган бәйрәм ул. Я әйт, әле, нәнием, сабантуй башка бәйрәмнәрдән нәрсәләр белән аерыла соң?

— ... , ... (анда көрәшәләр, ярышалар)

— Әйе үскәнем, сабантуйда ярышлар, төрле уеннар үткәрелә. Җиңүчеләргә әле бүләкләр дә бирелә. Шагыйрә Эльмира апагыз шул турыда бигрәк кызык итеп язган инде. Әйдә, игътибар белән тыңлыйк әле.

Сабантуй

Сабантуймы, сабантуй —
Уеннар туе бит ул,
Тәм-томнар сые бит ул,
Җиңүләр уе бит ул.
Чаптар өстендә чабып,
Катыктан тәңкә табып,
Колга башына менеп,
Узышлыга йөгереп
Һәм татарча көрәшеп,
Аркан белән сөйрәшеп,
Ватмый, йомырка ташып,
Тапкырлыкта сынашып
Җиңсәң әгәр,
Сабантуй —
Эчкә шатлык сыймас туй!

Эльмира Шәрифуллина

— Эльмира апагыз сабантуйда үткәрелә торган ярышлар турында язган. Исеңдә калдымы үскәнем, нинди ярышлар?

— ..., ...

— Әйе, бик дөрес тотып алдың. Болар — ат ярышлары, катыктан акча эзләү, колга башына менү, татарча көрәш, аркан тарту, кашыкка йомырка салып йөгерү. Әйдә әле, бергәләп кабатлыйк уен төрләрен: ат ярышлары, катыктан акча эзләү, колга башына менү, татарча көрәш, аркан тарту, кашыкка йомырка салып йөгерү.

— Шагыйрь Рафис абыегыз да, Шәүкәт абыегыз да сабантуй батыры булырга хыялланган яшьтәшең турында язалар.

Үзем башлыйм!
Сабан туе! Сабан туе!
Шундый кызык, күңелле!
Ник чыкмаска көрәшергә
Мин соң егет түгелме?!
Ексалар да үпкәләмим,
Димәк, миннән көчлерәк!
Көрәш өчен билдә — ныклык,
Беләкләрдә көч кирәк.
Батыр калу өчен әле
Миңда бераз иртәрәк.
Тик шулай да сабан туе
Үзем башлап җибәрәм.

Рафис Корбан

Сабан туе
Күңелле Сабантуйлары.
Бүген бәйрәм, зур бәйрәм.
Матур җырлар җырлый-җырлый
Уйныйлар әйләп-бәйләп.

Без җырлыйбыз Сабантуйда,
Иң матур җырлар сайлап.
Безнең җырга зәңгәр күктән
Кошлар кушыла сайрап.

Күбәләкләр безнең белән
Сабантуй -
күбәләкләр һәм
Кошлар өчен дә бәйрәм.

Уйныйбыз әйләп-бәйләп.
Әти-әниләребезгә
Җыйдык чәчәк бәйләме.

Матур булсын,
ямьле булсын
Сабан туе бәйрәме.

Гөлшат Зәйнашева

Сабан туе батыры

Быел батыр кем дисәң.
Батыр калды Шәвәли.
Зур мәйданда берүзе
Басып калды Шәвәли!

Басып калды Шәвәли —
Екты ул барчасын да.
Батыр калды Шәвәли
Балалар бакчасында!

Шәүкәт Галиев

— Шагыйрә Резеда апагыз сабантуйдагы чүлмәк вату, катыктан акча эзләү турында искиткеч кызык итеп язган. Күрәсең, бу уеннарда үзенең дә катнашканы булгандыр. Югыйсә шулкадәр мавыктыргыч итеп яза алмас иде. Әйдә тыңлыйк әле.

Чүлмәк вату

Уртада тора — чүлмәк,
Кулга бирделәр — күсәк,
Бәйләп куйдылар күзне,
Чуалдырдылар эзне.

Бер, ике, өч... ун адым,
Менә тагын буталдым!
Күпме генә сукмадым,
Чүлмәкне һич тотмадым.

Мөгаен, эшем уңмас,
Хәйлә кормыйча булмас!
Яулыкны чак күтәрдем,
Күсәкне алып бәрдем,
Ватылды китте чүлмәк —
Яулыкта булган хикмәт!

Катыктан акча эзләү

Коштабак тулы катык,
Торам тораташ катып,
Ничек кенә башлыйсы,
Куркуны алып ташлыйсы?
— Бер, ике, өч!-диюгә,
Катыкка авыз тиюгә,
Эшләрем китте хутка,
Курыкканмын ич юкка!

Битләрем ап-ак булды,
Борынга кадәр тулды,
Тик кайда соң акчасы,
Әллә ташлап качасы?
Авыз шәбрәк сөздеме,
Әллә уйны сиздеме,
Эләкте бит, эләкте,
Мин дә булдым бүләкле!

Бәйрәмнән соң

Кай арада көн үткән,
Йокларга вакыт җиткән.
Тиз-тиз генә чәйләдем,
Урынны да җәймәдем,

Баш төрткәнче мендәргә
Йокы кергән күзләргә.

Төне буе төш күрдем,
Һаман мәйданда йөрдем.
Бер җиңелдем, бер җиңдем,
Бер еладым, бер көлдем.
Ә шулай да шәп, хәйран
Сабантуй дигән бәйрәм!

Резеда Шарипова

Сабантуй батыры!

Бүген Сабантуй! Кояш Рузилне якты җылы нурлары белән сәламләп каршы алды. Тәрәзә каршында үскән каеннар, чаганнар да, ишегалдында чыр-чу килгән кошлар да — барысы малайны бәйрәм белән тәбрикләде.

Рузил алдан ук әзерләп куйган күмәч валчыкларын чәчәкле газонга сипте. Шуны гына көткәндәй, каяндыр өч күгәрчен очып килде һәм, «гөлдер-гөлдер-гөлдергү» дип, рәхмәтләрен укый-укый, валчыкларны чүпли башлады. Малай, күгәрченнәрнең ашаганын күреп, бик сөенде.

Рузил белән әбисе Сабантуй узачак болынга килеп җиткәндә, бәйрәм башланган иде инде. Малайның игътибарын озын колгада җилфердәп торган әләм җәлеп итте. Татарстан байрагы. Яшел, ак, кызыл төсләр кояш нурларында шундый матур булып уйныйлар, ирексездән ямь-яшел болын буйлап ап-ак ромашкалар, кып-кызыл сусыл җиләкләр җыярга китәрсең...

Ярышларның иң кызган чагы икән: кем йомырка салынган кашык кабып йөгерә, кем сулы чиләкләр тотып чаба, кем мәйданда көрәшә.

Рузил балалар мәйданчыгын күреп алды да шул якка таба тиз-тиз атлап китте. Мәйданчыктагы малайларның кайсысы машина, кайсысы туп тоткан. Кызлар рәхәтләнеп шоколад ашый. Әнә ике малай сулы мичкәдә балык тота. Балыклар кулдан ычкыналар да мичкәгә чумалар, алар артыннан малайларның башлары да суга кереп китә.

Бер ишегалдында яшәүче Зөләйха апасын күргәч, Рузил кояш кебек балкыды. Зөләйха апасы да малайны таныды. Өстәлдәге кәрзиннән яшькелт-кара роботны алды да Рузил янына килде.

— Исәнме, күрше! Озак йоклагансың бүген. Мә, Сабантуй истәлеге булсын! — дип, малайга робот сузды.

Рузилнең мондый роботы юк иде әле. Булганнары да ватылып беттеләр. Малай нишләргә дә белмәде. Менә робот. Кулыңны суз да ал. Сабантуйда алай эшләргә ярыймы соң? Ул як-ягына борылып карады. Рузилнең әнисе, ал эшләпәсен кигән нәни Алияне алдына утыртып, янындагы күрше апага нидер сөйли иде. Әнә Марат. Чебен тимәс чер итәр бер елак малай ул. Тагын әнисенең итәгенә тагылган инде. Кулындагы туңдырмасы күлмәк изүенә аккан.

Рузил роботны Зөләйха апасына кире сузды һәм: — Мә, апа! Мин бу роботны үзем көрәшеп алам, — диде.

Ул, кыю гына атлап, мәйданның уртасына узды.

Көрәштерүче абый аның каршына кап-кара чәчле таза гына бер малайны китереп бастырды. Рузил шикләнә башлады: «Әгәр җиңелсәм?»

Шунда ул биек колгага кунган күгәрченне күреп алды. Ишегалларында күмәч валчыкларын чүпләгән өч күгәрченне исенә төшерде. Рузилнең кәефе күтәрелеп китте, һәм ул, башын селкеп, борчулы уй ларыннан тизрәк арынырга ашыкты.

«Юк, бирешергә ярамый! — Рузил сөлге белән таза малайның биленнән кысып алды да аны чирәмгә екты. — Көч бар икән бит. Эх, әни күрсә генә ярар иде!»

Таза малай сикереп торды, Рузилне биленнән алмакчы булды. Үзе мыш-мыш килә, аяк чалырга маташа. Рузилнең ачуы кабарды: таза малайны чирәмгә ничек итеп тәгәрәткәнен сизми дә калды. Көрәштерүче абый малайларны аякларына бастырды да җиңүченең кулын өскә күтәрде.

...Рузил әле капчык киеп тә йөгерде. Алдан килгән өчен, аңа футбол тубы бирделәр. Йомырка салынган кашык кабып чапты — машиналы булды...

Тәмам арып беткән Рузил әнисе алдына бүләкләрен китереп салгач, әнисе:

— Булдырдың, улым! — дип, малайның юешләнгән чәчләрен артка сыпырып куйды.

Малай сөенде. Сеңлесен күреп, уенчык машинаны Алиягә сузды.

Зөләйха апасы, килеп, малайның кулын кысты:

— Күрше! Кайда соң роботың?

Рузил яшькелт-кара роботны, бүләкләр арасыннан табып, һәммәсенә күрсәтте. Бу — аның көрәшеп җиңгән беренче бүләге.

— Менә бит, улым, син дә Сабантуй батыры булдың! — дип, әбисе малайны җилкәсеннән сөеп алды.

Ямь-яшел урманнар, ап-ак ромашкалы, кып-кызыл җиләкле аланнар алтынсу кояш нурларына күмелгән. Көн гаҗәеп матур. Мәйдандагы кешеләрнең күзләренә сөенеч тулган, һәркем көлә, һәркем шатлана.

Рузилнең баш очыннан гына өч күгәрчен очып үтте. Алар да кулына уенчык робот тоткан малайны котлый иде.

Рәшит Бәшәр

Карга боткасы

Яз җиттеме, безнең әби
Ясый «карга боткасы»,
Ботка белән сыйланалар
Бөтен авыл баласы.

Аның яме! Аның тәме
Телләреңне йотарлык!
Аның тәмен ел буена
Саклап кына тотарлык.

Әзһәр Габиди

— Кадерлем, менә дигән сабантуй, карга боткасы бәйрәмендә дә булып кайттык. Син үзеңнең исеңдә калганнарны рәсемдә чагылдырырга теләсәң, буш вакытыңны багышларсың әле, яме.

— Сабантуй гына түгел, татар халкының башка милли бәйрәмнәре дә бар. Шуларның бер се — Нәүрүз. Синең бу бәйрәм турында ишеткәнең бармы?

— Әйе.

— Бабаларыбыз элекке вакытларда Ай һәм Кояш календаре буенча яшәгән. Яңа елның беренче көне итеп көн белән төннен тигезләшкән вакытын (ул 21 мартка туры килгән) исәпләгәннәр. Татарлар аны «Нәүрүз ае» дип йөрткәннәр. «Нәүрүз» фарсы телендә «яңа көн» дигәнне аңлата. Бу көнне Яңа елны каршылау белән бәйле җырлар башкарылган. Нәүрүз бәйрәме көнендә балалар, өйдән өйгә йөреп, нәүрүз әйткәннәр, бүләк җыйганнар.

Чиби-чиби, чип тавык,
Куначага мен, тавык.
Куначага меналмасаң,
Чебешеңне җый, тавык.
Әби-бабай, үдәмесең,
Бер җомырка бирәмесең?

Бер җомырка бирмәсәң,
Тимерчегә барырмын,
Тимер тукмак алырмын.

Нәүрүзчеләр йорт хужаларына яңа елда исәнлек-саулык, кырларга бай уңыш, мал-туарга мул үрчем теләгәннәр.

Былбылдан аваз килде

Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде,
Былбылдан аваз килде —
Нәүрүз мөбарәк булсын!

Абзый, эшең уң булсын,
Теләгәнең юш булсын,
Күңелләрең хуш булсын
Нәүрүз мөбарәк булсын!

Нәүрүз хакы биш алтын,
Бирсәң, ярар ике алтын,
Карама ялтын-йолтын —
Нәүрүз мөбарәк булсын!

Нәүрүз

Әнә яз яшелләнә,
Жир-анабыз гөлләнә,
Бозны тишә ак чәчәк,
Көнгә бага саф чәчәк!

Бүген көн тиң төннәргә,
Урын юк hич көнләргә,
Без дә тиң, без дә тигез!
Мөбарәк Нәүрүз! — дибез.

Әхмәт Гадел

Нәүрүз

Хуш киләсең, гүзәл Нәүрүз! —
Язгы яңа елыбыз,

Яңа елда туры булсын,
Нурлы булсын юлыбыз!
Ерақларга яңгырасын
Бүген дәртле җырыбыз.

Роберт Миңнуллин

Нәүрүз килә

Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,
Нәүрүзне зурлыйк әле.
Гөрләвекләр челтерәвенә
Кушылып җырлыйк әле.

Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,
Илләр, көннәр ямьләнә.
Бергәләшеп биергә дип,
Куллар кулга бәйләнә.

Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,
Күктән нурлар сибелә.
Туган илем, туган җирем
Язны күреп сөенә.

Роза Хафизова

— Үскәнем, мин сиңа тагын Сөмбелә бәйрәме турында да сөйлим. Урып-жыю эшләре тәмамлангач, халкыбыз Уныш бәйрәмен — Сөмбелә бәйрәмен уздыра торган булган. Ул көн белән төн тигезләшкән вакытка (21-23 сентябрьгә) туры килгән. Уныш, җыелып, келәт-амбарларга тутырылгач, халык бик зурлап бәйрәм уздырган. «Сөмбелә» сүзе гарэпчәдән «башак, бөртек, орлык, иген» дип тәрҗемә ителә. Ә бәйрәмнең «Сөмбелә» дип аталуы Уңыш алиһәсенең исеменнән алынган. Татар халкы элек-электән игенчелек белән шөгыльләнгән. Бәйрәмнең хуҗасы Сәмбелә алтын-сары төстәге толымлы кыз булган. Аны иң үңган, ин чибәр кызлар арасыннан сайлап алганнар һәм, матур итеп киендереп, мәйданга алып чыкканнар. Сөмбеләнең башына алтын башаклардан такыя үреп кидергәннәр. Ил агайлары Сәмбеләне көлтәләр белән бизәлгән тәхеткә утыртканнар. Кызга төрле сораулар биргәннәр: «Балтамы, әллә безме?» Сөмбелә: «Балта» — диса, көз салкын булачак, бозны балта белән дә вата алмассың, имеш. «Без» — диса, көз жылы

киләчәк, елгадагы бозны без белән дә тишеп булачак, дип уйлаганнар. Сөмбелә бәйрәмен бүген дә бик күңелле итеп бәйрәм итәләр. Аның иң матур үрнәкләрен авыл мәктәпләрендә күрергә була. Балалар берничә көн алдан шигырьләр, җырлар өйрәнәләр, уеннар әзерлиләр. Бәйрәм көнне яшелчә, җиләк-җимешләр, башаклар белән өстәл бизиләр. Монда биш чатлы кишерне дә, колач кинлегендәге кабакны да, төймә зурлыгындагы помидорны да күрергә була. Ин уртага — түргә икмәк куела. Өстәлне бизәүдә шулай ук сары яфракларны, кызыл миләшләрне, баланнарны да кулланалар. Укучылар бөртек аеру, бәрәңге чүпләү, бәйләү, суган әрчү буенча бәйгеләр үткәрәләр. Барлык бәйгеләрдә җиңеп чыккан кыз сыйныфның йә мәктәпнең Сөмбеләсе исеменә лаек була. Аңа башаклардан ясалган такыя яки чәчәкләрдән үрелгән калфак кидерәләр.

Уңыш

Үсеп утыра арыш,
Һәр башагы бер карыш.
Бодай үсә ургылып,
Дулкынланып, зур булып.

Әгәр күрсәң солысын
Исең китеп торырсың.
Әнә кара тарыга,
Үрмәли югарыга.
Зәңгәр чәчәкле житен —
Читләтеп үтү читен.
Киндер дә бигрәк уңган,
Әйтерсең кара урман.

Кәбестәләр, суганнар
Түтәлләргә тулганнар.
Кишер белән чөгендер
Тик җыеп кына өлгер.

Әхмәт Ерикей

Алма җыябыз

Урман-кырларга
Килде матур көз.
Жай үтте диеп
Укенмибез без.

Бакчада хуш ис,
Бакчада ямьле.
Берсеннән-берсе
Алмалар тәмле.

Без, шау-гөр килеп,
Алма коябыз.
Алны тутырып,
Алма җыябыз.

Әниләр безгә:
— Булдырасыз! — ди, —
Бездән дә инде
Уздырасыз! — ди.
Без аның саен
Шатланышабыз.
Әниләр белән
Без ярышабыз.

Галимжан Латыйп

Көзге табын

Көзге табын – бай табын,
Кыяр, карбыз һәм кавын
Телем-телем теленгән,
Өем-өем өелгән.

Алмалары ал төсле,
Балкып туган таң төсле.
Капсаң, эри авызда,
Һәр кисәге бал төсле.

Ә җимеше, җимеше,
Ачысы бар, төчесе!
Яңа пешкән күмәчтер
Кайнар кояш төслесе.

Әткәм кебек тырыш көз,
Әнкәм кебек юмарт көз.
Көзләр юмарт булганга,
Бик бәхетле, бик шат без.

Фәнис Яруллин

Сөмбелә
(жыр)

Сөмбелә дип матур исем
Кушты икән кем генә?
Сөмбел гөлдән өзлеп төшкән
Чәчәк кебек Сөмбелә.

Кушымта:
Сөмбелә, Сөмбелә,
Сөмбел гөлдән өзлеп төшкән
Чәчәктер ул, кем белә?

Әткәсенә, әнкәсенә
Ул күз карасы кебек.
Гөл арасында сайраган
Былбыл баласы кебек.

Кушымта:
Сөмбелә, Сөмбелә,
Гөл арасында сайраган
Былбылдыр ул, кем белә?

Чәчәк кебек сөйкемле ул,
Былбыл кебек моңлы ул.
Таң аткач та сүнми торган
Йолдыз кебек нурлы ул.

Кушымта:
Сөмбелә, Сөмбелә,
Таң аткач та сүнми торган
Йолдыздыр ул, кем белә?

Гөлшат Зәйнашева

Сөмбелә

Табыннар сыгылып тора
Ул сыйдан, ул нигъмәттән.
Алмалары ташып чыккан
Баллы, татлы ширбәттән.

Ташкабак менеп утырган
Уртага, бәлеш булып.
Кайнатма, бал, кыстыбыйдан
Өстәлләр тора тулып.

Ит бәлеше дә күренә,
Хәтта өчпомагы да.
Гомбәнең ниндие кирәк —
Майлысы да, агы да.

Кура җиләге һәм чия
Компотка әверелгән.
Кемдер исә муенына
Миләш-муенса элгән.

Ак күмәч, ак ипи булып,
Түрдән икмәк нур сибә.
Мондый тәм-томнарны күргәч,
Авыздан сулар килә.

Биибез дә, җырлыйбыз да,
Уеннар да уйныйбыз.
Киләсе елга да уңыш
Мул булыр дип уйлыйбыз.

Иртә яздан тырыштык бит,
Тир түктек бакчабызда.
Хезмәтнең нәтижәсенә
Сөенә барчабыз да.

Нинди көн, нинди тантана,
Бу бәйрәмне кем белә?
Бездә Уңыш бәйрәме бит,
Бай һәм юмарт Сөмбелә!

Ленар Шәех

Уңыш җыелды

Уңыш җыелды,
Аккошлар китте,
Матур көз ае -
Сентябрь житте.

Урамнар тулып,
Йөкләр үтәләр,
Алар дәүләткә
Ашлык илтәләр.

Бар да ашыга,
Тизрәк илтик, дип,
Илебезне бай,
Матур итик, дип.

Ленар Шәех

Помидор-светофор

Помидор-светофор
Ямь-яшел алдымда.
Су сибим, йомшартыйм,
Мин барыйм янына.

Помидор-светофор
Саргая кай ара.
Көз, бераз түз, диям,
Әйтерсең, шаяра.

Помидор-светофор,
Син пештең кызарып.
Туктыйм да сокланам,
Киталмыйм кузгалып.

Шәүкәт Галиев

Ипекәй

Бала:
Яхшы беләм игеннең
Кара җирдә үскәнен,

Урган чакта әтинең
Манма тиргә төшкәнен.
Нигә алтын төсле соң
Ындырдагы көшелләр?

Ипекәй:
Үстергәнгә кадерләп
Алтын куллы кешеләр.

Бала:
Оны ап-ак! Бу аклык
Каян килгән соң аңа?

Ипекай:
Ак булган ул, игенче
Күңеле ак булганга.

Бала:
Ашаганда телемне
Йота яздым әле мин.

Ипекей:
Беләсеңме, әниең
Пешергәнгә тәмле мин.

Бала:
Валчыгын да калдырмыйм
Ашаганда табында.

Ипекәй:
Әгәр эшләп ашасаң,
Тәмлерәк мин тагын да.

Бала:
Кайдан алып безгә син
Шулкадәр көч бирәсең?

Ипекәй:
Миңа күпме кешенең
Көче кергән, беләмсең?

Хәкимжан Халиков

Балачак бәйрәмнәре

Бәйрәмсез бик күңелсез бит
Күңелсездер сезгә дә.
Бәйрәмнәр кирәк безгә дә,
Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә,
Кирәк һәммәбезгә дә!
Бәйрәмнәр кирәк әтигә,
Бәйрәмнәр кирәк әнигә,
Бабай белән әбигә!
Бәйрәмнәр бетмәс берчак та,
Балачаклар бар чакта.
Зур бәйрәм — бишле алсак та,
Кырларда эшләп арсак та,
Зоопаркка барсак та!
Зур бәйрәм — җырлап алсак та,
Җәйге кояшта янсак та,
Походларга барсак та!
Бәйрәмнәр бездә җитәрлек.
Үзе бәйрәм — балачак!
Балачакның шат җырлары,
Балачакның шат еллары
Мәңге истә калачак!
Бәйрәмнәр бик күп болай да,
Ә шулай да, ә шулай да
Иң шәп бәйрәм — балачак!

Роберт Миннуллин

— Бәйрәм булгач, анда милли ризыклар да булырга тиеш. Ә татарда милли ризыклар бик күп. Алдагы тукталыш — милли ризыклар.

МИЛЛИ РИЗЫКЛАР

— Кадерлем, син татарларның ачык чырайлы, кунакчыл халык булуы турында ишеткәнсеңдер инде. Халкыбыз кунакны мул ризык белән каршыларга яраткан. Шәүкәт абыегыз үзенең шигырендә шул турыда язган. Ә син ул әйткән ризыкларны исеңдә калдырырга тырыш, ярыймы?

Татар милли ризыклары турында табышмаклар

Бутап камыр басканнар.
Бәрәңге, ит, тоз салып,
Почмаклар ясаганнар. (Өчпочмак)

Утырсам да мин менә
Тыйнак кына, тик кенә.
Эчем тулы ит кенә,
Май белән, дөге белән. (Бәлеш)

Чыж иттереп саласың,
Бик тиз генә аласың.
Балга манып кабасың.
Ул нәрсә? (Коймак)

Камыр эчендә бәрәңге
Йә, уйлап кара әле. (Кыстыбый)

Иттән генә торам мин
Майга чумып чыгам мин. (Пәрәмәч)

Вак-вак кына итеп кисеп,
Өяләр аны таудай!

Чак-чак кына алып, өзеп
Аша, дустым, син шулай. (Чәк-чәк)

Үзе түгәрәк,

Урыны түрдәрәк,
Эче тулы күзәнәк
Әчкелтем дә төчкелтем,
Бар нәрсәдән дә кадерлерәк!
Ул нәрсә — ипи.

Уен-табышмак “Бер сүз белән әйт”

— Эченә бәрәңге, тары ярмасыннан эчлек салып пешергән ашамлык (Кыстыбый)

— Милли татар ашамлыгы (Өчпочмак)

— Бик үзенчәлекле ашамлык, аны күбрәк шәһәр халкы әзерли. Эчлеге кат-кат итеп тезелә (Гөбәдия)

— Күкәм ризык, туй мәҗлесенең бизәге (Чәк-чәк).

— Иң борынгыдан саналган эчемлек (Әйрән).

— Көз өмәсе табынының бизәге (Тәбикмәк).

— Җиләк-җимешне кайнатып, сөзеп ясала торган ризык (Как.)

— Көн саен кулланыла торган ризык, аннан башка ашау үтми, аңа халык дан җырлый (Икмәк, ипи).

— Туйларда чәк-чәкне алыштыра торган ризык (Катлама).

— 2 сүздән тора, татар халкының милли ризыгына керә (Кош теле).

— Аш пешергәндә кулланыла. Татар халкына хас камыр ризыгы (Токмач).

Кунаклар

Без әзерлибез табын,
Китереп бөтен ягын:
Уртага куйдык чәчәк,
Чәчәк янына — чәк-чәк.

Бавырсак һәм кош теле.
Ризыклар төрле-төрле:
Сумса, бәлеш, өчпочмак,
Гөбәдия һәм коймак.

Һәркемгә чыгар өлеш:
Бар кыстыбый һәм бәлеш!
— Җитешегез, кунаклар,

Кыстатмагыз, кунаклар!
Өйгә кайтып китәргә
Ашыкмагыз, кунаклар!

Шәүкәт Галиев

Пәрәмәч...

Бүген минем туган көн.
Бәйрәм була торган көн.
Сорады әни иртән:
— Нәрсә пешерим икән?
— Пәрәмәч, — диде әти,
— Бәлеш, — диде дәү әни.
Ә мин киттем камырга,
Ашханәдән алырга.
Әнкәй кисәтте мине:
— Кайтканда ашык, — диде,
— Чыкмасын ташып! — диде.
Карадым камыр алгач,
Сатучы үлчәп салгач —
Бидоным тулыр-тулмас,
Ташымас, берни булмас!
Гәҗитләр карый-карый,
Морожный ялый-ялый,
Киттем кайтыр уңайга,
Утырдым трамвайга.
Шулай кайтып килгәндә,
Капкач төште идәнгә.
Күрәм шунда: агарып
Камыр чыга кабарып!
Тиз генә этэм-төртәм,
Савыт эченә кертәм.
Ә камыр гүя тере —
Килә дә чыга кире!
Ул үзе шундый үзле,
Үзе үзле, үзсүзле,
Бик басып тутырсаң да.
Өстенә утырсаң да,
Мөмкин түгел тыярга,

Уйламый да сыярга...
Булса да беретым жәл,
Калмады бүтән әмәл —
Салдым камырны өзеп...
Ул чыга һаман сөзеп!
Пиджакта да, чалбарда
Кесәләр тулы бар да...
Анда да бит кабара!
Мин тотындым чабарга...
Бар җирдән камыр ташып.
Торам ишектә басып.
Әйтә алмыйча берни
Бот чабып куйды әни.
— Пәрә-мә-әч!.. — диде әти,
— Бә-ә-әлеш!.. — диде дәү әни.

Шәүкәт Галиев

— Акыллым, безнең әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез кул эшләренә, җырга-биюгә бик сәләтле булу белән бергә, аш-суга да оста булганнар, тәмле ризыклар пешергәннәр. Милли ашларның үзенчәлеге халыкның тормыш рәвешенә бәйле булган. Без бүген татар милли ризыклары тукталышында. Анда бене бик күп тәмле сыйлар көтеп тора.

Бәйрәмсез бик күңелсез бит,
Күңелсездер сезгә дә.
Бәйрәмнәр кирәк безгә дә
Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә
Кирәк һәммәбезгә дә.

Роберт Миңнуллин

Кунак яратам

Зурлап олы бәйрәмне
Җыелды татлы ашлар.
Гөбәдия, бәлешләр,
Пәрәмәч, өчпочмаклар.

“Чишмәкәй”бакчасына
Җыелдылар күп булып.

Утыралар тезелеп,
Кабарып, өстәл тулып.

“Табын яме – чәк-чәк” дигән
Сүзләр йөри түгелме?
Һәрбер туйның иң түрендә
Урын ала түгелме?

Баллы чәк-чәккә күңеле
Күтәрелә кызларның.
Хәзер инде тыпыр-тыпыр
Биисе бар аларның.

Менә табын түрендә
Гөбәдия күренде.
Йөзе шат, көлеп тора,
Хуш ис бөркелеп тора.

Табын түрен һәрчак бизи
Майда пешкән кош теле.
Авыз итми һич тә китми,
Килгән кунак, билгеле.

Утырсам да мин бәлеш
Тыйнак кына, тик кенә.
Эчем тулы ит кенә,
Май белән, дөге белән.

Иттән генә торсам да,
Майга чумып чыксам да,
Мин дә бик тәмле булам,
Мин бит пәрәмәч була.

Роберт Миңнуллин

Кош теле

Табын түрен һәрчак бизи
Майда пешкән кош теле.

Авыз итми һич тә китми
Килгән кунак, билгеле.

Бәлеш

Утырсам да мин менә
Тыйнак кына, тик кенә,
Эчем тулы ит кенә,
Май белән, дөге белән.

Бөккән

Менә мине әйткәндә,
Мин бит төрлечә булам:
Бер пешкәндә — ит белән,
Бер алма белән тулам.
Мине дә тәмле, диләр,
Табынның яме, диләр.

Коймак

Коймак пеште,
Табадан төште.
Кунакларга сый-хөрмәт,
Якты чырай, такта чәй.

— Үскәнем, бергәләп “Коймаклар” уенын уйнап алыйк.

“Коймаклар” уены.

Булатның туган көнендә
Без чакырдык кунаклар.
Кунакларның килүенә
Без пешердек коймаклар.

Коймакларга карасаң,
Менә шулай күпергән,
Менә шулай җәелгән,
Менә шулай кысылган.

Коймагыңны майлап ал,
Теләгәнеңне сайлар ал!

— Акыллым, мин сиңа өчпочмак ясау серләрен әйтеп китим әле. Өчпочмак гадәттә әче камырдан ясыйлар. Сарык я бозау итен вак кына турыйлар. Бәрәңгене әрчеп, югач турыйлар. Иткә бәрәңге, суган, май, тоз, борыч салып болгаталар. Камырны чәй тәлинкәсе кадәр җәяләр. Камыр уртасына эчен салалар да өчпочмак ясап, чеметеп, ябыштыралар. Ясап бетергәч, майлаган табага тезеп, духовкага тыгалар. Өчпочмак бер сәгать чамасы пешә.

— Үскәнем, менә шундый тәмле ризыклар, мул табыннар белән каршылый татар халкы кунакны. Син нинди ризык атамаларын исеңдә калдырдың, я әйтеп чык әле?

— ..., ..., ...

— Афәрин! Ә хәзер әйдә бергәләп кабтлыйк: чәк-чәк, бавырсак, кош теле,сумса, бәлеш, өчпочмак, гөбәдия, коймак. кыстыбый һәм бәлеш.

— Алдагы шигырь олы кунаклар турында. Кемнәр икән алар?Ни өчен кунаклар килешкә бик тырышалар?

Олы кунаклар

Безгә бүген кем килә?
Саескан күптән белә.
Өйдә пешә пәрәмәч,
Бәлеш исләре килә.

Өстәлебез дә әзер,
Мунча куйган ягылып.
Килә олы кунаклар,
Көтәм күптән, сагынып.

Килә ике әбием,
Килә ике бабам.
Мин аларны яратам,
Һәрвакыт көтеп алам.

Вәсимә Хәйруллина

— Акыллым, олы кунакларның кемнәр икәнен белдеңме инде?

— ... , ...

— Әйе, әбиләр, бабайлар татар гаиләсендә иң кадерле, иң көтелгән, иң хөрмәтле кешеләр. Шуңа күрә алар килүгә аеруча тырышып әзерләнәләр гаиләдә.

— Алдагы шигырьләр дә татар халкының кунакчыллыгын, ризык әзерләү, чәй әзерләү осталыгын чагылдыра. Тыңла һәм хәтереңә салып бар, яме.

Дуслык балы

Дустым миңа алып килгән
Күчтәнәчкә «Башкорт балы»,
Янәшәгә мин дә куям —
Җыйган татар бал кортлары.

Гәрәбәдәй якты икән,
Икесе дә татлы икән:
Синең бал да кәттә икән,
Минем бал да яхшы икән!

Кысташабыз алмаш-тилмәш,
Макташабыз алмаш-тилмәш,
Очрашабыз алмаш-тилмәш —
Бик күңелле дустың килгәч!

Кыр-болыннар янәшәләр,
Гөл-чәчәкләр янәшәдер,
Бал кортлары әрле-бирле
Шәт кунакка йөрешәләр?

Син дип, мин дип бүлешергә
Гөл илендә чикләр юк бит,
Касәләре көнгә ачык,
Гел дә ачык — бикләр юк бит.

Синең балкорт, минем чәчәк
Күптән инде кушылгандыр,
Синең көйме, минем җырмы —
Җан уртаклык шушындадыр?

“Сезнең бал шәп!”, “Сезнеке!” — дип,
Макташыйк без бергә килеп,
Туганнарча йөрик шулай,
Сезгә барып, безгә килеп.

Бозылмый да, картаймый да
Безнең татар-башкорт балы —
Гәрәбәдәй якты булсын,
Мәңге булсын дуслык балы!

Шәүкәт Галиев

Бүген

Алсу җил таң нурларын
Сибеп китте тәрәзгә.
Урынымнан торалмый
Яттым әле беразга.
Нәрсәдер чаж-чож итә,
Әй исләре, исләре!
Искә төшерә өйдә
Бәлеш пешкән кичләрне
Миңа карап елмая
Матур йөзле әбием.
Сөлгегә кулын сөртә
Ак яулыкны әнием:
— Юын, чистарт тешеңне,
Матур итеп киен! — ди, —
Бүген татар бәйрәме —
Гает көне бүген! — ди.
Тордым, кердем кухняга.
Камыр шулай, чыжылдап,
Табага төшә икән,
Кетер-кетер кетердәп,
Йөгердем юынгычка.
Мин бәләкәй татарга
Ярамый мондый көнне
Озак йоклап ятарга.

Рәшит Бәшир

Кунакка килегез!

Кунакларны бик яраткан
Электән безнең халык.
Юмарт, диеп, уңган, диеп,
Килгән күптән макталып.
Татар кызы — Таңсылу мин,
Уңган буласым килә.
Чәем кайнар, чәкчәк әзер,
Йә, кем кунакка килә?

Йолдыз

— Акыллым, Йолдыз апагыз татар халкының нинди сыйфатлары турында язган?

— ..., ...

— Әйе, үскәнем, татар халкы кунакчыллыгы, юмартлыгы, уңганлыгы белән дан тоткан. Ә Зәкия апагыз сезгә халкыбыздагы тагын бер сыйфат турында сөйли. Шигырне тыңлаганда шул турыда уйла әле, нинди сыйфат икән ул?

Минем гаиләм

Аш кашыгы — агачтан,
Чәй кашыгы — көмештән.
Җиз самавыр кайнап тора —
Суы — изге инештән.

Әбием һәм әнием
Безгә бәлеш пешергән.
Бәлеш уңган, күрәсең,
Өйгә тәмле ис тулган.

Әби-бабай, әти-әни,
Мин, нәни кыз, Наилә.
Менә нинди сокландыргыч
Безнең матур гаилә!

Зәкия Туфайлова

— Я, акыллым, әйтеп кара әле, Зәкия апагыз нәрсә турында язган?

— ... .(Дус, тату гаилә турында.)

— Бик дөрес акыллым, Дус, тату, бер-берсен яратып, хөрмәт итеп яши торган зур гаилә турында. Татар халкы туганнары, күршеләре, дуслары белән һәрвакыт аралашып, ярдәмләшеп яшәгән, матур итеп өстәл әзерләгән, тәмле ризыклар, тәмле итеп чәй пешергән. Шул турыда халыкның бик матур әйтеше бар, тыңлыйк әле.

Халык авыз иҗатыннан

И әбекәй, әбекәй,
Пешер миңа тәмлекәй.
Пешер бераз әлбә дә,
Янына куш хәлвә дә.

Тагын булса, әбекәй,
Шикәр белән тәмле чәй,
Рәхмәт әйтеп, әбекәй,
Әй итәрмен чәбәкәй!

— Үскәнем, исеңдә калдымы, әйтештә әбигә эндәшү сүзе. Күр әле, ничек матур итеп, әбекәй дип эндәшә оныгы, әбисенә тәмле чәй өчен тәмле итеп рәхмәт әйткәндә. Әсин үзеңнең әбиеңә нинди матур эндәш сүзләре әйтәсең?

— Дәү әнием, кадерлем, Әбекәем бәгырым, Дәү әнием, алтыным кебек сүзләрне еш әйтәсеңме?

— ... .

— Афәрин, тәрбияле, тәмле телле кешеләр шундый матур сүзләрне еш кулланалр шул.

Акыллым, ә синең мунча чәе эчкәнең бармы?

— ... (Юк)

— Юкмыни?. Ә менә мунча чәе була икән. Шагыйрә Вәсимә апагыз сиңа шигырыендә шундый чәй турында язгын.

Шифа чәе

Мунча яккан көнне әни
Шифа чәе пешерә.
Шифа чәе җәй көннәрен
Исебезгә төшерә.

Әнием аларны җәен
Урман, болыннан җыйган.
Кышын кечкенә чәйнеккә
Бөтен җәй үзе сыйган.

Ничә төрле яфрак, җимеш,
Җир җиләге, карлыган.
Иске үлән, бөтнек, чия,
Мәтрүшкә дә калмаган.

Вәсимә Хәйруллина

— Акыллым, мунча чәен тагын ничек дип атыйлар икән?

— ... . (Шифа чәе)

— Акыллы да инде үзең. Әйе, шифа чәе дип атыйлар. Ә ни өчен шулай атыйлар икән, үскәнем?

— .... (Ул чәй үләннәрдән пешерелә).

— Афәрин. Әйе, җәй көне болыннарда, бакчаларда үскән үләннәрдән, яфраклардан пешерелә торган чәй булганга күрә ул чәй шифалы. Әле шул шифалы чәй янына әби-әбекәй коймак та пешереп куйса, чып-чын мунча сые була инде. Тыңлап китик әле шигырьне.

Әбиләрдә кунакта

Коймагы да коймагы,
Агып тора каймагы!
Табада пешеп тора,
Табынга төшеп тора.

Кайнар! —
Яланкул тотма,
Тәмле! —
Телеңне йотма.
Син телең йотсаң, Нәбирә,
Кем рәхмәт әйтер әбигә?

Шәүкәт Галиев

— Акыллым, син ничек уйлыйсың — коймак тәмле булганмы?

— ... (Әйе).

Әйтеп кара әле, нәнием, ризык бик тәмле булганда нинди сүзләр әйтәләр?

— ..... . (бик тәмле диләр)

— Әйе, бик тәмле дә диләр. Әле тагын телеңне йотарлык булган диләр. Әйдә бергәләп әби пешергән коймакны мактыйк әле: Әбекәем, коймагың бик тәмле булган, телеңне йотарлык. Булдырдың. Акыллым, әниең, әбиең пешергән ризык өчен рәхмәт әйткәндә, менә шулай мактап рәхмәт әйтергә оныта күрмә инде, ярыймы?

— Кадерлем, әйт әле, ризыкларның иң әһәмиятлесе, иң кыйммәте, иң кирәклесе нәрсә ул?

— .... (Ипи).

— Бик дөрес, үскәнем, ипи. Роберт абыегыз да безнең фикеребезне хуплый.

Ипи булса...

Ипи басуда үсә
Аннан амбарга күчә,
Аннары мичтә пешә,
Кызарып мичтән төшә.

Шуннан килә өстәлгә,
Безгә куәт өстәргә!
Ипи булса табында
Булдырам мин барын да!

Роберт Миңнуллин

— Әйе, акыллым, өстәлдә нинди генә ризык булмасын, иң кадерлесе, иң олысы — икмәк. Син үзең дә бу турыда беләсең, шулай бит.

Кыз һәм икмәк

(Балалар матбугатыннан)

Бер авылда Гөлназ исемле кыз яшәгән, ди. Бер начар гадәте булган аның: ул көйсезләнергә ярата икән.

Бервакыт әбисе аны өстәл янына аш ашарга чакырган. Тәлинкә янына бер телем арыш ипие куйган. Шунда Гөлназ: «Мин сезнең бу ипиегезне ашамыйм, үзегез ашагыз, миңа конфет бирегез», — дип киреләнә башлаган.

Шулвакыт бөтен өйне дер селкетеп, тәрәзә янына Трактор килеп туктаган:

— Мин басуны сөрдем, тырмаладым, орлык чәчтем. Ашлык куе, биек булып үсте, башаклар алтын-сары төскә керде. Ипи кирәкми дигәне өчен Гөлназга мин бик ачулы! — дигән.

Аның артыннан Комбайн килеп кергән:

— Күрсәтегез әле миңа ул ипи яратмаган Гөлназ исемле кызны! Мин юкка гына ашлыкны урдым, суктыммы? Көннәр, төннәр буе басудан кайтмадым,— дип ачуланган.

Өй янына тырылдап Йөк машинасы якынлашкан һәм яңгыратып кычкырып җибәргән:

— Мин дә ипи яратмаган Гөлназ турында ишеттем, бик үпкәләдем. Без шофер белән ару-талуны белмичә ашлыкны амбарга ташыдык. Бер дә юкка тырышканбыз икән!

Тәрәзә артында шакылдаган, гүләгән, шыгырдаган тавышлар килгән, өй дер селкенгән. Канатларын әйләндереп, Тегермән ашыгып килеп туктаган.

— Монда ничек шауламаска, ачуланмаска! Мин бер файда-сызга ашлыктан он ясадыммы? Ә Гөлназ ипигә карамый да!

Мич тә капкачларын шалтыраткан:

— Мин дә аз эшләмәдем. Гөлназ өчен гөбердәп торган ипи пешердем,— дигән.

Әбисе, аңа шелтәле карап:

— Күрдеңме, кызым, сиңа өстәл өстендә ипи булсын өчен барысы да күпме эш эшләгәннәр, тырышканнар,— дигән.

Гөлназга бик оят булган. Ул өстәл янына килгән дә:

— Әби, миңа аш ашарга ипи бирче,— дип пышылдаган. Ашны ипи белән ялт итеп ашап та бетергән. Аннан соң ишегалдына чыккан. Трактор йөртүчегә, шоферга, тегермәнгә, комбайнчыга һәм әбисенә:

— Бик зур рәхмәт! Ипи бик тәмле! — дигән.

Икмәк

(Төрекмән халык әкияте)

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер Егет. Ул бик ярлы булган. Картайган әнисеннән башка беркеме дә — сеңелләре дә, энеләре дә булмаган. Егет бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр байга эшләгән, ләкин бай аңа хезмәт хакы түләмәгән, ашарына да бик аз биргән.

Беркөнне Әнисе улына әйткән:

— Бай сине ачка үтерергә тели. Эшкә чыкма. Тауга утынга бар. Мин утынны ярлыларга сатармын. Аларның да акчалары аз, билгеле. Ләкин бу эштән килгән акчага без ничек тә яши алырбыз.

— Синеңчә булсын,— дигән Егет.

Ул иртән иртүк, кояш чыкканчы торган да, бау, балта асып, Әнисе белән саубуллашып, өйдән чыгып китәргә җыенган.

— Улым,— дигән Карчык,— менә бу ипи кисәген дә ал әле. Башка бернәрсәбез дә юк безнең. Ләкин син аның балга әйләнгәнен көтеп тор. Шуннан соң гына ашарсың.

Егет ипи телемен яулыкка төреп алган да тауларга таба киткән.

Егет төш җиткәнче эшләгән дә эшләгән. Арыган. Бик нык ашыйсы килгән. Кичтән үк авызына бернәрсә капмаган булган. Төенчекне алган да чишеп караган: ипи балга әйләнмәгәнме, янәсе. Ләкин ипи һаман да ипи булып калган. Бик ашыйсы килсә дә Әнисенең үтенечен бозарга теләмәгән Егет.

Ипине күкрәгенә яшергән дә яңадан эшли башлаган. Караңгы төшкәнче утын кисүен дәвам иткән.

— Хәзер ипи балга әйләнгәндер инде,— дип әйткән ул үз-үзенә һәм төенчекне тагын чишкән.

Караса, ипи һаман да ипи булып калган, ди. Егетнең күңеле төшкән.

— Әни мине алдаган,— дип уйлаган һәм ипине ашый башлаган. Кабуы булган, балдан да тәмлерәк булып тоелган ипи. Егет Әнисеннән оялган:

— Кичер мине, Әни. Ипи тәмле, бал кебек татлы, — дигән ул.

Йомры икмәк

(Рус халык әкияте)

Әби белән бабай бик тату яшәгәннәр.

Бервакыт бабай әбигә карап:

— Карчык, икмәк пешерер идең? — дигән.

— Нәрсәдән пешерим соң, он юк бит.

— Эх, карчык, әрҗә төбеннән кырып, бура почмакларыннан себереп, бераз җыелмасмы?

Әби, кечкенә генә канат белән әрҗә төбеннән, бура почмакларыннан себереп, бер-ике уч он җыйган.

Әби шул оннан йомры икмәк пешергән дә тәрәзә төбенә суытырга куйган.

Икмәк тәрәзә төбендә тора торгач, кинәт сәке өстенә тәгәрәп төшкән, сәке өстеннән идәнгә, идән буенча ишеккә, аннан, бусага аша сикереп, өйалдына, өйалдыңнан тышкы баскычка, тышкы баскычтан ишегалдына, ишегалдыннан урамга чыгып, юл буйлап тәгәрәп киткән.

Икмәк юл буйлап тәгәрәп барганда, каршысына бер куян килеп чыккан:

— Икмәк, Йомры икмәк, мин сине ашыйм!-дигән аңар Куян.

— Син мине ашама, Кылый куян, мин сиңа җыр җырлармын, — дигән дә шунда ук җырларга тотынган.

— Мин — Йомры икмәк, Йомры икмәк, мине әрҗә төбеннән кырдылар, бура төбеннән себерделәр. Каймак белән тугладылар, майда бастылар, тәрәзә төбендә суыттылар. Мин бабайдан да качтым, мин әбидән дә качтым, синнән дә, Куян, кыен булмас качуы! — дигән дә, үз юлына тәгәрәп китеп барган, куян аны күреп кенә калган...

Йомры икмәк һаман тәгәрәвен белгән. Менә бервакыт аның каршысына бер бүре килеп чыккан.

— Йомры икмәк, Йомры икмәк, мин сине ашыйм!

— Син мине ашама, Соры бүре, мин сиңа җыр җырлармын.

— Мин — Йомры икмәк, Йомры икмәк, мине әрҗә төбеннән кырдылар, бура төбеннән себерделәр, каймак белән тугладылар, май белән бастылар, тәрәзә төбендә суыттылар. Мин бабайдан да качтым, мин әбидән дә качтым, мин куяннан да качтым, синнән дә кыен булмас качуы! — дигән дә алга тәгәрәгән, бүре аны күреп кенә калган.

Йомры икмәк тәгәрәгән дә тәгәрәгән. Менә бервакыт аның каршына бер аю килеп чыккан.

— Йомры икмәк, йомры икмәк, мин сине ашыйм!

— Кайда ул сиңа, Кыйшык аяк, мине ашарга! Мин — Йомры икмәк, Йомры икмәк, мине әрҗә төбеннән кырдылар, бурадан себерделәр, каймак белән тугладылар, майда бастылар, тәрәзә төбендә суыттылар. Мин бабайдан да качтым, мин әбидән дә качтым, мин куяннан да качтым, мин бүредән дә качтым, синнән дә, аю, кыен булмас качуы! — дигән һәм йомры икмәк тагын да алга таба тәгәрәп киткән, аю аны күреп кенә калган.

Йомры икмәк тәгәрәгән дә тәгәрәгән, аның каршысына бер төлке килеп чыккан:

— Исәнме, Йомры икмәк, син нинди гүзәл икән?!

Аңар каршы йомры икмәк җырлый башлаган:

— Мин — Йомры икмәк, Йомры икмәк, мине әрҗә төбеннән кырдылар, бурадан себерделәр, каймак белән тугладылар, майда бастылар, тәрәзә

төбендә суыттылар. Мин бабайдан да качтым, мин әбидән дә качтым, мин куяннан да качтым, мин бүредән дә качтым, мин аюдан да качтым, синнән дә, төлке, кыен булмас качуы!

— Нинди яхшы җыр! — дигән Төлке.— Тик мин, Йомры икмәк, картайдым инде, бик начар ишетәм; минем борыным өстенә утырып тагын да бер генә җырлап күрсәт әле. Кычкырыбрак җырла.

Йомры икмәк төлкенең борын өстенә менеп утырган да шул ук җырны кабатлаган.

— Рәхмәт, Йомры икмәк, яхшы җыр. Мин тагын да тыңлар идем. Минем телем өстенә утырып соңгы тапкыр җырлачы! -дигән Төлке һәм телен чыгарган.

Йомры икмәк уйлап-нитеп тормаган, төлкенең тел өстенә сикергән, ә төлке аны шунда ук «һам!» итеп йотып та җибәргән.

— Акыллым, табын янында бик әдәпле була белергә кирәк. Ә менә Батулла язган әкияттә аю баласы Әппәс үзен бер дә матур тота белми, киреләнә. Шул әкиятне укыйк әле.

Чыбык ашату

Аю баласы Әппәс гел киреләнә. Өйдәгеләр ашарга утыра башласа көйсезләнә, елый, ди. Әнисе дә, әтисе дә аптырап беткәннәр.

— Миңа бал кирәк, миңа конфет кирәк, миңа туңдырма-маружный кирәк! — дип, Әппәс әти-әнисенең теңкәсенә тиеп беткән.

— Балыбыз юк бит, балам, әнә кәбестә аша! — ди әтисе.

— Мин кәбестә яратмый-йм! — ди Әппәс.

Башка аю балалары белән әти-әнисе кәбестәне ашап бетергәннәр, ди.

— Миңа кәбестә калдырмагансыз! — дип, Әппәс тагын елый башлаган.

— Әнә кишер аша, ул да баллы бит! — дигән әнисе.

— Мин кишер яратмыйм! — дигән Әппәс.

Шуннан кишерне дә ашап бетергәннәр.

— Миңа кишер калдырмагансыз! — дип, тагын елый башлаган Әппәс.

— Алайса, шалкан аша! — дигән абыйсы Әппәскә.

— Мин шалкан яратмыйм! — дигән Әппәс.

Шуннан шалканны да ашап бетергәннәр өйдәгеләр.

— Миңа шалкан калдырмагансыз! — дип акыра башлаган Әппәс.

Шуннан әтисе белән әнисе, базарга чыгып, бал, конфет, кәбестә, кишер, шалкан, тагын әллә никадәр яшелчә, баллы тәм-томнар алып кайтканнар да:

— Мә, киребеткән Әппәс, җаның ни теләсә, шуны аша! — дигәннәр.

— Хәзер инде ашыйсым килми-и! — дигән Әппәс.

— Мә, алайса, чыбык аша! — дип, әтисе Әппәсне бик каты ачуланып йокларга яткырган.

Син дә аю баласы Әппәс кебек кире булма инде. Аның хәленә калма, бәбекәем, безнең белән аша. Ашаганнан соң, битеңне юарсың, авызыңны чайкарсың, аннан соң йокларга ятарсың, яме!

Рабит Батулла

— Аю малае Әппәс кебек булма, берничә киңәшне истә тот:

1) әти-әнидән алда табын янына килеп утырма;
2) әти-әнидән алда ашка сузылма;
3) ипи валчыгын коеп ашама, ипинең рәнҗүе төшәр;
4) сыныгыңны ашап бетер, югыйсә бәхетең калыр;
5) вакытында туя бел, кашыгыңны куя бел.

— Әдәпле булу турында Ризаэддин Фәхреддин һәм Каюм Насыйри менә ничек язып калдырганнар.

Тәрбияле бала
(Өзек)

Тәрбияле баланың кешегә күренә торган яхшы һөнәре зурлар һәм кечкенәләр белән тереклек итүләрендә булыр. Мәсәлән, тәрбияле бала үзеннән кечкенәләргә бик шәфкатьле булыр, аларны кызганыр, һәрвакыт «туганым» дип кенә эндәшер, шулай ук үзеннән зурларга, бигрәк тә ата-анасына, үзен тәрбияләүче тәрбиячеләренә, хәтта ки үзеннән олы яшьтәгеләрнең барысына да һәрвакыт хөрмәт күрсәтер... Баланың тәрбияле булуы ашарга утырганда беленер. Тәрбияле бала зурлар күрсәткән урынга туры китереп утырыр. Терсәкләре белән таянмас, ашарга бирүләрен көтәр һәм, бүлеп бирсәләр, шуны ашар. Аз гына кабып, яхшылап чәйнәп ашар... Тәрбияле бала ашаганда һич ашыкмас, икмәк валчыкларын читкә төшермәс, ашны ашъяулыкка һәм үзенең киемнәренә түкмәс... Тәрбияле бала үзенә хәзерләп бирелгән чәйне яхшы гына утырып эчәр, икмәкне дә кадерләп кенә ашар. Аяк өстендә ашап йөргән кешенең икмәк валчыклары, җиргә төшеп, аяк белән тапталыр да гөнаһ булыр. Шуның өчен тәрбияле бала һичбер вакытта аяк өстендә ашап йөрмәс. Тәрбияле бала, аш яныннан торгач, майлы кулы белән әйбер тотмас, кулын киемнәренә сөртмәс, бәлки, яхшылап сабын белән юар. Авызын чайкар, зурлар бар вакытта, алар юынып бетергәнне көтәр, үзенә чират җиткәч юар. Тәрбияле бала үз эшен үзе эшләр. Көндез кия торган

киемнәрен урынныннан алып, пычраклары күренсә, үзе чистартыр. Әгәр дә үзенең көче җитмәслек эшләр булса, ул вакытта зурлардан үтенер... Мондый балаларны һәркем яратыр.

Ризаэддин Фәхреддин

Табын әдәпләре

Әй угыл, ризыкны уң кулың белән аша. Авызыңны тутырып капма. Вак-вак чәйнәп аша, ашың сеңешлерәк булыр. Табынга ашны китергәч, шунда ук ашарга утыр, көттермә. Ашап бетергәч, өстәлдән ашны алмас борын торып китмә. Күп кеше килгән булып, бер генә кеше килеп җитмәгән булса, бер кеше өчен күп кешене көттермә.

Ашарга утырган вакытыгызда, иң элек кулларыгызны юыгыз вә яхшы сөртегез. Үзегездән олы кешеләр булганда, өстәл янына алардан элек утырмагыз. Аш янында берни белән дә уйнамагыз. Аш янында борыныгызны тартмагыз, чөмереп ашамагыз. Ризыкны зур-зур алмагыз, ашыкмагыз, яхшы чәйнәгез, кул вә киемнәрегезне буямагыз, башкаларның ашавына карап тормагыз, күп ашарга гадәтләнмәгез, аштан күңелегез кайтканчы туктагыз. Бу нәрсәләрнең сәламәтлек өчен файдасы күп икәнлеген үзегез дә белерсез. Чәй янында каймак вә майлы ашлар булса, киемнәрегезгә тамызмагыз, кулларыгызны майламагыз, майлы кулларыгызны киемнәрегезгә сөртмәгез. Аштан соң кул вә авызларыгызны юыгыз, теш арасында бернәрсә калдырмагыз.

Каюм Насыйри

Дустым, Шәүкәт абыебыз Галиевның герое нинди икән? Укып белик әле.

Тамаша

Әнәс табын янында,
Тәлинкәсе алдында.
Кашыгы — уң кулында,
Китабы — сул кулында.
Аныкын һич белмәссең —
Әллә чәйни җөмләсен,
Әллә чәйни боткасын,
Әллә чәйни ноктасын!
Кайчак була тамаша,

Кашыклы кул адаша.
Авыз тирәли йөртә,
Ашны борынга төртә.
Йә китә ул еракка —
Барып җитә колакка!
Юри микән, кай ара
Кул болай да шаяра:
Шикәр-фәләнтоткач та,
Салып куя токмачка.
Гәрчис бутый ул чәйгә —
Эч, Әнәскәй, эч әйдә!
Инде бусы ни тагы?
Таплы-таплы китабы...
Ни ашадың? дип сора,
Ул аны белми тора.
Укудан да рәт юк ла —
Башында аның ботка!
Аш янында китап тотып
Утырмыйсыңдыр ла син?
Бу шигырьне кашык белән
Укымыйсыңдыр ла син?

Шәүкәт Галиев

— Акыллым, без синең белән бик күп тукталышларда булдык, бик күп әйберләр белдек. Минем әле сине милли киемнәр белән таныштырасым килә.

МИЛЛИ КИЕМНӘР

— Акыллым, кара әле, бу нәрсә?

— Чулпы.

— Бу чулпыларны моннан бик күп еллар элек тагып йөргәннәр. Ә кемнәр таккан икән аларны?

— Татар кызлары.

— Әйе, дөрес. Татар кызлары чулпыларны чәчләренә тагып йөргәннәр. Алар зеңгелдәп бик матур тавышлар чыгарганнар. Шул чорда татар кызлары һәм малайлары ничек киенеп йөргән икән? Синең алдыңда Әминә һәм Хәлил курчаклар. Әминә нинди киемнәр кигән?

— ... (Күлмәк, камзул, читек, калфак).

— Хәлил нинди киемнәр кигән?

— ... (Күлмәк, чалбар, камзул, читек, билбау, түбәтәй).

— Әлеге киемнәр милли киемнәр дип атала. Чөнки алар татар халкының гореф-гадәтләрен чагылдыра.

Татар баласы

Калфак кигән кыз баланың
Багып алчы йөзенә,
Нинди гүзәл татар кызы,
Күз тимәсен үзенә.

Килешеп тора түбәтәй
Аның күркәм йөзенә.
Нинди матур татар улы,
Күз тимәсен үзенә.

Ләбиб Лерон

— Үскәнем, син игътибар иттеңме, малай белән кызның киеме нәрсә белән аерыла?

— Малайларның башында түбәтәй, кызларның — калфак. Малайлар күлмәк, чалбар, билбау кия, кызлар күлмәк кия.

— Нинди киемне кызлар да малайлар да кия?

— ... (читек).

— Әйдә әле, Тәһир һәм Зөһрәне татар милли киемнәренә киендерик. Зөһрәне ничек киендерәбез?

— Зөһрәнең өстендә күлмәк, камзул, аягында читек. Башында калфак.

— Тәһир ничек киенер?

— Тәһирнең өстендә күлмәк, камзул. Аягында чалбар, читекләр. Биленда билбау. Башында түбәтәй.

— Булдырдың, үскәнем. Милли киемнәрдә миллилек өсти торган нинди үзенчәлек бар?

— Орнамент — бизәк.

— Орнамент татар халкының гореф — гадәтләрен чагылдыра. Орнаментта гадәттә чәчәкләр ясала. Сез орнаментта нинди чәчәкләр күргәнегез бар?

— Ләлә чәчәге (тюльпан), канәфер чәчәге (гвоздика).

— Тагы нинди бизәкләр төшерелә?

— Ай рәсеме, йөрәк рәсеме, өчяфрак, гөлҗимеш.

— Бик дөрес. Менә бу татар хатын-кызлары кия торган чигүле озын күлмәк. Ул төрле бизәкләр белән бизәкләнә. Безнең әбиләребез күлмәк изүенә, итәк очына, кайвакыт иңбаш турысына төрле-төрле ситсы кисәкчәләре теккәннәр. Ул күз тимәсен өчен, төрле авырулардан саклану өчен булган.

Матур изү бизәп тора, күлмәгеннең күкрәген
Диңгез суы кебек тора, дулкынланып итәге.

— Менә нинди матур итеп киенгәннәр әбиләребез яшь чакта.

— Ә менә монысы — камзул. Ул озын яки кыска, җиңле яки җиңсез булган. Бай хатын-кызлар камзулларын бәрхет яйсә ефәктән теккәннәр. Шулай ук асыл ташлар белән бизәгәннәр.

Күргәнегез бармы сылу кызлар, кия торган татар камзулын?
Бизәгәнгә, гүя, сыйдырган ул, бар тарихын илнең, бар моңын.

— Камзулны ирләр дә кигән. Ләкин алар аны өйдә кигәннәр. Алар күбрәк күлмәк белән ыштан кигәннәр.Безнең бабаларыбыз карарак төстә, ә әби-апаларыбыз ачык, якты төстәге бәрхеттән теккәннәр. Хәзерге заманда ул җилетка охшаган, аны шулай дип йөртәләр.

— Ә менә монысы, балакай, алъяпкыч. Аны гел әби-апалар киеп йөргән. Ул эш киеме генә түгел, ә көн саен кия торган кием булып саналган. Алъяпкычның күкрәк турысына, итәк читенә төрле чәчәкләр, яфраклар белән бизәп чиккәннәр. Алъяпкыч бер ничә төрле булган. Әби-апаларыбыз ашарга пешергәндә бер алъяпкыч кигәннәр, эшләгәндә печән җыйганда икенчесен, шулай ук кунакка бара торган алъяпкычлар да булган.

— Ә менә монысы калфак.. Калфакларның да төрлесе булган. Кечкенә калфакларны чәчкә кыстырып куйганнар, аның өстенә шәл ябылган. Ә менә зур калфакларны тулысынча башка кигәннәр. Аларны диңгез энҗеләре белән чиккәннәр. Эҥже чирләрдән сакласа, ә калфак башта начар уйлар юк икәнен аңлаткан. Заманалар узу белән, калфаклар да үзгәргән. Элек бәйләнгән калфаклар булган, ә хәзер күбрәк кечкенә бәрхет калфаклар алыштырган. Аларны алтын җепләр, сәйләннәр, энҗеләр белән бизәгәннәр.

— Ә хәзер, үскәнем, Р. Валиеваның “Калфак кигән кыз турында” шигырен искә төшерик.

Дәү әнием эҥже калфак, бүләк итте үземә
Эҥже калфак үзе ап-ак, бик килешә йөземә.
Калфагымның матурлыгын, һәммәсе дә күрсеннәр
Эҥже калфак кигән кыз ул татар кызы — дисеннәр.

— Балакай, кара әле ә менә бу баш киеме барыбызга да таныш. Нәрсә ул?

— Түбәтәй.

— Дөрес, чөнки аны ир-егетләр бүгенге көндә дә киялләр. Билгеле бу түбәтәй, аны кәләпүш дип тә йөртәләр. Ул безнең әтиләребез, бабаларыбыз кия торган баш киеме. Түбәтәй матур бизәлгәнме?

— Әйе, бик матур бизәлгән.

— Түбәсен алтын җеп белән бизәгәннәр. Кырыйларында матур үсемлек бизәкләре урнаштырганнар. Шулай ук түбәтәйне эҥжеләр, төрле төстәге ташлар белән дә бизәгәннәр. Ул ташлар куркакларга батырлык биргән.

— Балакай, Р Валиеваның “Түбәтәй кигән малай турында” язган шигырен дә искә төшереп китик инде.

Йөзләремә килешәсен, кайлардан гына белгән
Туган көнгә Дәү әтием, түбәтәй алып килгән
Түбәтәемне кидем мин, көзге каршына килдем
Менә шундый була ул, татар малае! — дидем.

— Үскәнем, татар халкы элек-электән ук матур итеп киенә дә белгән, бәйрәмнәр дә үткәргән. Бәйрәмнәр бик күңелле узган. Ә хәзер табышмаклар әйтешеп уйныйк.

Яңа гына идем итек.
Ч өстәгәч, булдым ... (читек)

Әнием, ак сәйләп тезеп,
Чиккән яшел бәрхетне.
Бар түбәмдә ... (түбәтәем)

Җырлый-җырлый сәхнәләрдә
Кызларның биер чагы.
Кызларга бик килешә
Башындагы ... (калфагы)

Чигәләр бүләк өчен,
Кесәңдә ул гел йөрсен,
Кечкенә генә яулык
Ул була инде ... (кулъяулык).

— Афәрин! Булдырдың, бала! Хәзер җырлы-биюле уен «Түбәтәй» уенын уйныйбыз! Түгәрәкләп басабыз, түбәндәге җырны җырлый-җырлый, түбәтәйне бер-беребезгә бирәбез:

Түбәтәеңне кигәнсең,
Бик ераклардан килгәнсең,
Төскә матурлыгың белән
Шаккаттырыйм, дигәнсең.

Кушымта.
Түп-түп, түбәтәй,
Түбәтәең укалы.
Чиккән матур түбәтәең
Менә кемдә тукталды.

Җыр ахырында, түбәтәй кемдә калса, шуңа җәза бирелә: бии. Уен шулай дәвам итә.

— Үскәнем, алга таба милли киемнәр турында шигырьләр укырбыз. Нинди милли киемнәр турында сүз барыр икән, игътибар белән тыңлыйк әле.

Дәү әнием энҗе калфак
Бүләк итте үземә,
Энҗе калфак, үзе ап-ак,
Бик килешә йөземә.
Калфагымның матурлыгын
Һәммәсе дә күрсеннәр.
Энҗе калфак кигән кыз ул —
Татар кызы, дисеннәр.

Резеда Вәлиева

Каюлы Читек

Әти алган бүләк итеп
Миңа каюлы читек.
Сабан туйда күрсәтермен
Тыпырдап биеп китеп.

Бу читекне һәрбер кеше
Күреп исе китәчәк.
Балтырлары — яшел болын,
Бизәкләре — күк чәчәк.

Мәрзия Фәйзуллина

Чигүле читекләрем

Аягымда чиккән читек,
Бизәге көлеп тора.
Нәкыш җепләрдән күңелгә
Җылы нур бөркеп тора.
Салават күпере төсе
Җемелди итекләрдә.
Останың кул җылыларын
Тоямын читекләрдә.
Биегән саен биетә
Каюлы читекләрем.
Үземә килешеп тора
Чигүле читекләрем.

Лиана Әмирханова

Түбәтәй

Әнием туган көнемә
Бүләк итте түбәтәй.
Шундый матур түбәтәем,
Үзем кебек бәләкәй.

Әнием ак сәйләп тезеп
Чиккән яшел бәрхетне.
Бар түбәмдә түбәтәем –
Мин бүген бик бәхетле!

Вәсимә Хәйруллина

Түбәтәеңне кигәнсең,
Бик ераклардан килгәнсең,
Төскә матурлыгың белән
Шаккаттыйрм дигәнсең.

Халык авыз иҗатыннан

Биилəр итек, читекләр

Гармун уйныйм, гармун уйныйм,
Һаман гармун уйныйм мин,
Остарып җиткәч, барсын да
Биетергә уйлыйм мин.

Учларыңны шакылдатып,
Чәчләреңне сыпыр да
Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр,
Тыпыр-тыпыр тыпырда.
Әй, бии итек, читекләр!
Әй, уйныйм мин, уйныйм мин,
Минем кебек шәп гармунчы
Юктыр диеп уйлыйм мин!

Шәүкәт Галиев

Кәләпүшем, кәләпүш

Йөзләремә килешәсен
Кайлардан гына белгән,
Туган көнгә дәү әтием
Кәләпүш алып килгән.

Кәләпүшемне кидем мин,
Көзге каршына килдем:
— Менә шушындый була ул
Татар малае! — дидем.

Кәләпүшем, кәләпүш,
Энҗе-мәрҗәннәр чиккән!
Чиккән кәләпүш үземә
Бигрәк килешә икән!

Әнием дә бик сөенде,
Кочаклап алып сөйде.
— Котлы булсын кәләпүшең,
Бигрәк килешә! — диде.

Әй, кәләпүш, кәләпүш,
Укалыдыр читләре.
Шундый матур кәләпүшле
Малай булдым бит әле!

Резедә Вәлиева

— Нинди киемнәрне исеңдә калдырдың, үскәнем?

— ..., ... , ...

— Бик игътибарлы икәнсең. Ә хәзер әйдә бергәләп кабатлыйк инде: энҗе калфак, каюлы читек, чиккән читек, чиккән кәләпүш, чиккән түбәтәй. Ә сезнең өегездә аларның кайсылары бар? Кемнәр кия?

— .... Чиккән түбәтәй, чиккән кәләпүш.

— Үскәнем, өлкәннәр белән бергәләп, аларда ясалган рәсем үрнәкләрен дәфтәреңә ясап кара әле. Аларда син яфрак, чәчәк рәсемнәрен күреп алгансыңдыр, мөгаен.

— Кадерлем, инде сәяхәтебезне тәмамларга да вакыт җитте. Ә тәмамлар алдыннан минем сиңа Тукаебызның “Су анасы” әкиятен тыңлатасым килә. Син әкият герое белән мажарлы вакыгаларны кичеп чыгарсың һәм бөек шагыребезнең әкият герое белән танышырсың. Әйдә җайлап утырып, бик игътибар белән тыңлыйк әле.

Су анасы

Җәй көне: эссе һавада мин суда коенам, йөзәм:
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.
Шул рәвешчә бер сәгать ярым кадәрле уйнагач,
Инде шаять бер сәгатьсез тирләмәм дип уйлагач,
Йөгереп чыктым судан, тиз-тиз киендем өс-башым;
Куркам үзем әллә нидән, юк янымда юлдашым.
Бервакыт, китәм дигәндә, төште күзем басмага;
Карасам, бер куркыныч хатын утырган басмада.
Көнгә каршы ялтырый кулындагы алтын тарак;
Шул тарак берләп утыра тузгыган сачын тарап.
Тын да алмыйча торам, куркып кына, тешне кысып,
Шунда яр буендагы куе агачларга посып.
Сачларын үргәч тарап, сикерде төште суга ул,
Чумды да китте, тәмам юк булды күздән шунда ул.
Инде мин әкрен генә килдем дә кердем басмага,
Җен онытkан ахры, калган тарагы басмада.
Як-ягымда һич кеше дә юклыгын белдем дә мин,
Чаптым авылга таракны тиз генә элдем дә мин.
Күрмимен алны вә артны, и чабам мин, и чабам;
Ашыгам, тирлим, пешәм һәм кып-кызу уттай янам.
Бер заманны әйләнеп баккан идем артка таба,
Ah, харап эш! — Су анасы да минем арттан чаба.
Кычкырадыр: “Качма! Качма! Тукта! Тукта, и карак!
Ник аласың син аны, ул бит минем алтын тарак!”
Мин качамын — ул куадыр, ул куадыр — мин качам,
Шул кадәрле кыр тыныч, һичбер кеше юк ичмасам.
Шул рәвешчә чабышып җиттек авылга бервакыт,
Су анасын куарга күтәрелде барча эт!
“Вау!” да “вау!” да, “һау!” да “һау!” — бертуктамый этләр өрә;
Су анасы, куркып этләрдән, кире йөгерә.
Инде эш җайланды, куркудан тынычландым, дидем;
И явыз карчык! Тарагыңнан коры калдың, дидем.
Өйгә кайттым да: “Әни, алтын тарак таптым!” — дидем;
“Сусадым, ардым, әни, мин бик озак чаптым”, — дидем.
Сөйләгәчтен кыйссаны, алды тарагымны әни;
Курка үзе алса да, уйлый эченнән әллә ни...

II

Яхшы, хуш. Батты кояш. Йокларга яттым кич белән.
Өй эче тулган иде кичке һава, хуш ис белән.
Юрган астында йокыга китми ятам мин һаман;
“Шык” та “шык!” кемдер тәрәзәгә чиертә бер заман.
Мин ятам рәхәт кенә, тормыйм да, кузгалмыйм әле.
Бу тавышка сискәнеп, торган йокысыннан әни:
— Ни кирәк? Кем бу? Кара төндә вакытсыз кем йөри?
Нәрсә бар соң төнлә берләп, и пычагым кергере!
— Су анасы мин, китер, кайда минем алтын тарак? Бир!
Бая көндез алып качты синең углың, карак!
Төшкән айның шәүләсе, мин юрган астыннан карыйм,
Калтырыйм, куркам, “Ходай! — дим, — инде мин кайда барыйм?”
Һич өзлексез “шык” та “шык!” безнең тәрәзәне кага,
Ул коточкыч сачларыннан чишмә төсле су ага.
Әнкәем алтын таракны тиз генә эзләп табып,
Атты да тышка, тиз үк куйды тәрәзәне ябып.
Су анасыннан котылгачтын, тынычлангач, әни
И орышты, и орышты, и орышты соң мине.
Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым,
“Я, иясе юк!” — дип, әйберләргә тими башладым.

Габдулла Тукай

— Әкият нәрсәгә өйрәтә?
— ... .
— Бик дөрес, үскәнем. Кеше әйберсенә тию иң начар гамәлләрнең берсе.

— Сәяхәтебезне туган телебез турындагы шигырьләр белән тәмамларга телибез, нәни дустым. Җыентыктагы әсәрләрнең күңеленә иң ошаганнарын исеңдә калдыр, иптәшләреңә, өлкәннәргә сөйлә. Туган телеңдә сөйләшә белүнең олы бәхет икәнлеген һәрвакыт исеңдә тот.

Минем өем

Татар телем — туган телем,
Бик кадерле телем минем.
Нинди матур сүзләр бит ул:
Әнием, әтием, өем!

Минем бик-бик якты өем
Эчендә би-ик зур илнең.
Тәрәз төбендә шул өйнең
Чәчкә аткан чагы гөлнең.
Чәчкә аткан шул гөлләргә
Сулар сибә сеңлем минем.
Ак җәймәле караватта
Бармак имеп ята энем.

Рәшит Бәшәр

Без — татар балалары!
Без — Кол Шәриф шәкертләре,
Идегәй бөркетләре,
Күчембикә токымнары,
Нурсолтан шытымнары,
Сөембикә орлыклары,
Кол Гали оныклары,
Батырша яраннары без
Һәм Тукай оланнары.
Халкымның күз каралары,
Әрнүле яралары,
Без — татар балалары шул,
Без — татар балалары!

Эльмира Шәрифуллина

Үс шул канунны белеп
Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел!

Шәйхи Маннур

Туган телеңне яхшы бел! —
Сүзсез дә анык кебек.
Бии бит ул безнең белән
Имән идәнгә чүгеп.
Туган телеңне яхшы бел! —
Артыкмы бу искәртү?
Җитә кебек: “Ак калфагым

Табылган”, диеп әйтү.
Туган телеңне яхшы бел! —
Тәкрарлау кирәк микән?
Иман байлыгы сеңдереп,
Йөзеңә кем нур сипкән?!
Туган телеңне яхшы бел! —
Кисәтү артык кебек.
Һич кенә дә артык түгел,
Үс, шул канунны белеп!

Эльмира Шәрифуллина

Тел турында мәкальләр белән дә таныш. Кайсы ошый, шуны исеңдә калдыр.

Тел — белемнең ачкычы, акылның баскычы.

Телне каләм саклый.

Теле барның юлы бар.

Һәр илнең ачкычы — тел, телен белгән ил ачар.

Теле юкны тигәнәк талар.

Тел — күңел көзгесе.

Тел — ананың баласына иң кадерле бүләге.

Кадерле дустым, туган телебезгә сәяхәт шуның белән тәмам. Үзеңнең кем икәнеңне онытма, яме!

Мин кем?

И җиләгем, ди, әни,
Җир җиләгем, ди, әни.
Баллы гөл, дип иркәли,
Чикерткә, дип шелтәли.
Күбәләктәй кунам мин,
Кайчак колын булам мин...
Аңладым инде күптән:
Мин — җәйге болын икән!

Сирень Якупова

Дустым, дөньядагы иң-иң матур ил — ул туган ил һәм иң-иң матур тел — ул туган тел икәнлеген һәрвакыт исеңдә тот. Үз туган телеңне ярат! Хөрмәтлә! Уңышлар сиңа, дустым!

ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1. Балалар календаре / төз. С. Маннапов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.
2. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әтиәниләр өчен хрестоматия. — Казан: РИЦ, 2011. — 560 б.
3. Балалар дөньясы / төз. Л.Г. Гыйләҗева, Г.Ә. Нәбиуллина. — Татар. кит. нәшр., 2013. — 159 б.
4. Балачак энциклопедиясе / төз. Т. Шакирова, Л. Шәех. — Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. — 208 б.
5. Гөлбакча (Балалар бакчалары өчен хрестоматия): Балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр өчен кулланма. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.
6. Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы: татар гимназияләре һәм лицейларының 11 нче с-фы, педагогия колледжлары, училищелары өчен дәреслек-хрестоматия. — Казан: Мәгариф, 2000.
7. Иң күңелле көн: бәйрәмнәр турында шигырьләр / төз. Э.Кәлимуллина. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. — 95 б.
8. Иң матур суз: уку китабы, балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия / төз.-авт. К. Закирова. — 2 нче басма. — Казан: Татар. кит. нэшр., 2012. — 430 б.
9. Татар халык әкиятләре: тылсымлы әкиятләр. — Казан: Тата.кит.нәшр., 1994. — 415 б.
10. Тәмле сүз: әдәпле булу серләре / төз. Талия Шакирова. — 2 нче басма. — Татарстан китап нәшр., 2013. — 79 б.
11. Туган телдә сөйләшәбез / М.М. Зарипова, Л.Н. Вәҗиева. — Казан: ФОЛИАНТ, 20212. — 304 б.
12. Урманче Ф.И. Татар халык ижаты. — Казан: Мәгариф, 2002.

ЭЧТӘЛЕК

ӘТИ-ӘНИЛӘР ӨЧЕН АҢЛАТМА ЯЗУЫ 3
ТӘМЛЕ ТЕЛЕМ 4
ҮЗЕМ ТУРЫНДА 24
ЯХШЫ ГАДӘТЛӘРЕМ 63
МИНЕМ ГАИЛӘМ, ӨЕМ 102
МИНЕМ ДУСЛАРЫМ 142
МИНЕМ УЕНЧЫКЛАРЫМ 168
МИН УЙНАРГА ЯРАТАМ 183
МИН ТАБИГАТЬ ЯРАТАМ 218
ЙОРТ ХАЙВАННАРЫ, КОШ-КОРТЛАРЫ 253
МИЛЛИ БӘЙРӘМНӘР 293
МИЛЛИ РИЗЫКЛАР 310
МИЛЛИ КИЕМНӘР 330
ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ 341